КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ
ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# 1960-1980 ЕЛЛАР ТАТАР ПРОЗАСЫ ТАРИХЫ
## II КИСӘК

КАЗАН, 2012

*Печатается по решению*

*Учебно-методического совета Института филологии и искусств КФУ*

*Протокол №6 от 27.04.2012 г.*

*заседания кафедры татарской литературы XX-XX1 вв. и методики преподавания отделения татарской филологии ИФИ*

*Протокол № 0.1.2.11.2.01 – 6.02.2012 г.*

*Автор-составитель*

доц., канд.филол.наук Г.Р.Гайнуллина

*Научный редактор*

доктор филол.наук Д.Ф.Загидуллина

*Рецензент*

доц., канд.фил.наук Э.Ф.Нагуманова

Гайнуллина Г.Р. 1960-1980 еллар татар прозасы тарихы (II кисәк): Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Ихлас, 2012. – 90 б.

1960-1980 еллар татар прозасы тарихы (II кисәк) дип исемләнгән уку-укыту ярдәмлеге “Татар әдәбияты тарихы (1960-1980 еллар)” курсын өйрәнүче студентларга атап төзелде. Төп курс өчен эшләнгән ярдәмлектә лекция материалы формасында шул чор әдәбиятына кагылышлы материал урнаштырыла, гамәли дәрес темалары, контроль эш, зачет сораулыклары, реферат темалары, төп һәм мәҗбүри әдәбият исемлеге тәкъдим ителә.

## Тема: XX гасырның 60-80 нче еллар татар прозасында стиль тенденцияләре

Үткән гасырның 80 нче елларына татар прозасында алга таба үзгәрешләргә китерәчәк стиль тенденцияләре аермачык күзаллана башлый. Беренчедән, лирик-эмоциональ башлангыч алга чыга һәм ул, бер яктан, әсәр тукымасында субъектив катламның зур урын били башлавын, икенче яктан, хикәяләүче яки автор образының, вакыйгаларны күзәтүче генә булып калмыйча, аларда катнашучы герой халәтенә күтәрелүен тәэмин итә. Әсәр чынбарлыгын сөйләүче-күрсәтүче генә түгел, ә бәлки шушы чынбарлыкка мөнәсәбәтен үсеш-үзгәрештә, хәрәкәттә сурәтләүче автор «мин»е, шуның тирәсенә тупланган лирик-субъектив катлам вакыйгалар (сюжет) катламыннан да зураеп китә, мозаика кебек чәчелгән вакыйга күренешләрне үз янына – бер үзәк тирәсенә туплый. Нәтиҗәдә әсәрдәге төп каһарман булган «мин»нең рухи дөньясы, аңы укучыга тәэсир итү вазифасын үз җилкәсенә ала. Әсәрнең иҗатчысы, язучы-автор белән янәшә әсәр тукымасында тагын бер автор образы пәйда була. Язучы-автор уңай герой ярдәмендә белдерергә мөмкин булган фикерләр, идеал нәкъ менә автор образы аша укучыга ирештерелә. Автор образы уңай геройга хас булырга мөмкин барлык сыйфатларга ия: вакыйгаларны, кешеләрнең эш- гамәлләрен бәяләүдә гадел, нечкә һәм саф күңелле, күзәтүчән, туган җирне туфракны яратучы, хезмәт кешесе, тормыштагы күңелсез моментларны авыр кичерүче һ. б. шундый яклары белән укучы күз алдында бербөтен булып калка. Мәсәлән, М.Мәһдиев, Р.Төхфәтуллин, Ф.Хөсни, Ә.Баяновның аерым әсәрләрендә без шушы күренеш белән очрашабыз.

Икенчедән, психологизм үсү күзәтелә. Мәгълүм ки, 1960-1980 елларда Ә.Еники, Ф.Шәфигуллин, Г.Сабитов һ.б. элгәргеләрдән Ф.Әмирханнар, Ш.Камаллар башлаган традицияне дәвам итеп, кешенең рухи дөньясын, психологиясен сурәтләү объекты дәрәҗәсенә күтәрәләр. Аерым әсәрләр дә шәхеснең уй-фикер, хис-кичереш, теләк-омтылышлар үзгәреше аның эш-гамәлләре сәбәбе итеп карала, күп кенә иҗтимагый күренешләр дә кеше күңелендәге хәл-халәткә бәйләп аңлатыла. Шуңа күрә, мәсәлән Ә.Еники әсәрләрендә, матди һәм рухи кыйммәтләр бер-берсенә комачауламый: рухи дөньясы бай булган геройлар (Акъәбиләр, Кларалар, Зөһрәләр) дөрес эш-гамәлләр дә кылалар, җәмгыятьттән дә читләшмиләр, һәм киресенчә, рухи доньясы ярлы булган кешеләр матди байлыкны бар нәрсәдән өстен саный.

Татар әдәбияты акрынлап иҗтимагый аңлатылышлы психологизмнан гомумән кешенең рухи дөньясын, тарихи яки иҗтимагый сәбәпләргә бәйләмичә, фәлсәфи кыйммәт дип карауга таба хәрәкәт итә.

Өченчедән, тәнкыйди башлангыч көчәя. Бу бигрәк тә А.Гыйләҗев иҗатында зур чагылыш тапты. Язучының һәр әсәрендә диярлек тәнкыйтькә дучар сыйфатлар үзләре бербөтен тәшкил итәрдәй җәмгыять сурәте, картинасы тудырыла. Әнә шундый тәнкыйди башлангыч шулай ук әсәрдәге субъектив катламны, хикәяләүче яки автор образының кыйммәтен арттыра, укучының акыл эшчәнлеген активлаштыра һәм әдәби иҗатны интеллектуаль яссылыкка таба хәрәкәт иттерә. М.Хәсәнов, Х.Камалов һ. б. язучылар иҗаты да автор уйланмасыннан ук башлана торган тәнкыйди парадигмага өстенлек бирә. Бу катламда иҗат ителгән әсәрләр әдәбият белемендә постреализм кысаларында карала торган күп кенә сыйфатларга да ия иде. Алар үз чиратында әдәбиятның тәнкыйди угын кеше-җәмгыять яссылыгыннан шәхес-система, тоталитар режим баскычына таба юнәлтә башладылар.

Дүртенче – публицистик башлангыч чит илләргә сәяхәтләр (М. Юныс, М. Мәһдиев), автобиографик истәлекләр (Ф. Хөсни, И. Гази, Ә. Еники), тормыш хакында сөйләшүне тарихи, фәлсәфи, әдәби аналогияләр белән баету (М.Галиев) фонында, язучы белән укучының интеллектуаль, акыл яссылыгында сөйләшүен тәэмин итеп, әзерлекле һәм зәвыклы укучыга юнәлтелгән әдәби катламның массачыл әдәбияттан ерагаюына нигезләнеп тамырлана, киңәя. Ул ассоциатив сурәтлелеккә, цитацияләр, коллаж алымнарына мөрәҗәгать итә, үзенчәлекле поэтика тудырырга омтыла. Бу алымнар әкренләп әдәби материалга, синтезга омтылмаган текстларга күчә башлый.

**Төп әдәбият**

1. Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.4-5.

2. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

## Өстәмә әдәбият

3. Лейдерман Н.Л., Липовецкий М.Н. Современная русская литература: В. 3-х кн.. Кн. 2: Семидесятые годы (1968-1986): Учебное пособие. – М.: Эдиториал, УРСС, 2001. – 288 с.

## Тема: XX гасырның 60-80 нче еллар татар прозасында лирик-эмоциональ башлангыч: Ә. Баянов прозасы

XX гасырның 60-70 еллары – татар прозасында соцреализм нигезләре какшап, язучыларның шартлы алымнарга киңрәк мөрәҗәгать итү, лирик-психологик башлангычны көчәйтү чоры. Бу дәвердә М.Мәһдиев повестьлары языла, В. Нуруллин, Г.Ахунов эчке монологка корылган әсәрләре укыла, шигърияттән прозага Ә.Баянов килә. Авыл прозасы вәкилләре җир кешесен данлап, алар үрнәгендә рухи кыйммәтләрне югары күтәреп прозада лирик катламны ныгыттылар. Шул ук вакытта бу күренешнең тарихи җирлеге гомум әдәби барышта, аерым алганда поэзиядә барган яңарыш белән бәйле.

Иҗатының һәм эчтәлегендә, һәм формасында актив эзләнүчән булуы, урынында үз сүзен әйтергә теләве белән буындашлары арасында да Ә.Баянов үзгәрәк урын тота.

Әхсән Фәтхелбаян улы Баянов 1927 елның 8 декабрендә Башкортстан республикасының Илеш районы Әшмән авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлап, төрле урыннарда эшләгәннән соң, ул 1951 елда Казанга килә һәм Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1956 елда университетны тәмамлый һәм аннан соң байтак еллар журналистика өлкәсендә эшли. "Социалистик Татарстан" газетасы редакциясенең хәбәрчесе, әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, "Казан утлары" журналының җаваплы секретаре, баш редактор урынбасары вазифаларын башкара.

Алтмышынчы еллардан Ә.Баянов проза өлкәсендә актив һәм нәтиҗәле эшли башлый. Ә.Баяновның “Тау ягы повесте” (1969-1972) – сугыш чоры, сугыштан соңгы авыл турында. Ф.Миңнуллинча әйтсәк, язучы әсәрдә “шул чор тормышының башкалар кулы тимәгән өр-яңа катламын күтәрә, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтенә кагылышлы җитди проблемалар кузгата”. Төп сюжет сызыгы приютта унынчы классны бетергәч, Юдино тимер юл станциясендә ике ел сварщик булып эшләгәннән соң армиягә киткән, нефть институтына керергә җыенган Тәбрик Тугашевның туганнарын эзләп кайтып баруы белән башлана.

Игәче Сөембикә апасы белән танышуы, әнисе исән түгеллеген белүе белән төенләнгән вакыйгалар егетнең туган җирен табуы белән чишелә. Тәбрикнең эчке монологына һәм янәшә автор сөйләвенә корылган төп сюжет сызыгы психологик урын һәм вакытның алга чыгуы турында хәбәр итә, төп геройның субъектив хронотобы тергезелә. Әсәрнең буеннан-буена сузылган психологизмның җан хәрәкәте алымы ярдәмендә яшәеш мәгънәсе дип төгәлләштерелгән туган җирне урату, буыннар арасындагы бәйләнешләрне аңларга өйрәнү кебек фәлсәфи проблемалар алга алына. Шул рәвешле, субъектив вакыттан, хәтердән тыш әсәрдә тарихи вакыт чагылышы да бар.

Кичерешләр чылбыры Тәбрикнең әнисе турындагы уйланулары – ана мәхәббәте дигән хисне тергезергә теләве белән башланып китә. Каршында басып торган хатынның әнисе түгеллеге билгеле булгач туган беренче хис хыял һәм чынбарлык каршылыгы кебек төгәлләшә, өй/юл хронотобы оппозициясен хасил итә. Ана үлеме турында белү Тәбрикнең тормыш белән рухи бәйләнешләрен өзә, югалтуның чиксезлеге тойгысы китерә. Шушы мизгелдән ул мәңгелек ятимлеккә дучар ителә. Хәзергедән үткәнгә, эчке монологтан һәм үз-үзе белән сөйләшүдән әнигә адресланган сүзләргә күчүләр бер-берсе белән кушыла. Күңелендәге каршылыклы уйлар көрәше туган җир, ата-ана төшенчәсен бар дип тә белмәгән егеттә үткән һәм бүгенгенең эчке бер бәйләнешен тоемларга мөмкинлек бирә. Бу хисләр ялгызлык мотивы белән көчәйтелә. Авыл өенең тышкы сурәтенә дә Тәбрикнең хисләре салына, бәясе бирелә. Ана портреты – әсәрдә бирелгән иң тетрәндергеч урын. Портретның йорт хронотобы белән бергә бирелешенә игътибар итсәк, мифологик туган нигезгә кайту мотивының эчтәлеген укырга мөмкин. Сәгать образы килеп керү мифологик мотивны мәңгелеккә кайту кебек төгәлләштерә. “Ана – иң башта баланыкы ул”. Бу кабатланып килә торган гыйбарәнең дә эчтәлеге шул. Көлемсәрнең исеменә дә шулай яшәү дөрес дигән мәгънә салына. Мифологик мотивлардан туган нигезгә әйләнеп кайту мотивына караган чабыр бәйрәменә кабилә-халыкның генофондын саклау йөкләмәсе салына. Туган нигез образын сандугач, гөлҗимеш, этәч образлары тулыландыра һәм аңа үткән һәм бүгенгене тоташтыручы мәгънәсе салына. Повестьта "кеше һәм табигать арасындагы бәйләнешне, тормышның чәчәк ату мизгелен символлаштыручы, мәхәббәт хисен универсальләштерүче сандугач

образы җыр текстында да кабатланып килә. Беренче җырны Тәбрик әкият дип кабул итә. Җыенда җырланган алдагы җыр мәхәббәт, якты үткәннәр турында. Өченче тапкыр Тәбрик ишеткән Гөләндәм җырлаган җыр аңа инде таныш тоела. Биредә сандугач һәм җыр образларына бәйле рәвештә Тәбрикнең рухи тәҗрибәсенең гомумәһәмияте билгеләнә. Тугаш бабай образы карт архетибына туры килә. Карт архетибы галәм акылы кебек күзаллана. Татар әдәбиятында еш кына ак сакаллы карт кебек гәүдәләнеш таба. Кеше тормышының иң авыр мизгелләрендә күренүче образ буларак билгеле. Юл хронотобы Хозыр Ильяснық генотибы булган Тугаш бабай ярдәмендә Тәбрикнең ябык пространстводан ачык пространствога таба хәрәкәтен сурәтли. Вакыйгалар вакыты белән психологик вакытны хәтер мотивы тоташтыра. Хәтер мотивы Тәбрикнең һәм Тугаш бабайның субъектив хронотопларын якынайта. Хатирәләр төсендә бирелгән эчке вакыт чынбарлыктагы вакытның кабатланмаслыгы белән килешмичә тизләнә, әкренәя, кире кайта, алга йөгерә ала. Тугаш бабайның хәзергесе исә җырлары аша сулу, арганлык, сагышлану, илһам сүнү вакыты булып күзаллана.

Үткәннән бүгенгегә таба агучы мифологик елга мотивы әсәрдә төрле модификацияләрдә (кое, чишмә) очрый. Тәбрикнең кое чистартуына егетнең Фәрхетдин яныннан кайтканда кое турында бәясе ачыклык кертә. Егет нәсел-ыруының үткәне турында күбрәк белгән саен чистарына, күңеле белән туган нигезенә кайта, берегә. Әтисе Мирсәет янына барганчы авылга чишмә суы бирү турында уйлануы да символик эчтәлекле. Егетне тагын бер сынау –фаҗигале үткән белән очрашу көтә. Тәбрик үткәннәр белән бүгенге бәйләнешләрен тоеп, кичерешләр аша үткәргәннән соң гына катарсис кичерә, авылны матурайту теләге белән укырга китә. Кое чистартуның чишмә булдыру кебек кабатлануы егетнең фикер масштабы киңәюе ябык пространстводан ачык пространствога хәрәкәте турында сөйли. Тәбрик үзен бөтен авыл язмышы өчен җаваплы итеп хис итү дәрәҗәсенә якыная. Баланың ана каберенә баруы – кичерешләр сызыгын югары ноктага менгерә. Тугаш бабайның агачны туганнар кабере дип йөртүләре турында әйтүе кеше гомерен тарих, милләт, ил вакыты контекстына куя. Сагыш, үкенеч, чарасызлык мотивлары Тугаш бабайның киләчәк турында уйланулары белән бәйле. Шул рәвешле Тугаш бабай образында мәдәни герой сыйфатлары да чагылып китә.

“Яшьлегемне эзлим” (1964-1966) повесте, Ф.Миңнуллин билгеләп үткәнчә, интеллектуаль укучыга исәп тотып язылган әсәр. Повесть 17 яшьлек Әниснең эчке монологы рәвешендә язылган. Әниснең һәр адымын 24 яшьлек студент Әнис карап, күзәтеп язылa.

Бу повесть басылып чыгуга ук тәнкыйтьчеләрнең игътибарын җәлеп итә. Бәхәсләр әсәрнең жанры, төп герой бирелеше тирәсендә бара. Әсәр турында үз чорында М.Маликова, А.Гыйләҗев, Р.Мостафин, Ф.Миңнуллиннар матбугатта төрле фикер-карашларын белдерәләр. Беренче ике автор төп герой бирелешенә игътибар итсә, соңгылары әсәрне жанр ягыннан бәяли. А.Гыйләҗев повестьны лирик повесть түгел, чөнки лирик чигенешләр эпик әсәрләргә хас типик күренеш дип бәяли. Р.Мостафин повестьны лирик дип әйтергә нигез бар, чөнки әсәр төп геройның эчке монологы рәвешендә язылган, лирик чигенешләр, фәлсәфи уйланулар, көтелмәгән ассоциацияләр тулып ята, ди. Бу фикер белән Ф.Миңнуллин да килешә.

“Яшьлегемне эзлим” авторның эчке монологка корылган лирик повесть язу юлында беренче адымы”, ди тәнкыйтьче. Балтик буе республикаларында, бигрәк тә Литва әдәбиятында киң таралган яңа форманы бездә иң элек Ә.Баянов куллана башлады”.

"Күңел серләрен ихлас сөйләп бирүгә корылган" әлеге әсәрдә психологик вакыт, субъектив хронотоп өстенлек итә. Эчке монолог структурасы нигездә психологик урын һәм вакыт белән бәйләнгән. Тарихи урын һәм вакыт сугыш алды һәм сугыш еллары, ә психологик урын һәм вакыт Әнис Бадигинның үсмерлектән яшьлеккә атлаган чоры кебек билгеләнә.

Повестьта юл хронотобы аерым мәгънәгә ия булып кабатлана. Юл перцептив вакытта Әниснең ябык пространстводан ачык пространствога хәрәкәте кебек аңлана. Өй-юл оппозициясе сюжет сызыгын хәрәкәткә китерә. Фәһимә белән бәхетен тапкан егетне юл тарта. Ябык пространстводан качарга теләү омтылышы өстенлек ала. Яшәү мәгънәсен, тормыштагы рухи кыйммәтләрне эзләп киткән Әниснең юлы түгәрәк хасил итә. Түгәрәкне үткәннән бүгенгегә агучы Агыйдел образы билгели. Агыйдел әсәрнең буеннан-буена сузылап төп сюжет сызыгын лирик-фәлсәфи, мифологик дулкынга көйли. “Бу сулар Агыйделгә тоташа,” – ди Әнис Фәһимәгә. Үткәнне бүгенге белән мәхәббәт тоташтыра, коены һәркем үзе казый, яшәеш мәгънәсе, бәхет турында уйланулар "Агыйдел рапсодиясе" кеше өчен мәңгелек. Бу өлештә тарантас, арба детальләре егетнең рухи үсеш-үзгәрешен ача.

Төп сюжет сызыгы Әниснең Фәһимәдән Ленага ияреп Уфага китүе ноктасында төенләнә һәм Сведловск, Уфаларны гизеп, туган нигезен табуы, Фәһимәне мәңгелеккә югалтуын аңлавы ноктасында чишелә. Туган нигезгә әйләнеп кайту мотивы мәңгелек кайтуның рудименты буларак табыла. Төп геройның җан хәрәкәтен ачарга ярдәмче образлар булып Фәһимә һәм Лена образлары килә. Фәһимә-Лена каршылыгы Әниснең рухи үсеш баскычын билгеләүче ярдәче сызык буларак карала. Портрет бирелеше ярдәмендә автор табигый һәм ясалма матурлыкка бәя бирә. Эпилог өлешендә бирелгән пейзаж мәхәббәт фаҗигасе мотивын билгели, сюжетка керергә ярдәм итә, аны каймалап ала. Әнис Бадигин алдан ук үзен бөтен Галәмгә чит, ялгыз итеп куя, чиксезлек һәм Галәм белән сөйләшүен әйтә. Ялгызлык һәм геройның читләшүе мотивы Әнис тормышының төрле этапларын, күренешләрен ача. Имән агачы яшәеш мәгънәсендә килүче пейзаж элементы, аны корыту тормыш кәүсәсенә балта чабу кебек кабул ителә. Әниснең халәтен бушлык-тулылык оппозициясе ачыклый. Моңа бәйле рәвештә әсәрдә мифологик үлем һәм яңадан туу мотивы килеп керә. Фәһимәне югалтуын аңлаган Әнис яшәеш мәгънәсен эзләп авылдан чыгып китә. Шәүлә биредә Әниснең күңеле, әйтелми калган сүзләре кебек яңгырый.

Әсәр ахырындагы тәрәзә егетнең Галәм белән кушылуын, иркенлеккә чыгуын белдерә: "Менә хәзер мин тәрәзә ачам, сине иркенлеккә чыгару өчен". Тәрәзә егетнең ябык пространствода булуы хакында да хәбәр итә. Баян, җыр – югалту-табышлар сызыгын тоташтыручы символлар. Баян егетнең беренче мәртәбә ачык пространствога аяк атлавы, кешеләргә шатлык китерә алуыннан туган ышанычы, уйларныкың илаһи белән тоташуы, үткән белән бүгенгенең берлеге, рухи үсешен күрсәтүче билге. Китәр алдыннан әнисенең баянны бирергә теләве ананың улына хәерле юл, җан җылысы табачагына өметләнүе кебек аңлашыла. Баян – явызлыкның якында гына булуын искәртеп килүче бүре символы белән каршылыкка керә. Баянны алып китү – иң киеренке нокта. Тарихи вакытка психологик характердагы детальләр киеренкелек өсти. Яшел төс егетнең ачык пространствога юлының символик белдерелүе: яшел диңгез - печән өсте, яшел өй, яшел дулкын.

**Текстлар**

1. Баянов Ә. Тау ягы повесте / Баянов Ә. Сайланма әсәрләр. Ике томда. I том: Повестьлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1993. – Б.7-117.

2. Баянов Ә. Яшьлегемне эзлим / Баянов Ә. Сайланма әсәрләр. Ике томда. I том: Повестьлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1993. – Б.118-281.

**Төп әдәбият**

3. Гайнуллина Г.Р. Ә.Баянов повестьларында лирик-эмоциональ башлангыч / Фәнни язмалар – 2006. – Казан: Казан дәүләт университеты нәшрияты, 2007. – Б.114-122.

4. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

5. Миңнуллин Ф. Шагыйрьнең прозасы / Балта явызлар кулында. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994. – Б. 263-300.

## Тема: М. Мәһдиев повестьларында лирик-эмоциональ башлангыч

Татар тәнкыйте М.Мәһдиев-язучыны үткәнен сагынучы, татар авылының тарихта калган кичәге көнен җырлаучы дип исемләде. Әдәбият тарихы фәне әдәби әсәрдә геройларның балачак хатирәләреннән алып хәзергенең үткен каршылыклы күренешләренә кадәрге язмышын хис һәм мөнәсәбәт тарихы кебек гәүдәләндергән, үткәндәге якты-бәхетле яшәү рәвешен хәтердә тергезү мотивларын импрессионистик алымнар баеткан әсәрләрне сентименталь реализм агымына нисбәтләде. “Торналар төшкән җирдә”, “Бәхилләшү” әсәрләрендә үткәндәге тормыш аерым кешеләр өчен бүгенгедән әһәмиятлерәк яссылыкка куела, лирик геройларның эчке дөньяларына заман үтеп керә, хис-мөнәсәбәтләр чор, иҗтимагый тәртипләр тәэсирендә хасил булалар, вакыт ягыннан тәртипле оешканлык, ретроспекция алымы үткәндәге психологик вакытка алып китә.

“Торналар төшкән җирдә” (1979, август-сентябрь) повестенда автор 1970 нче еллар ахыры әдәбияты өчен актуаль булган иҗтимагый проблемалар – татар авылының үткәне, бүгенгесе, буыннар арасында бәйләнешләр өзелү, туган нигезне оныту кебек мәсьәләләрне алга ала. Көчле позициягә – повестьның исеменә, беренче эпиграф һәм кереш

сүзгә вакытка бәйле бинар оппозиция чыгарыла. XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүче галимә Д.Заһидуллина вакытка бәйле бинар оппозицияләрнең үткән/бүгенге кебек ике чиккә аерылуы гомумиләштерүләргә омтылу тенденциясе белән бәйле булуын билгели: "Киңәю күренеше татар әдәбиятында вакытны аерым кеше гомеренә нисбәтле түгел, бәлки кешелекнең гадәти вәкиле булган шәхес тормышы һәм яшәеше кысаларында тергезү аша хасил була".

XX гасыр башының мәдәни, әдәби, милли тарихын өйрәнеп, иң кызыклы һәм иң кызганыч, гаҗәпләндерә һәм сөендерә алырлык сәхифәләрен татар укучысына җиткерә алган галим. М.Мәһдиев татар прозасының фәлсәфи канатына караган әсәрләреннән юнәлеш алган дип билгеләргә тулы нигез бар. Д.Заһидуллина күрсәтеп үткәнчә, "аның фәнни хезмәтләрендә үткәннәргә, яшәп киткән олы шәхесләргә, аларның бәяләп бетергесез эш-гамәлләренә соклану, шуларны бүгенге чынбарлыктан эзләп үкенү хисләре ярылып ята". Димәк, "үзе дә Тукай-Әмирханнар буынының бер вәкиле кебек тоелган" әдип әсәрләрендә XX гасыр башы әдәбиятындагы дөнья сурәтен – вакытны кешелекнең гадәти вәкиле булган шәхес тормышы һәм яшәеше кысаларында тергезү алымын үз итә, сюжет структурасына сала.

"Торналар төшкән җирдә" повестена кереш сүз хикәяләүчене җитди, тормышның моңлы якларына күбрәк игътибар бирүче, яшәешкә фәлсәфи карашлы хикәяләүче-геройны тәкъдим итү белән башланып китә: "Безнең авылдан бер генә герой да, бер генә академик та чыкмаган. Гап-гади, иң гадәти бер авыл. Анда зур сулар, таулар иркен болыннар юк, кыялар юк. Тагын бик күп нәрсә юк".

Эпиграфта сүз туган җирне сагыну турында бара. Автор-хикәяләүченең сагышы кешенең үзе өчен кадерле булган кыйммәтләрнең кадерен (туган ил, газиз кешеләр) югалткач кына аңлавы белән бәйле: "1976 нчы елның октябрендә мин Франциянең Париж, Марсель, Авиньон шәһәрләрендә йөрдем. ... Баш әйләнгән, тәэсирләр шундый көчле, ниндидер бер мизгелдә үзеңне онытып, югалып торасың. Ләкин нәкъ шул хәлдә – табигыйлекне югалткан бер хәлдә, нигәдер минем йөрәгем сулыгып-сулыгып алды..." Үткән/бүгенге оппозициясендә әдип үткәннең билгеләрен тергезә. Бу билгеләр үзара оппозиция хасил итәләр: "безнең авылда гасырлар буе үстерелеп, тукылып, эрләнеп, сугылып килгән киндерне" бүген джинсы диләр, ат итенең файдасы турындагы гыйльми ачыш "безнең авыл тегүчесе Хөснетдин абзыйга" күптән мәгълүм, арыш

капчыгының да бүгенге исеме башка, хәзер иң югары культура билгесе саналган безнең авылның бурабзары башкача атала. Кереш сүз өлешендә образларны детальләштерү урын ала. Үткән – алтын куллы буяучы, калайчы, тимерче; кызылга каккан кайры тун, сагыз, арыш капчыгы, күтүмкә, чутсыз катык. Бүгенге – джинсы, жвачка, озын чәчле егет, йоклар алдыннан бер стакан катык. Үткән/бүгенге оппозициясендә мотивлар да катнаша: Чуриле урыслары манып биргән киндер "кешеләрне матур итәм, кешеләргә матурлык бирәм дигән төшенчә белән бер", ә бүген "без аны тырышып-тырышып онытып ятабыз"; "эшнең көйле, ритмлы җайга салынган икәнлеген" белдерүче сагызны чәйнәүче Сан-Мартин төзек наратларның жвачка ясау өчен ясалган сырының елап утыруын ишетми. Шул рәвешле, кабатланган образ, детальләр, мотивлар аша "дөньядагы барлык халыклар өчен уртак гадәт, уртак гамәл, холык-фигыль, эш-гамәлләр" булырга тиешле хакыйкать атала – эшең көйле, ритмлы җайга салынган булсын дисәң, кешеләрне матур итәм, кешеләргә матурлык бирәм, дип яшәү дөрес. Әсәр шул турыда: "Бу әсәр – безнең авылда яшәгән, бүгенге буынга юньле әхлак-гадәтләр тапшырып дөньядан киткән кешеләр турында". Кереш сүзгә өстәмә өлешендә үткәне бүгенге белән бәйләүче таш, елга образлары автор фикерен ныгытып куя. Көчле позициядә укучы табачак әлеге хакыйкатьнең гомумәһәмиятлелеге иҗади гомумиләштерелгән таш образы аша искәртелә. Таш – мәдәни һәм дини күзаллау белән бәйле конструктив архитектура элементы. Ул – био- һәм семиосфераны, табигать һәм мәдәниятне, органик һәм органик булмаганны, яшәү һәм үлемне бәйләүче символ. Бу мотивны куллану нәселнең йомшак, хатын-кыз белән бәйле "борынгы хәтеренә" мөрәҗәгать төсен ала. Ташлар – телсез, алар сөйләме "өнсез". Дәшмәүләре борынгы заманнарның мифологик асылына тәңгәл килә. "Бәлки ата-бабалар баскан таш"ка бүгенгедәге "тимер рәшәткәле капка " – ике дөнья арасындагы чикне белдерүче образ каршы куела. Профсоюз җитәкчесе Нәкыйп абый белән тимер ишекле капка янында очрашу, иңенә авыр туган җир ташын сыйдырган капчык кигертү – яшәп килүче идеология шартларына җайлашкан үз асылына кайта алмый газапланган татар кешесе образын тәкъдим итү. Текстның башлам өлешендә автор укучысы образын шул рәвешле урнаштырса, хикәяләүче образын "кешеләрнең эш-гамәлләрен бәяләүдә гадел, нечкә һәм саф күңелле, күзәтүчән, туган туфракны яратучы, хезмәт кешесе, тормыштагы күңелсез моментларны авыр кичерүче" автор образы дип

идеаллаштырып кертеп җибәрә. Лирик-эмоциональ башлангычлы автобиографик повесть тукымасында тәкъдим ителгән әсәр чынбарлыгына карата мөнәсәбәтен үсеш-үзгәрештә, хәрәкәттә сурәтләүче автор "мин"е тирәсенә җыелган лирик-субъектив катлам вакыйга-күренешләрне бер үзәк тирәсенә туплый. "Нәтиҗәдә, әсәрдәге төп каһарман булган "мин"нең рухи дөньясы, аңы, укучыга тәэсир итү вазифасын үз җилкәсенә ала. Әсәрнең иҗатчысы, язучы-автор белән янәшә, әсәр тукымасында тагын бер автор образы пәйда була. Язучы-автор уңай герой ярдәмендә белдерергә мөмкин булган фикерләр, идеал нәкъ менә автор образы аша укучыга ирештерелә. Автор образы уңай геройга хас булырга мөмкин барлык сыйфатларга ия".

М.Мәһдиев повестьларында үткән/хәзерге оппозициясе әсәрләрне оештыру вазифасын үти. Авторның кереш сүзендә структура билгеләп үтелә: "... Фәрваз Миңнуллин сөйли: бу иптәшнең, ди, бөтен иҗаты – яшьлекне сагыну. Яшьлекне сагыну? Бу – минем өчен ачыш. Бәлки бу әсәргә исемне шулай кушаргадыр?"

Шул рәвешле, көчле позициядә әсәрнең сюжет структурасын оештырган мотив, образлар, хис-мөнәсәбәт сызыгы гомумиләштерелә.

"Төлке уйный торган орлар" дип исемләнгән беренче бүлеккә борынгы йола җырыннан алынган эпиграф ("Җиләк җыям, как коям Падишага бүләккә...) һәм исем сайланышы М.Мәһдиевнең XX йөз башы әдәбиятында колач алган мифлаштыру – мәгълүм мифларны файдалану яки яңа миф тудыру күренешенә мөрәҗәгать итүен раслап килә. Бу урында галим М.Мәһдиевнең җыр жанрына караган фәнни эзләнүләре барлыгын да күрсәтеп үтү урынлы булыр. Әдәбият галиме А.Г.Яхин белән бергә эшләнгән "Халык иҗаты әсәрләрен система итеп тикшерү" дип исемләнгән хезмәттә бик борынгы заманнарда җырның ничек барлыкка килүе хакында сүз алып барыла, иҗат процессына табигатьнең тәэсире, ихтыяҗ булып туган-үскән йола фольклоры, ритм һәм состав өлешләре кебек тәкъдим ителә. 1960-1980 еллар прозасында мифны үзенең әсәрләрендә сюжет структурасына төреп тәкъдим иткән әдипләр арасында М.Мәһдиевнең беренче урында торуы гаҗәп түгел.

Мифның тормышны концептуальләштерү чарасы булуы гомумбилгеле. Ул әдәбияттагы аерым, үзенчәлекле, конкрет күренешләрдән – гомумиләштерелгән, модельләштерелгән бәягә, типиклыктан архетипиклыкка хәрәкәт итәргә юл ача. Әдәбият, аерым

кеше яки гаилә, авыл яки гадәттән тыш вакыйга-хәл тарихы белән канәгатьләнмичә, милли тарих, гасырлар төпкеленә китә торган төрки-татар тарихы, кешелек тарихы хакында сөйли башлый. Мәгълүм мифологик материалга мөрәҗәгать иткән әсәрләрдә иң әһәмиятлесе – авторның шәрехләве, субъектив фикер катламы.

Беренче бүлектә җире рәтсез булу әхлакый югарылык белән янәшә куела: “Җире рәтсез якта халык һөнәрле була”. “Агач, юкә төшерү, мунчала чыгару, такта яру, утын әзерләү белән шөгыльләнгән төбәкләрдә гасырлар буе алга китә алмаганнар. Аларның бердәнбер табышы – әхлакый югарылык”. Дөнья мәдәниятләре өчен уртак кыйммәт дип исәпләнгән Җир образы мифопоэтик укылышта ана мәгънәсендә килә, яңадан туу, рухи үсеш, яңарыш, үз асылыңа кайтуны символлаштыра. Эллин акыл ияләре Җирне Яшәешне барлыкка китергән ана буларак илаһилаштыралар. Афиналылырның барлык серле Элевсин мистерияләре Җир культы – уңыш җыю, орлыкны саклау, җир эшкәртү белән бәйле була. Җир-Ана тудыручы, саклаучы, нәселне дәвам итүче буларак сакральләштерелә. Рус халкында «Алдама, җир ишетер”, “Җир яраткан кадәр ярат” дигән мәкальләр Русь дәүләтеннән үк килә. Бөек сәяхәтче Ибн Фадлан болгарлар илаһилаштырган унике исем арасында җир барлыгын теркәп калдыра. Әлеге образ дөнья фольклорында зур урын били, ут, су, һава белән беррәттән, борынгы натурфилософик дүрт стихиянең берсе буларак милли дөньяларны һәм акылларны сурәтләүче метател сыйфатында, дөньяның тулы картинасын тергезергә мөмкинлек бирүче кебек тамгалана. Галәмдәге яшәешнең башлангычында торган Җир-Күк пары – барлык мәдәниятләр өчен уртак мифологик сюжет.

Автор-хикәяләүче укучыны символик укылышта сынаулар аша үтү юлы кебек шәрехләнгән урман юлына алып керә: “Безнең халыкның бөтен рухи дөньясы урман белән бәйле”. Шул урында эпиграфта билгеләнгән, мифологик катламда яшерелгән тормыш гаделсезлеге, үкенү хисе эчтәлеккә кереп урнаша. “Үзгенә үткән, бәгырендә яман төер, кара кайрак булып калган, ахыр чиктә гомерен кыскарткан утызынчы елларга Мәһдиев иҗатында аерым урын, үзгә мөнәсәбәт яши,”– дип яза әдәбият галиме Т.Галиуллин. Тормыш-сынауның башлангычы – күңелдә урнашкан шом, куркуның әдип һәм аның замандашлары өчен шул елларга барып тоташуы аның һәр әсәрендә искә алына: “Безнең урманның бер почмагы минем гел күз алдымда тора. ... Телефонлы олы юл (бездә чыбыклы юл) кырыендагы

дүрт квартал почмагы ул. Анда юан баганалар утыртылган. ... Әлеге баганалар нәкъ кеше сыман утыралар, алар нәрсәдер әйтергә телиләр, сөйләшергә омтылалар. Кешеләрнең аларга ихтирамы шулкадәр зур, утыз өченче елларда утыртылган баганалар илленче елларда төптән череп, өзелеп аудылар, әмма бер генә кеше дә аларны утын итеп өенә алып кайтмады”.

Урман-сынау образына бәйле пейзаж, тышкы дөнья сурәтләнеше җир табигатенә хас образларга илаһи серлелек өсти. М.Мәһдиев үткән / бүгенге оппозициясен сакраль /профан оппозициясе белән көчәйтә. Бу оппозициянең сакраль ягын миф формалаштырса, профан ягы авторның мөнәсәбәте, фикере кебек хасил була: “Урманга беренче баруымны хәтерлим: дүрт яшьләрдә булганмындыр. Аңарчы урман безнең басу түрендә могҗизалы стена, серле әкият булып торды. Ул басу түренең бер почмагыннан башланып ике чакрым ераклыкта ярым боҗра ясап авылны әйләнеп уза. ... Менә, ниһаять, шул сихри дөньяның бер почмагына алып кереп мине бастырдылар. Күзгә ташланган иң беренче нәрсә күч-күч булып утырган абагалар иде. Аннан миңа карт имән ботагында утырган бер кошны күрсәтеләр. Ул, ахрысы, миннән бик аз гына кечкенәрәк иде. Мәче башлы ябалак. Аның бите миңа кеше бите булып күренде. Мифлардан килгән символик укылышта абага чәчәгенең ике мәгънәсе бар: “Беренчедән, аның халык ышануларындагы могҗазалы-романтик рухы саклanса, икенчедән, үзенең реаль эчтәлеген саклап, “дөньяда юк әйбер”, “беркайчан да булмаячак” мәгънәсендә кулланыла”. Серле дә, куркыныч та тоелган билгесез хыял чынлап та булмастай чынбарык, аны мәче башлы ябалактай кануннар богаулый, әмма тормыш дәвам итә, аның кануннары кырысрак: “Ахырдан, берничә еллар узгач, мин “уф алла” арбасы белән бу урманнан утын ташыдым. Абагалар беткән, мәче башлы ябалаклар да хәзер күренми иде”. Илаһи серлелекне Торна елгасы образы дәвам итерә. Көчле позициягә – исемгә чыгарылган, текстта кабатланган әлеге образ символик укылышта зирәклек, саклык, уяу булу һәм чисталык мәгънәсен белдереп килә. Төрки-татар әкиятләрендә геройның тугрылыклы һәм ышанычлы ярдәмчесе итеп сурәтләнгән бөркет образы белән янәшәлектә бирелү – сынаулар үткәндәге яшәеш кагыйдәсенең тәкъдим ителүе ул. Тугрылыклы, ышанычлы булу күңел чисталыгын саклый, үзең булып калырга, сынаулар килгәндә югалып калмаска ярдәм итә, ди автор: “Торна елгасы дигән урында язын торналар туктап бала чыгара иде. Урманнан

бөркет китү үзе бер зур вакыйга була иде”. Мифологик укылышта Аполлон образы белән тәңгәл бүре яктылык, ана мәгънәсендә килә. Мисырлыларда бүренең җимергеч көч буларак символлаштырылуы мәгълүм. М.Мәһдиев прозасында бүре символы ике мәгънәдә дә кулланыла. Бөркет образы белән янәшә килгәндә бүре куркыныч янавын белдереп кулланыла: “Авылга килгән бөркетне авылның бөтен кош-кортлары сизә иде. Бүрене дә шулай”. Идеологиянең вәхшилеген тасвирлау максаты белән унбиш яшьлек малайның бүре күрү вакыйгасын, ана бүренең аны исән калдыруын сөйләп, автор-хикәяләүче М.Җәлилнең “Бүреләр” шигырен стильләштереп, әлеге образның беренче мәгънәсен куллана: “Юк, ни генә әйтмәсеннәр – бүреләр кешеләр кебек үк яман түгелләр. Мәсәлән, НКВД кешеләре кебек...”.

Үткән / бүгенгене тоташтыручы кичерешләр сызыгы чыбыклы юл әдәби деталенә салына: “Әмма гомер буе минем йөрәгемне телеп-телеп сагыш кайнады, бала вакытта шул юкә төпләрендә чыбыклы юл буенда ятканда уйлаган уйларым миңа гомер тынгылык бирмәде, гел каядыр чакырып торды”. Шул рәвешле, кеше тормышының беренче кагыйдәсе атала: “Безнең урманның матурлыгын, мәгънәлелеген, акылын беләсегез килсә, аның эчен көзге вак яңгыр яуганда керегез. Керегез...” Импрессионистик алымнар белән баетылган пейзаж өлешендә хакыйкать тамчысы дип укылган яңгыр символы ярдәмендә автор тормышның мәгънәсен заман шаукымына уяу булып, буыннар арасындагы бәйләнешне саклау дип төгәлләштерә: “Вак кына аланнарда икешәр, өчәр булып моңаеп утырган печән кибәнәре. Аларны киртә белән әйләндереп алганнар, ул киртәләрнең кайрысын поши килеп каезлаган. Карт юкәләр вак яңгыр тамчыларын өсләренә җыеп акрын гына шыбырдашып утыралар, әле яфрак бар, әмма инде соңгы атналар. Каен инде саргаеп яфрак коя, яфрагын койган каен чыбыклары күксел шәмәхә слива төсен керә бара. ... Юеш киртәле печән кибәннәре җиләк исе, шипр исе бәреп торган коры ылыс түшәлгән чыршы төпләре – барысы да калыгып, көзне көтеп уйга калган. Шулар янында көз килгәнне тыңлап тору рәхәт тә, сагышлы да... Киләсе елда да шулай күрешә алырбызмы? Без исән булырбызмы? Урманчы кләймә сугып сезне утынга ыргытмасмы? Ә сез, печән кибәннәре, киртә буена килгән биек аяклы, кара ахак күзле беркатлы поши малайларына, кызларына бездән сәлам әйтегез. Ә сез, чыбыклы юл юл буендагы чокырлар, орлар! Сезнең иңкүлектә төлкеләр

уйнаганда Сез аларга әйтегез: сак булсыннар, аучы килгәнен сизми калмасыннар!" Автор шул рәвешле сакраль/профан чиген үткән геройны идеаллаштыра, аны тормышның мәгънәсен аңлаган, аны башкаларга өйтеп бирергә теләүче итеп таныта.

Икенче бүлектә автор-хикәяләүче хакыйкатьне күңелгә үткәргән укучыны аңа таныш булган бәхетле чынбарлыкка алып керә – Сабантуй, түгәрәк уеннарның татар кешесе тормышындагы урынын мөнәсәбәт тарихы итеп урнаштыра. Бу бүлектә илаһи серлелек җыр, моң образына салып тәкъдим ителә: "Бу инде кеше генә түгел, бу инде гармун гына түгел, бу – татар халкының гасырлар буена килгән моңы, рухи куәте, музыкаль потенциясе, бу – татар халкының оркестры, филармониясе, консерваториясе". Сабантуй – татарны туплый, җыйный торган бәйрәм, йола: "Сабантуй көне авылга күрше- тирә авыллардан нәсел-нәсеп җыела". Сабантуй мифологик мотивына татар халкының көнитеше, бәхеткә юлы дигән мәгънә салына. Түгәрәк уенны тасвирлау, җыр образы аша автор халыкның рухи тәҗрибәсенә универсальлек һәм гомумәһәмиятлелек өсти, иҗади гомумиләштерә: "Монда – үзенә бер дөнья. Үзенә бер закон. Син инде йөрәгең җитеп түгәрәк уенга кердеңме, рәхим итеп аның кануннарына буйсын. Бу – язылмаган закон". Автор татар кешесенә хас булган сыйфатларны берсүзсез үтәлергә тиеш язылмаган закон дип белдерә. Татар кешесен бәхетле итә торган сыйфат – битараф булмау, гаделлекне яклау һәм сер бирмәү. Һәр җыр ситуациясе шул хакта. Экзистенциаль башлангычлы , яшерен сагыш белән өретелгән һәр вакыйга һәрчак яшерен өмет ноктасында төгәлләнә.

Хикәяләүче укучыны татар кешесенә ят булган гадәтләр белән таныштыру ноктасына җитә: "Безнең авылда "ят" сүзенең эчке мәгънәсе коточкыч иде,.. "Ят" – синең иң газизеңә, иң кадерлеңә кул сузучы, күз салучы икән". Татар кешесе өчен хәсрәт китерүче, газиз кешеңә, кадерле хисләреңә, кыйммәтен билгеләп бетергесез гадәтләреңә кул сузучы ят, чит:

Алма биреп ашатырлар,
Ашама, бәгыркәем,
Аштырлар, ташлатырлар,
Ташлама, бәгырькәем.

Бу – "авыл йоклаганда да яшәүче рухи тормыш". Шул рәвешле, татар кешесенә тугрылыклылык, ышанычлы булу, уяу, сак булу хас, дип автор миф кертелгән эчтәлектән хис-мөнәсәбәтләр тарихы

катламына күчереп кабатлый. Татарның иң кыйммәтле ягы – бердәмлеге. Борынгыдыан килгән һәр йола кешедә бердәмлек, ярдәмчеллек  гадәте тәрбияләү максатына буйсындырыла. Татар тормышында һәр кешенең үз урыны, гамәле бар. Символик эчтәлектә кичке уен, җыр образына төреп автор-хикәяләүче бердәмлекне серле, илаһи хис дип бәяли: "Бу хорда һәркемнең үз роле бар. Моны берәү дә белми. Үзеннән-үзе шулай килеп чыга: берәү җырны башлый. Икенчесе җырның  билгеле бер урынында катышып китә. Өченчесе җырның билгеле бер урынында болай гына тавыш биреп куя. ... Дүртенче берсе билгеле бер урында сызгырып җибәрә". Халык тормышының үзе булып торган җырлар  турындагы сөйләм өметсезлек ноктасында төгәлләнә: "Уен җырлары һәм урам җырлары исә яшьләрдә үз авылына, үз туфрагына мәхәббәт тәрбияләү буенча озак кына файдалы хезмәт иттеләр дә тарих сәхнәсеннән төштеләр".

Яшерен сагыш белән өретелгән хикәяләү "Алай да чишмә бар әле..." бүлегендә дәвам итә. Автор эпиграф итеп С. Хәкимнең дүртьюллыгын кертә.

Чишмәләр үзләре минем
Учларыма су салды.
Су салды алар яшәргә
Көчәйтеп тик сусауны.

Чишмә образы яшәүгә дәрт бирүче шул ук вакытта сусауны – яшәүгә омтылышны ныгытучы  чыганак мәгънәсендә килә. Биредә әлеге яшәешне күзәтүче вазифасын башкаручы Сафый абзый тарихы сөйләнелә. Хикәяләүче укучыны "су буена таба бүлтәеп чыккан тау битенә" алып менә, урам тормышына читтән карарга чакыра: "Ул – бөтен бала-чагасы белән урам тормышыннан читтә". Зирәк карт архетипик моделе ("кызгылт бит, зәңгәр күз, очлы ияк, сирәк сакал, өстә – кызыл сатин күлмәк") бакчачы карт Сафый абзыйның төп гамәле – яшәешнең башлангычы символы булган чишмәне саклау: "Чишмәне ул карап тора, өстен яба, тамагын чүп-чардан чистарта, әйләнә-тирәдәге чүп үләнне йолка, үзенең хикмәтле, кирәмәтле бакчасына кереп югалганчы чишмәне бер әйләнә". Су, агымсу – кешенең чиксезлеккә төбәлгән соравына җавап бирүче: "Су – бик борынгыдан килгән яшәү символы. Тормышның килеп чыгышы хакындагы барлык легендаларда су – беренчел элемент". Сафый абзый – "уракчы хатыннарның яулыкларын артка чөеп, бит юганнан соң, көлтә бавы чылатулары, өстикәгә су тутырулары, "ат караучы Әхмәт

абзыйның башта чишмәдән агып чыккан ерганакка алып килеп, йөгән сабагын ычкындырып, аркалыгын бушатып, сызгыра-сызгыра ат сугаруы, аннан озын агач саплы кара тимер чиләк белән мичкәгә чишмә суын тутыра башлавы", кичкә таба вак-төяк кыз баланың бәрәңге юу, бүген суйган тавыкны юу, ит юу – ризык, тормыш итү өчен җаваплы: "Сафый абзый шунда бик бәхетле була, керт-керт атлап таудан чишмә өстенә үк төшә дә бәрхет чирәмгә җайлап кына утырып кәеф-сафа кора. Ул караган чишмәнең суын бүген колхозның җитмешләгән аты рәхәтләнеп эчәчәк. Сафый абзый шатлыктан кызгылт-сары тар сакалын сыпырса, аның вак зәңгәр күзләренә очкын йөгерә һәм ул бәхете ташыган кыяфәттә болай ди: "Алай да чишмә бар әле, име, Әхмәт!" Шул көе ул елмаеп кала.

Буыннарда туплана торган хис-кичерешләр өчен җаваплы Сафый абзый янәшәсендә бирелгән "сөйләшергә яратмый, эш кенә эшли торган, әмма Сафый абзыйның бу чишмәсенең кеше тормышындагы әһәмиятен югары бәяләүче Әхмәт абзый" образы – М.Мәһдиевнең күтелгән укучысы, югары әхлаклы камил татар кешесе образын гомумиләштерә: " ...һәм сүзгә гадәттән тыш юмартланып Сафый абзыйның әлеге лирик чакыруына ул да җавап бирә: "А-а..." Бу инде туган телгә тәрҗемә иткәндә менә нәрсә дигән сүз: әйе, ы-ы, Сафый туган, синең бу чишмәң безнең барыбыз өчен дә кирәк, син дөрес әйтәсең, сиңа рәхмәт. ... Әхмәт абзый да бүген үзенең артыграк сөйләшеп ташлавыннан кыенсынып калган сыман һаман әле чишмә инешенә үрелеп яткан атын ачулана: аты чишмәгә суга төшкән бер кызның чиләгенә үрелеп, авызлыклары белән зыңгырдап, төкле кара иреннәре белән чиләк бавын кыймылдатып ята икән".

М.Мәһдиевтә яшәешне анализлау өчен кулланылган бакча, чишмә образлары – гомумиләштерелгән образлар. Автор-хикәяләүченең өмете кебек формалаштырылган соңгы өлеш М.Мәһдиевнең милли йөзен үзе теләп җуйган татар кешесе иртәме-соңмы бер үз асылына кайтып, чишмәдә бит-кулын юар, җанын сафландырыр дигән теләге ул: " Бу чишмә әле дә шулай чурлап ага, безнең авылдан читкә киткән кешеләр авылга кайткач әле дә булса беренче чиратта шул чишмәгә төшеп битләрен, кулларын юалар, рәхәтләнеп суын эчәләр". "Дөньяның дүрт ягыннан нәкъ җиде юл кайтып төшкән җирдә урнашкан безнең авыл" – кешенең изге асылы, рухы, камиллеге.

Әсәрдә укучыга тәэсир итү вазифасын үз җилкәсенә алган автор-хикәяләүче буыннардан килә торган яшәеш тәртибен – эшең көйле, ритмлы җайга салынган булсын дисәң, кешеләргә матурлык бирәм, дигән максатны алга кую бурычын урман-сынауны үткәндәге төп канун буларак билгели, Хозыр Ильясның генотибы, зирәк карт архетипик моделе Сафый абзый образы ярдәмендә беркетә, ышандыра, иң кадерле кешесе – әтисе образы аша ныгытып куя. “Әти... Минем дә әтием бар иде, солдат булган, мәдрәсә шәкерте булган, Риза Фәхретдинов имзасы куелган зур документы – “имам-хатиб-мөдәррис” дигән дипломы булган, Тукай, Ф.Әмирхан иҗатын күңелдән белгән әтием бар иде”, – дип яза М.Мәһдиев үзен фәнгә китергән сәбәпләрнең берсе хакында. “Дүрт тополь” дип исемләнгән бүлектә әтисенең солдатка алыну тарихы белән таныштыра: “Гаиләдә ул төпчек малай булган, әтисез үскәннәр. Әбинең бу малайга өмете зур булган һәм аны ерактагы Сатыш мәдрәсәсенә җибәреп ун ел укыткан. Мәдрәсәне тәмамлауга әти наборга эләккән”. Тормыш тәртибе турында ата улына өйрәткән кагыйдәләрдән укучыга өчесе тәкъдим ителә: “Тәрбия өлкәсендә әтинең берничә таләбе бар иде. Моның өч пункты хәтердә калган. Ул таләпләрдән мин файда да күп күрдем, зыян да аз күрмәдем”. Шул рәвешле, буыннардан килә торган яшәеш тәртибен автор-хикәяләүче “Ялганлама.Тик дөресен генә сөйлә. Урлама. Кеше малына, дәүләт милкенә кагылма. Укытучы алдында белгәнеңне яшермә. Бераз белсәң кул күтәр. Укытучы үзе ярдәм итәр” кебек өч кагыйдәгә утырта. Димәк, кешеләргә мөнәсәбәттә гадел булу, белгән гамәлеңне кылу – иң камил һәм гади яшәеш тәртибе дип билгеләнә, гадел кешегә тормыш-укытучы үзе ярдәм итә, өйрәтә, алга этәрә, ди автор. Дүрт саны бөтенлекне, камил ритмны, гаделлек Алласын белдереп килә. Төп геройның әтисе тормышының бөтен, камил оештырылганын, гаделлек юнәлешендә икәнлеген хәбәр итү өчен автор-хикәяләүче дүрт тополь детален куллана. Тополь – биш серле агачның берсе, ел фасылларын символлаштыра: “ Нигә инде әти аларны тугыз-ун төп утыртмады икән?”

“Елларга иминлек бирсен” бүлеген автор-хикәяләүче үзенең “кечкенә вакытта тыңлаган догаларының берсе”ннән алынган сүзләр белән атый: “Тынычлык, иминлек шулай бик кадерле, ул безнең халыкның рухына сеңгән иде”. Биредә хикәяләүче “ата-бабадан килгән матур омтылыш – бердәмлек рухы”ның “авыл педагогикасының нигезендә” ятуын сөйли. Димәк, бәхетле булырга ата-ана аерым

өйрәтми, “авыл” җәмгыятендәге һәркем башка берәү өчен үзен җаваплылык тоя: “Олылар сөйләшеп утырганда да гел әдәп-әхлак кагыйдәләре, иминлек теләкләре белдерелә иде”. Бу өлештә Әсхадулла абзыйның сүзсез, елатмыйча гына алты малаен тыю өчен биш тапкыр тал чыбыгы сызгыртуы, Хәсән абзыйларда сөйләшмичә ашау әдәбенең үрнәк итеп алынуы, кош балаларын үтерүче Миңниислам исемле ташбаш малай мисалында “начарлык ягына адым атлаган кеше тормышта җәзасын таба” дип белдерү, “бөтен бер төбәкне беркетеп торган” Камәр түти мунчасы, өч-дүрт сәгать чыкмый юынып-сыйланып утыра торган Гыйльмениса мунчасы, ял итү – “таянып алу” өчен көйләнгән “дөньядагы иң тыныч урын” булган “Бүре Әскый сәкесе” , “дөньядагы иң тыныч кеше”, “гомер буе бер кеше белән дә конфликтка кермәгән” Бүре Әскый үзе – имин яшәү рәвешенең аталышы. Шул рәвешле, лирик-эмоциональ башлангычлы автобиографик повесть тукымасында автор “мин”е тирәсенә җыелган лирик-субъектив катлам вакыйга-күренешләрне бер үзәк тирәсенә туплый. Үткәндәге тормыш автор-хикәяләүче өчен бүгенгедән әһәмиятлерәк яссылыкка куела, хис-мөнәсәбәтләр чор, иҗтимагый тәртипләр тәэсирендә хасил булалар. “Җирдә икмәк үстерүче, урман кисүче, юкәдән – чабата, агачыннан башмак ясаучы, мунчаласыннан бау ишүче, чиста, әдәпле, ипле кеше” Әскый-Әсхәдулла образы ашы үткән/бүгенге кебек ике чиккә аерылган як татар кешесенең бәхетле яшәү рәвешен гомумиләштерергә омтылу: “Андый кеше юктыр, юктыр...” Дога белән башланган бүлекне Әскый картның үлем алдыннан әйткән азан белән тәмамлап, автор аның яшәешен сакраль/профан оппозициясен үтү юлы кебек тамгалап куя.

Татар кешесенең көйле, ритмлы, җайга салынган тормышы, кешеләрне матур итәм, кешеләргә матурлык бирәм, дигән максаты хәсрәтле чынбарлыкны яратып, рәхмәт әйтеп кабул итә белүе белән бәйле, ди автор әсәрдә гомумиләштерелгән Сафый, Сөнгат, Әсхадулла абзый образлары ярдәмендә.

“Әйа агач, яшең күпме?” бүлегендә Беренче Бөтендөнья сугышында тол калып үстергән өч малаен Икенче Бөтендөнья сугышына озатып, аларның үлем хәбәре белән бер-бер артлы өч кәгазь килгәч, “халык алдына чыгып елап йөрмәгән, хәлен сорашкан кешеләргә: “Шөкер, хәсрәтне күп күрдем”, – дип җавап биргән авыл табибәсе Мәрфугатти язмышы шулай ук авторның татар кешесенең тагын бер ягын изгеләштереп куюы. Шәфкатьлелек идеалын

символлаштырган 99 яшьлек карчыкның үлем алдыннан әйткән соңгы рәхмәте – татар кешесенең хәсрәтле чынбарлыкны рәхмәтле булып кабул итүе – тормышның көе, ритмы, җае ул, ди М.Мәһдиев. Ике малае сугышта эзсез югалган балаларны шатландыра белүче “Йосыф-Зөләйха” поэмасының бер нөсхәсе иясе рухи ана Хәдичәтти теле белән әйтелгән Г.Кандалый сүзләре – татар кешеснең рухи көчен аның рәхмәтле, сабыр булуына бәйләп фикерне ныгытып кую өлеше.

Яшәешне аңлату өчен сайланган алдагы образ “гомер буе кеше матурлаган”, “Тукайның үзенә тужурка тегеп биргән, Габдулла Кариевны, Мортаза байны, Камил Мотыйгыйны, Мотыйгулла хәзрәтне күреп-белеп сөйләүче ак тегүче” Гатият абзый, шулай ук Тукайга берничә тапкыр чалбар, күлмәк теккән икенче ак тегүче Хәмит абзый сюжет структурасына кереп урнаша, төп мотивны кабатлыйлар. “Кешене матур итәм” мотивын кабатлаучы кендек әбиләре образлары – яшәеш фәлсәфәсен әйтеп бирүчеләр. “Берәү – улдан, берәү – кыздан” бүлегендә һәркем белән исәнләшеп, һәр бала янында туктап, үзе таптырган балаларны башыннан сыйпап елап җибәрә торган кендек әбисе Газзәтти, ике бүрек киеп йөрүче кендек әби Гайшәтти игелеклелек идеалы буларак тәкъдим ителә.

Әсәр төзелешенә урнаштырылган борынгы йола-гадәтләр дә яшәешне анализлау өчен сайланган детальләр кебек кабул ителә. Шәл бәйләү, аулак өйләр – “тормыш-көнитештәге “күп мәсьәләләрне хәл итү урыны”: “ Монда кызлар бер-берсеннән хезмәткә өйрәнәләр (шәл үрнәкләре, чигү, бәйләү һ.б.), монда егет сайлыйлар, танышалар, аңлашалар, җыр-көй өйрәнәләр, уен уйныйлар”.

Әсәрдә вакыйгалар үткәннең бәхетен сагынып, балачакны хәтердә тергезү ноктасында төгәлләнми. Кабер детале яшәештәге ата-бала арасындагы арасындагы дәвамчанлыкның, тормышның өзелмәс-тукталмаслыгын, яшәүнең нindидер олы, шушы дәвамчанлык белән бәйле мәгънәсен беренче планга чыгара, кешенең үз эш-гамәлләре белән шушы олы кыйммәткә лаек булырга тиешлегенә басым ясала: “Хәдичәттинең кабере безнең авыл зиратының иң матур урыны – кояшлы, җиләкле тау кырында. Аның кабере очында бик көяз каен агачы бар. Җәйнең тын, эссе көннәрендә дә вак, затлы-пөхтә яфракларын дерелдәтеп, һава дулкыны белән серләшеп утыра ул каен. Мин шул каберлеккә килəм дә (Хәдичәтти янында үз әнием дә ята) каен башына текәлеп торам”. “Арчин” бүлегенә көчле позициягә – эпиграфка чыгарылган Р.Гамзатовтан алынган текст яшәү мәгънәсен

раслап куя: “Кешеләрнең кадерле җырлары өч төрле. Бу җырларга халыкның бөтен кайгысы һәм шатлыгы тупланган. Шуларның берсе бик якты: ул җырны бишек янында ана җырлый. Җырның икенчесе дә анықы: табутта яткан улының боз кебек салкын яңакларын сыйпап җырлый ул аны. Ә өченче төрлесе? Калган барлык җырлар өченчесенә керә...” Яшәеш кагыйдәсе – сабырлык Шәйхи алмазы, “Арчин” бүлегендә бирелгән Гатият Әсмасы фаҗигасе аша шул мотив кабатланып килә.

Алдагы бүлекләр – автор-хикәяләүченең – “малайлыктан егетлеккә аяк атлаган” яшүсмернең беренче тапкыр символик укылышта зирәклек, саклык, уяу булу һәм чисталык мәгънәсендә килгән торналар белән хушлашуыннан туган экзистенциаль сагыш мотивы кабатланган өлеш: “Торналар хушлашуын ишетеп иңрәп калган бу авыл мине үз баласы күк итеп ямансылап озатып калды. Сау бул, яшьлек!” Әтисе фаҗигасе, әнисе үлеме турында сөйләгәннән соң автор-хикәяләүче көчле позициядә – соңгы сүз өлешендә моң, хәсрәт нигезләнә: “Торналар шунда минем тормышымнан нәрсәнедер алып киттеләр. Мин үкенечле караш белән күккә күз юнәлтеп авызымны ачып тордым. Их, нигә ашыктым соң? Нигә тыныч кына карап тормадым?” “Мәңгелек матурлык, шигърият чыганагы” торналар, “сабырлык, акыл чәчә торган Масра юлы” – автор-хикәяләүченең теләге, үкенеч-сагышлары да.

Күренгәнчә, автор-хикәяләүче сюжет структурасын көчле позициядә бирелгән мотив-образларны кабатлауга кора. Еш кына интертекстуальлеккә мөрәҗәгать итү дә төп оппозицияне көчәйтүгә хезмәт итә. “Акрын искел, сәбах җиле!” бүлегенә исем итеп алынган Дәрдемәнд сүзләре сюжеттагы сагыш мотивын көчәйтә. Горур холыклы тегүче Хөснетдин белән Гыйльменисаттиләрдән автор-хикәяләүче меңъеллык тарихлы татарның өстәл китабы “Йосыф-Зөләйханы” әйттерә: “Йосыф-Зөләйха” кыйссасы турында мин күпме генә фәнни хезмәт укымадым! Бу турыда ничә генә лекция тыңламадым! Әмма алсу эре чәчәкле шәлъяулыгы белән бөтен аркасын-җилкәсен каплаган Гыйльменисаттинең урындык яртысын гына алып “ы-ы” килеп Йосыф кыйссасын укыгандагы кебек көчле тәэсирне бер җирдә дә алмадым”. Биредә XX гасыр башы “татар әдәбиятына үзенчәлекле метафизик күзаллау алып килгән” Дәрдемәнднең шигъри тезмәсен көчле позициягә чыгару аның шигырьләре белән аваздашлыкны табарга мөмкинлек бирә.

Дәрдемәнднең “яшәешне анализлау чагылыш тапкан шигырьләрендә дөнья сурәте гомумиләштерелгән образ хасил итә. Яшәешне аңларга омтылучы лирик герой аны ике: реаль / трансцендентал ь якларга аера. Хакыйкатьне шушы ике чик тоташкан урында табарга, теге яки бу оппозициянең билге-символлары аша белдерергә тели. Ул – кешелекнең бер вәкиле, гомумән, кеше аңының тирәлекне-яшәешне танып белү омтылышын үзендә йөртүче”. М.Мәһдиевнең сюжет структурасына хас булган реальлек / трансцендентальлек оппозициясе XX гасыр башы әдәбиятына тоташа икәнлеге раслана да. Дәрдемәндтә дә “лирик герой сагышының сәбәбен яшәешнең билгесезлеге тәшкил итә”. М.Мәһдиев исә тормышта гармония, сафлык сакланырмы, киләчәккә җитәрме, дип моңая, уйлана. “Бәхилләшү әсәрендә моңа җавап та бирә.


**Текстлар**

1. Мәһдиев М. Торналар төшкән җирдә / Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. 3 тода. I том: Повестьлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994. – Б.135-356.

**Төп әдәбият**

2. Заһидуллина Д.Ф. Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгат улы (1930-1995). – Казан: Казан дәүләт ун-ты нәшрияты. – 2003.- 45 б.
3. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

**Өстәмә әдәбият**

2. Жюльен Н. Словарь символов. – Челябинск: Урал LTD. – 1999. – 498 с.

4. Мифы народов мира. Энциклопедия (в 2 томах). Гл. ред. С.А.Токарев. - М. "Советская Энциклопедия" 1998. – Т.1. А-К. – С.70.

5. Урманче Ф. И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А-Г). – Казан: Мәгариф, 2008. – 303 б.

6. Яхин А.Г., Мәһдиев М.С. Халык иҗатын әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе (Мәкаль, табышмак, җырлар). – Казан: Казандәүләт ун.-ты нәшр., 1982. – 112 б.

**Тема: 1960 еллар татар прозасында психологизм үсү**
**(Ә.Еникинең “Туган туфрак” хикәясе)**

1960-1980 елларда Ә.Еники, Ф.Шәфигуллин, Г.Сабитов һ.б. кешенең рухи дөньясын, психологиясен сурәтләү объекты дәрәҗәсенә күтәрәләр. Ә.Еники әсәрләрендә, матди һәм рухи кыйммәтләр бер-берсенә комачауламый: рухи дөньясы бай булган кешеләр җәмгыятьттән читләшмиләр. Ә.Еникинең “Туган туфрак” хикәясендә “бөтен хисләрдән дә изгерәк, көчлерәк хис” дип туган туфрак хисе тәкъдим ителә, хис-кичерешләр сызыгының эчтәлеген тәшкил итә. Текст васыять образы белән ачыла, һәркемгә якын булырга тиешле туган туфрак хисе – ата-бабаның гомер иткән җире, гомер иткән нигез, ерак бабаларның каберләрен белү ихтыяҗы кебек төгәлләштерелә. Кларaның кичерешләре хисне танымаудан (“әллә кайдагы ул “туган туфрак” дигән нәрсә аңа ят иде, билгесез иде”) гармониягә ирешкәнгә күрә сөенүгә кадәр үсә (“беренче тапкыр, бик табигый рәвештә, туган җиренә, туган халкына, телдән генә сөйләнә торган түгел, ә кан тамырында йөри торган чын якынлык-мәхәббәт хис итте ул”).

Үткән-бүгенге, чит-үз бинар оппозицияләре Кларaның хис-кичерешләр сызыгын барлыкка китерә. Туган туфрак концепты символлар, әдәби детальләрдән оеша. Чыра-ут – илаһилык гәүдәләнеше, нәселне җыеп торучы учак образының модификациясе буларак текстта алдан ук тәкъдим ителә.

Хронотоп кичерешләр чылбырын хасил итүдә хәлиткеч роль уйный. Студент кыз Клара иң җитди вакытта – тормыш юлын сайлар алдыннан бабасының васыятен үтәр өчен юлга чыга, кояш баер алдыннан кечкенә бер станциягә туктый, караңгы төшеп тәмам күз бәйләнгәч Зиреклебашка аяк атлый. Яңа кичерешләр сызыгына – Каракошка иртәнге чәйдән соң юл ала, “йөзен кичке тау җиленә куеп” “тансык хисләр дулкынына” – үз асылына кайта.

Урын образына хис-кичерешләр сызыгын укып бару вазифасы йөкләнә. Кларaның кичерешләре туган туфракны “Питрәчнең көл балчыклы бәрәңге җирләрен” “бар икән ул туган туфрак дигән кадерле җир” дип кабул итүгә кадәр үсә. Клара килеп төшкән кечкенә станция – Кларaның яңа кичерешләр сызыгына аяк басуы турында хәбәр итә. Һәр вакыйгада хис-кичереш белән бергә урын үзгәрә. “Яңа чапкан печән тутырып, өстенә чуар палас бөкләп салган биле сыгылыбрак

торган тарантаска утыру” тәүге хисне – “җир якын, үләннәр якын” дип белдерелгән якынлыкны тоюдан “сагышлы һәм рәхәт көрсенүне” әзерли. Клара беренче тапкыр бабасының җырын искә төшерә, димәк, үзендәге буыннардан килгән хәтерне кабул итүгә әзерләнә. Җиде чакрымдагы Зиреклебашка кыз “туганлык хисен туймаганга күрә пошынып” калган хәлдә кайтып керә. Бу икенче хис кечкенә өйнең бусагасын (ике – чит һәм үз чынбарлык чиген) атлап керүгә алышына – кыз “югалып кала”. “Өйалдындагы махсус юып җыештырылган ак чоланда” йоклау кызны “беркайчан да татымаган “ хисләр чынбарлыгына – йон кабасы, тәрәш тарак, каен тузыннан теккән кечкенә тубал белән тулы һ.б. “әкәмәт нәрсәләр”гә сокланачак дөньяга алып керәчәк. Өченче хис – таныш түгел бу чынбарлыкны үз итү (“Странно, но мило!”). Тып-тын өйалды дип бирелгән урын ике чынбарлыкны очраштыра. “Киң билбаулы ефәк халат, ак танкеткалар” кигән көяз Клара ишектән чыкканда “чыбык-чабык күтәреп килүче” җиңгәчәсе белән очраша. Дүртенче хис – бу таныш түгел кешеләрнең аңа карата ягымлы була алуына аптырау (Иркә туташ дип эндәшү, сөлге, сабын күтәреп чыгу). Шунда Клара беренче тапкыр хәйран кала. Урын бирелешенә Кларада ачыла башлаган яңа чынбарлык турындагы фикер салына ( очы-кырые күренмәгән күкрәп үскән иген кыры). Сарыкның җан калтыравын белдерә торган карашы – Кларaның эчке дөньясында барган үзгәрешләрнең аталышы. Алсу белән Алмас – Кларaның “гаҗәп җиңел сөякле, куштан һәм татлы телле, үзеннән-үзе елмаерга торган” ягының ачылырга тиеш икәнлеген искәртү. Кызның Илаһият каршындагы бүгенге халәте символик укылышлы көзге образына салына. Автор укучыга Клара матурмы, дигән сорау белән мөрәҗәгать итә. Клара үзен олылаган туганнарыннан уңайсызлана. Күчтәнәчләр биргәндә беренче тапкыр елавы – үзен олылаган кешеләргә рәхмәтле булуыннан. Клара түргә утыртыла – шуннан торып ул әлеге чынбарлыкка бәя бирәчәк, аны өйрәнәчәк (өй эчен күзәтүе).

Бу урында Клара күзәтүче булудан туктый – авылдагы иң кырыйдагы өйдән урманга – сынау юлына аяк басу өчен капка төбенә чыга. Табигыйлек, хөрлек сокландырган Клара юл башында зирәк карт архетипик моделе кебек аңланган бабайдан хәер-фатиха ала: бәхетле булыр өчен үткәннәрне белү, хөрмәтләү тиешле (дога эчтәлеге). Бу изге сүзне дулкынланып кабул иткән кыз урманнан чәчәк бәйләме, сый-нигъмәт җыеп кайта. Ләкин кыз әле яшәештә кешене бәхетле

иткән як – ризык белән бүлешү бәхетен аңлауга әзер түгел (бәрәнне суйганга күңелсезләнүе). Җиңсез ак кофточка, киң итәк, чәчәкләр – Кларaның матурлыкны кабул итүе. Автор Хәсән вакыйгасы аша чын матурлык кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләрдә, бик азга гына шөкер итә белүдә дигән фикерне алга куя. Җиңгәчәсе сөйләгән вакыйга Кларaны гаҗәпкә калдыра – яшәеш, "дөреслек кайвакытта бик рәхимсез булса да, кешеләр аңа тыныч караса" үзгә була икән.

Шул халәттә Клара Каракошка – нигезгә кайту өчен тарантаска утыра. Таугa менү теләге – Кларада туган кичерешләр нәтиҗәсе. Кызның бу таныш түгел, әмма бик үз һәм якын булган кичерешләрне тагын да тирәнрәк тою теләге уяна. Бабасының сүзләре дә шул кичерешләр кайтавазы буларак искә төшә. Корысазлык турындагы вакыйга шул турыдагы хыялның бөреләнүен искәртә. Клара догадан соң беренче тапкыр "туган туфрак" хисен кичерә. Биредә Клара икенче тапкыр илаһият каршында – "үзе чиста, үзе рәхәт, салкынча" өйдә, күзге алдында кала. Югалган нигез белән – "билгесез, ят бер урын" белән очрашудан Кларада алдану хисе туа.

Тәбәнәк кенә манаралы кәкрәйгән айлы, искергән, тузган, мүк баскан, бүрәнәләре караеп беткән мәчет Кларaны гаҗәпкә калдыра. "Дөньяга күрмичә карыйлар" кебек тоелган мәчет тәрәзәләре – үзендәге матурлыкны күрергә теләмәгән татар кешесенең бүгенге эчке халәтенең укылышы кебек аңлана. Мәчет – татар кешесенең үзенән яшергән чынбарлыгы образы. Авылда яшеллекнең аз булуы бу яшәешнеүзгәртергә кирәклеге турында искәртү, сызланып белдерү.

Клара ап-ак казларны – нәселнең киләчәген күрә, ислекәй, ак әремне исни – дала исен сизә. Кларада беренче тапкыр үткәннәрне белү ихтыяҗы туа.

Вакыт сызыгы кайма хасил итә. Кояш баер алдыннан Клара яңа чынбарлыкка аяк атлый – таугa менә (печәнгә бару теләгеn әйтә). Сыерчыклар – кошлар символик укылышта җан, рух белдерелеше Кларадагы "рәхәтлек"нең аталышы. Клара үзгәрә – эшләпәсен сала, елый. Яңа тормыш юлына аяк баскан кыз буыннардан килгән бәхетле булу юлын кабул итә.

**Текст:**

1. Еники Ә. Туган туфрак / Еники Ә. Әсәрләр. 3 томда. 3 том. Хикәяләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1991. – Б.146-175.

**Төп әдәбият:**

2. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

## Тема: XX гасырның 60-80 еллар татар прозасында фәлсәфи катламның публицистик катлам белән керешүе (М.Юныс прозасы)

1960-1980 еллар татар прозасында автор позициясе әйдәп бару, автор һәм хикәяләүченең якынлыгы саклану әсәр тукымасына публицистик өстәлмәләрнең кереп урнашуына да сәбәп була.

Әдәбият мәйданында үткен телле, туры сүзле публицист буларак та килеп кергән Миргазиян Закир улы Юныс 1927 елның 25 маенда Татарстанның Баулы районы Исергәп авылында дөньяга килә. Авыл мәктәбенең алты классын тәмамлаганнан соң, ул ике ел колхозда эшли. 1944 елның августында армиягә алынып, хәрби авиация мәктәбенә укырга җибәрелә, аннары укчы радист сыйфатында бомбардировщикларда оча.1950 елда экстерн тәртибендә Харьков хәрби авиация училищесын тәмамлагач, авиаэскадрильяда элемтә начальнигы булып очуын дәвам итә, бер үк вакытта кичке мәктәптә укып, гомуми урта белем ала. 1955 елда, сәламәтлеге начараю сәбәпле, демобилизацияләнә һәм М.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының филология факультетына укырга керә, шул ук елны читтән торып укуга күчеп, 1961 елда аны тәмамлый. Шул дәвердә Кара диңгез дәүләт пароходчылыгында навигатор булып эшли башлый. 1957 елда кыска сроклы курсларны үткәннән соң, М.Юныс чит илгә йөри торган сәүдә корабы капитанының беренче ярдәмчесе итеп билгеләнә. 1968-1977 елларда бер-бер артлы Мәскәүдә Бөтенсоюз диңгез транспорты фәнни-тикшеренү институтында баш белгеч, СССР Диңгез флоты министрлыгында бүлек начальнигы һәм “Наука и религия” журналы редакциясендә бүлек мөдире вазифаларын башкара. 1977 елда диңгезгә кайтып, ул яңадан әүвәлге хезмәтендә – Кара диңгез пароходчылыкларында сәүдә корабы капитанының беренче ярдәмчесе булып эшли.

М.Юныс – әдәбиятка узган гасырның алтмышынчы елларында зур тормыш тәҗрибәсе туплап килгән прозаикларның берсе. Мөһаҗирләр язмышына, диңгез хезмәтенә, чит илләрдә яшәүче

халыкларның тормыш-көнкүрешенә кагылышлы кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгаларны тасвирлаган “Безнең өй өянкеләр астында иде…”, “Тимер фил”, “Әти оҗмахка киткәч”, “Ямәнгә сәяхәт”, Бездән яшерен зәңгәр дөнья”, “Диңгез чакыра” кебек хикәя, очерклары һәм романтик рухлы “Зәнзибар зәңгәр болытлар артында” исемле повесте белән ул үз укучысын тапты, аның күңел төпкеленә үтеп керде. Авторның шуннан соң язылган “Тозлы җил”, “Теләп алган давыл” повестьлары һәм “Энҗе эзләүчеләр”, “Табу һәм югалту”, “Шәмдәлләрдә генә утлар яна...” (« Биектә калу») әсәрләре киң катлам укучы тарафыннан яратып кабул ителде.  «Альбатрос язмышы» дигән баш астында дөнья күргән публицистик язмалар җыентыгы өчен М.Юныс 2004 елда Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә лаек булды.

Әдәбият галиме Т. Галиуллин билгеләп үткәнчә,  «М.Юныс геройларының эчке кичерешләрен, зиһен эшчәнлеген җентекләп, психологик  нечкәлек һәм лирик моң белән илһамланып сурәтли, рухи сфераны тасвирлауның киң мөмкинлекләрен эшкә җигә белә. Менә шунда авторның эрудициясе, язучылык әзерлеге ярдәмгә килә». М.Юнысның каләмдәше язучы М.Мәһдиев аның иҗади кыйбласын, тематика, жанр төрлелеген нигезләп карый: «Миргазиянның яраткан язучылары бар. Сөйләшкәндә, әгәр син ул язучының әсәрләрен укымаган булсаң, аның кәефе китә. Алар – Э. Хемингуэй, В.Быков, Ю.Трифонов, В.Конецкий. Соңгысын ул телгә алмыйча калмый. Чөнки В.Конецкий бүгенге иң күренекле язучы-маринист. Ул берәүне дә кабатламыйча әсәр яза белә... Әйтергә кирәк, В.Конецкийның бер китабы  «Мифлар һәм рифлар арасында» дип атала. М.Юнысның тормыш юлына, иҗат эшчәнлегенә күз салсаң, аның тормышы һәм иҗатына нәкъ шундый характеристика биреп булыр иде: ул гомере буе мифлар һәм рифлар арасында. Иҗат эшендә ул шактый кыенлыклар кичерә – язасы темалар күп, күргән - белгән күп..., язмалар аның кулы тигәнне көтә...Миргазиян ашыга, язасы темалар аңа тынгылык бирми. Вакыт җитмәүгә борчылып, ул кайвакытта чәчелеп китә, төрле жанрларга ташлана – мәкалә, притча, рецензия яза, ә әлеге зур тема - диңгез темасы туктап тора.

М.Юнысның “Шәмдәлләрдә генә утлар яна...” (“Биектә калу”) (1979) повесте дөнья күргәннән соң тәнкыйтьче Ф.Миңнуллин «беренче чор әсәрләрендә М.Юныс күбрәк материалларның яңалыгы белән алдырса, бусы – Ә.Еники стилендәрәк язылган фәлсәфи повесть булуы белән кызыклы. Ул – авторның язучы буларак тагын бер баскыч

югары күтәрелүе хакында сөйли...», дип, аның иҗади үсеш дәверләренең чикләрен билгеләп карый Тәнкыйтьче һичшиксез хаклы: повесть яшәү һәм үлем, мәхәббәт һәм нәфрәт турындагы, сугыш корбаннарына моңа кадәр кабатланып торган рәсми мәдхиягә каршы реквием булып яңгыраган «безнең әдәбиятта бу темага караган иң көчле әсәрләрнең берсе»: «...Ул – барыннан да бигрәк фәлсәфи тирәнлеге, эмоциональ тәэсир көченең зурлыгы белән аерылып тора».

Повестьта төп проблема булып фәлсәфи мотивлашкан яшәү мәгънәсе тора. Бу мәсьәлә татар халкы язмышы кебек төгәлләшеп, повестьның үзәк сюжет сызыгында катнашкан геройлар – татар егете Сәйрин Сәләхов, якут Максим Майнагашев, кырым татары Марсель Ялчинский образлары аша күрсәтелә.

Әсәрдә авторның эчке тавышы яңгырап тору, әдәби сурәтләү белән бергә публицистик стильгә мөрәҗәгать итүе – М.Юныс әдәби иҗатының үзенчәлеге. Повесть өметнең өметсезлек белән алышынып торуы, һәр хыялның сугыш шартлары, аяусыз кытлык аркасында җимерелү ноктасында калып килүе кебек антиномик структурага корылган.

Сюжет сызыгы Орел-Курск юнәлешендәге һөҗүмнең башланган чагында, икенче эскадрилья берьюлы дүрт экипажын югалтып кайткач, шунда күчерелгән лейтенант Сәләховның фронтны өзәргә килүче немец танкларын бомбага тоту операциясендә парашют белән сикереп качуы, сазлыкка кереп, тал тамырына ябышып исән калуы белән башлана. Яшәү теләге, яшьләргә хас булганча, үлем турында уйлаганда куркып калу башламда ук әйтелә, егетләр теле белән еш кабатлана. Сәйриннең тал тамырына эндәшүендә сугышның тулы бер буын язмышында котылгысыз фаҗига булып торуы укыла: “Кармалана торгач, Сәйриннең кулы тал тамырына төртелде. Ул аны көче, өмете һәм яшисе килү теләге белән эләктереп алды. “Өзелмә, тамыр! Зинһар, өзелмә! Миңа бит әле егерме дә тулмаган. Өзелмә, яме! Син минем бердәнбер ышанычым, киләчәгемнең, туачак балаларымның ышанычы”. Бу фикерне автор Ялчинский теле белән кабатлый, сугышның мәгънәсезлеген тормышның асыл мәгънәсенә каршы куя, кырым татарлары белән бәйле геноцидка бәйле сәясәтне фаш итә: “Соңгы вакытта Ялчинский төшенә башлады: эчендә җаны булган кеше куркудан котыла алмый. Куркуның файдалы, кирәк ягы бар. Ул булмаса, сугыш кырында үзеңне ничек саклап калыр идең? “Фоккер”ның пулемет көпшәләре тырпаеп торган тупас борыны сиңа

туп-туры үлем төзәгәндә ничек курыкмыйсың ди? Без бит бу дөньяга яшәр өчен килгәнбез. Тыныч яшәр өчен. Рәхәт, куанычлы яшәр өчен. Шатлык һәм мәхәббәт өчен. Ә без айлар, еллар буе үлем, сугыш эчендә яшәргә мәҗбүрбез. Туктаусыз сагалап йөргән үлем белән ничек уртак тел табып булсын? Ә кемне яклап үлемгә барабыз без? Әниеңне мал ташый торган сасы вагонга бикләп туган туфрагыңнан сөргенгә куучыларны яклапмы?” М.Майнагашев уйлары аша автор сугышның ачы хакыйкать икәнлеген, тормышка каршы тору яисә юану табу мөмкин түгеллеген, чарасызлыкны белдерә: “Ә яшәү киләчәктә дә, үткәндә дә түгел. Үткән гомер үлгән, ул җансыз. Киләчәккә әле җан кереп җитмәгән. Чын яшәү — шушы мизгелдә, безнең шушы сулышыбызда. Ул туктаусыз кими тора. Ә кимүне туктатырга бернинди чара юк. Шушы чарасызлык тизрәк киләчәккә элдертергә яисә үткән көннәр артына посып юанырга мәҗбүр итә.” М.Ялчинскийның һәм М.Майнагашевның хакыйкатьне яклау батырлыгы турындагы уйлары – авторның бу проблемага карашы, үз мөнәсәбәте.

Исән әйләнеп кайтуга ышаныч егетләрнең әниләре, дуслары, Разия сүзләре буларак яңгырый. Сәйрин әнисенең улы кайтуга тайпылгысыз ышанычы фаҗигане тагын да көчәйтә: “Синең исән калуыңа шулкадәр сөенәбез. Сиңа озын гомер теләп кылган догаларымны Аллаһы Тәгалә кабул итте, күрәсең. Инде кайтуыңны көтә башладык. Турай базарына барып, ике каз алып кайттым. Икесен дә каклап асып куйдым. Синең кайтуыңны көтәләр, ризык итәргә язсын иде.”

Фәлсәфи проблема “барон утарында кызгылт базальт таштан салынган биек йортта” яшәешнең өч катламы булу турындагы эпизодта дәвам иттерелә. Дүрт манаралы, нык диварлы, төрле төстәге борынгы пыяладан җыелган тар һәм биек витраж тәрәзәле урта гасыр ядкаре булган сарай деталенә автор буыннарны тоташтыручы, үткән белән бүгенгене сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрендә аңларга мөмкинлек бирүче мәгънәсен йөкли. Утарда көнитешнең бәйрәм, кунаклар, көндәлек һәм хезмәтчеләр катламына караган өлешеннән тыш, дүртенче – башка, астыртын яшәеш: яшерен мәхәббәт, яшерен дуслык, яшерен явызлык дип аталганы бар. Шәхеснең үз хакыйкате бу өлештә яшәеш фәлсәфәсен дәүләт сәясәте, хакимият мәнфәгате белән бәйләп куя. «Ул Германиянең архитектурасын, сәнгатен геройлары күзе белән бәяли, илнең үткәне, фашизмны властька китергән сәбәпләр турында

уйлана. Уйланулар әсәрнең интеллектуаль көчен, фәлсәфи эчтәлеген билгели һәм аны безнең чорга, заманга якынлаштыра», – дип күрсәтә Т.Галиуллин.

Идеологияне тәнкыйтьләү – повестьның лейтмотивы. Бу мотив сугышны тудыручыларга нәфрәт буларак та, табигый яшәү тәртипләрен бозучыларга кизәнү буларак та даими яңгырап тора. Сарайның купшы матурлыгын сурәтләү аша әдип буйсындыру, коллыкка төшерү сәясәтенә бәя бирә: "Сокланасың кильә…Кемнәр салган бу сарайны? Җиңүчеләр! Җиңелеп тапталган мескен халык! Һәрхәлдә, җиңелүчеләр түгелдер. Гадәттә, алардан зиндан салдырталар. Җиңелгән халык буйсынырга тиеш. Буйсыну булган җирдә төрмәгә ихтыяҗ туа. Мөнәсәбәтләрнең иң авыры – буйсыну". Совет системасында тәрбияләнгән кешенең күңелендәге идеологиягә беркатлы ышаныч белән чынбарлыктан курку каршылыгы тудырган тотрыклы драма совет солдатларының идәндәге шәүләдән куркып, ак буяу белән язылган кызыл комачны, "Сталин лачыны" гәзитен күргәч шатланулары вакыйгасында бирелә. Разиянең фаҗигасе – буйсындыруга, саф күңелле яшь кыздан шымчы ясарга омтылышның ямьсез, чирканчык нәтиҗәсе. Чакыруны алуга карусыз ризалашкан Разияне аклап, автор проблеманы милли мотивлаштыра.

Автор сәясәткә карашын Сәйриннең фикерләре аша трагик пафос белән укучыга җиткерә: "…сугыш өчен үстерәләр әниләр безне, сугышка җибәреп үтерер өчен яралган дәүләт өчен үстерәләр безне әниләр". Шулай ук Евдокия Семеновнаның Разиягә җирле халык тарихы турында сөйләве, М.Майнагашевның укытучысы Николай Юрьевич Бадерның якут халкы турындагы фикере мәдәни-иҗтимагый мәсьәләне милли проблема белән бер яссылыкка куя.

Яшәү матурлыгы – милли гореф-гадәтләрне саклауда, дигән эчтәлекне язучы повестьның лирик катламында, егетләрнең балачак, үсмер вакытларын искә төшерүләре белән бәйләп бирә. С.Сәләховның туган авылы турындагы хатирәләре авылдагы матур йола-гадәтләр – ит каклау, киндер агарту, шулай ук моңайган гармун детале белән төгәлләштерелә. Сәйриннең каклаган казны рус малайларыннан яшереп, соңыннан күңел газабы кичерүе үз табигатеннән читләшергә омтылган татар егетенең ялгышы кебек бирелә. Яшәешнең матурлыгы гореф-гадәтләр, йолалар белән бәйле булса, рухи бөтенлек, милләтнең борынгылыгына мөнәсәбәт халыкның киләчәген тәэмин итә, дигән фикер әдипнең үз яшәеш фәлсәфәсе, кредосы кебек укыла.

Җәмгыятьтә хөкем сөргән кануннарны автор милли йолаларны саклаган гаиләләрдәге тәртипләр белән янәшә куя, соңгыларының хакыйкать булуын раслый. “Өстенлек итү — тынгысыз тойгы. Өстенлеккә омтылу мәшәкатьле генә түгел. Өстенлек яулауны максат итеп куйган шәхесләр, өстенлек өчен сугышучы дәүләтләр үзләре дә сизмәстән кешелекләрен җуялар”,– дип күрсәтеп, сугышларның асыл сәбәбен аңлатып карый, җәмгыятьтә хөкем сөргән тәртипләрнең нигезен ачып сала.

Автор мәдәни-иҗтимагый мәсьәләгә дә милли йола-гадәтләргә мөнәсәбәт ноктасыннан басым ясый. Татар гаиләсендә борынгыдан килгән гадәтләрнең саклануын язучы тыныч яшәүнең шарты кебек раслый: “Әтисенең гаилә белән идарә итүе өстенлеккә көйләнмәгән иде. Аның һәр сүзе, кылган эш-гамәленә Аллага ышанган шикелле, ихлас күңелдән ышаналар иде. “Әтиегез болай эшләгәнне ярата...” “Әтиегез...” иң катлаулы мәсьәләне әнә шул сүз хәл итә иде. Каян килә икән шул ышану тылсымы “әтиегез” дигән сүздә? Әнисенең төп бурычы — гаилә эчендәге дустанә мөнәсәбәтләрне, туганлык, татулык хисен саклау иде. Бу вазифасын Сәйриннең әнисе сокланырлык итеп үтәп килде. Шунлыктанмы, Сәләховлар гаиләсендә яшәү тыныч һәм рәхәт иде. Шундый уңайлы иде гаилә куенында көн күрү. Барлык илләрнең җитәкчеләрен бергә җыеп, безнең баскыч янындагы тирәк төбенә утыртасы һәм әни ясаган чәйне эчертеп карыйсы иде, — дип Сәйрин юләрләрчә хыялланып куйды. — Шуннан соң да җир йөзендә гаугалар калыр идеме икән?” Разия дә – гаиләдәге иминлек, татулык, тынычлык өчен җавап бирергә әзер, бергә торуның җаваплылыгын – намуслы булуның үзең өчен генә түгел, ирең, балаларың өчен дә кирәклегенә инанган кыз. Автор бик үзенчәлекле борылыш ясый: “Җәмгыять өчен дә кирәк бу сыйфат. Разия соңгы сулышына кадәр Сәйриннең исеменә тап төшермәскә тырышачак”. Димәк, халык язмышы яшь кызлар тәкъдире аша үтә, дип, язучы әлеге фәлсәфи проблеманы яңа бер яссылыкта бирә. Әсәрдә ир-атның җан тынычлыгын тәэмин итүче хатын-кызның рухи камиллеге гаилә бөтенлегенең дә нигезе итеп билгеләнә. Талир тәңкәнең борынгы тавышы ирләр ызгышу, хатын-кызлар елашуга каршы куелу аша матур гадәтләрне үз иткән татар гаиләсе белән шуның киресе булган бүгенге гаиләне чагыштырып бәя бирүе авторның табышы кебек тоела.

М.Ялчинский образы, аның әнисе Сания, бабасы Әмит, сеңелләре Әсма, Земфира аша автор татар әдәбиятында беренчеләрдән булып Кырым татарлары фаҗигасе мәсьәләсен куя, димәк, телне, милләтне бүлгәләп таркатуга, юкка чыгаруга үз мөнәсәбәтен, позициясен белдерә. “Альбатрос язмышы” исемле публицистик язмалар тупланган җыентыгында урын алган “Телсезләнү: тамыры һәм җимешләре” дигән мәкаләдә әдип үзен ул трагедиянең шаһиты итеп күрсәтә: “Татар телен юкка чыгару өчен ташланган бомбаларның иң көчлесе, минемчә, Кырым татарлары өстенә төште: Ватан сугышында каһарманнарча көрәшкән тулы бер халыкка, сатлыкҗан мөһере сугып, аларны туган туфракларыннан сөрделәр”.

Яшәп килүче идеологияне тәнкыйтьләү Майнагашевның офицер дәрәҗәсенә әһәмият бирмәве, сугыш шартларында карьера ясарга омтылмавы, тормышны гади, табигый гүзәллегендә кабул итүен кат-кат искәртү аша да бирелә. Максим Майнагашев табигать белән гармониядә яшәүче кеше идеалы кебек аңлана. Халык фаҗигасе турында автор уйлануларының Максим исеменнән әйттерелүе дә очраклы түгел. Тормыш сәхнәсендә Майнагашев карьерист түгел, ә гади зирәк кеше, дип автор егетнең яшәешкә мөнәсәбәтен яклавын сиздерә. М.Юнысның идеалы – әхлак һәм табигать белән гармониядә яшәүче кеше. Повестьта әхлак мәсьәләсен төп критерий итеп кую, табигатькә соклану, фаҗига якынлашканда аңа сыену турындагы фикерләр әледән-әле кабатлана. Идеологиягә ярашу, аны кабул итү мәсьәләсе бөтен килеш-килбәте белән ил җитәкчесенә охшарга тырышкан штаб офицеры Павлов образында табыла. Власть яратучы Филимонов, Соколов, Орловларның тормыш фәлсәфәсе гадел, намуслы Растопчин, сугышчы егетләр саклаган кыйммәтләргә каршы куела. Автор бу конфликтны әдәби детальләр аша – Кононенко белән Майнагашевның йоклаган вакыттагы сурәтләрен янәшә куеп та көчәйтә. Ялчинскийның әнисен искә алганда кешегә баш ию психологиясе турындагы фикерләре, идеологиягә буйсынуны шәхси сыйфатлар белән бәйләве кызыклы. Н.Бадерның идеологиягә ярашу рухи бушлыкка китерә, дигән нәтиҗәсе шул ук фикерне тирәнәйтеп дәвам иттерә.

Идеологияне тәнкыйтьләү повестьта буыннар арасында рухи бәйләнешләр өзелү проблемасын күтәрү аша да алып барыла. М.Ялчинский, С.Сәләховларның зыялылыгы – исем, нәсел өчен җаваплылык кебек аңлана. Әсәр ахырында бирелгән өлеш – көннәр

җылыну белән, өмә ясап, йорт бүрәнәләрен эчке яктан пычак белән кырып юып, карчыклар килүенә Миңлезифа апаның бар җирендә саф, изге чисталык урнаштыруы, шомырт чәчкә аткан, бал кортлары бызылдап очып йөргән вакытта кунак җыюы, авторның борынгы йола-гадәтләрне тәфсилләп сөйләве Сәйриннең тормыш фәлсәфәсе нигезен тагын да тирәнрәк аңлата.

Яшәүнең матур бер шарты булган татулыкның бер-береңнән файда көтүгә, әшнәлеккә кайтып калып юкка чыгуы, төссезләнүе М.Юнысның "Табу һәм югалту" әсәрендә дә публицистик яңгыраш ала. «Биектә калу» повестенда табигать сурәте аша да, геройлары исеменнән дә әлеге темага автор даими рәвештә басым ясый, шәхси мөнәсәбәтен кабатлап тора: "Бал кортларының тату гөжләве гаҗәеп куанычлы. Аларның чәчәктән чәчәккә очып-кунып йөрүләре җанга рәхәт сала. Иртән явып үткән кояшлы яңгыр бал төшереп киткән. Баскыч төбендәге тирәкнең баллы яфраклары кояшта ялтырап ләззәтләнәләр". Бердәмлеккә бәйле үз карашларын автор Майнагашев аша да белдерә. Очу эшенең бердәмлек хисе тәрбияләве турындагы фикерләр бу теманы дәвам иттерә. Бердәмлек үзара мөгамәләдә җылылык, ярату, ышаныч, җаваплылык хисенең көчәюенә китерә, ахыр килеп бәхетле булуның шарты буларак аңлана (самолетка ышаныч белән карауның өмет уятуы, Майнагашевның эскадрилья очучыларына җылы мөнәсәбәте , көчекне тәрбияләве һ.б. ). Аяз, имин көннәргә ихлас сөенә белү, намус кушканча яши алуны рухи байлык белән бәйләп аңлатып, автор Сәйрин теле белән, Р.Мостафин әйткәнчә, «бүгенге кешегә кирәкле борынгыдан килә торган әхлак нормаларына басым ясый»: Тәнкыйтьче Р.Мостафин күрсәткән «гади күзәтүләрдән фәлсәфи гомумиләштерүләргә омтылуы» язучының стиль үзенчәлеге буларак билгеләнә ала.

Татар кешесенең күңел түрендәге яшерен тойгыларны уята алырлык сихри көчкә ия «Гөлҗамал» җырының тезмәсе повестьның бер исеме буларак тәкъдим ителү дә очраклы түгел. «Шәмдәлләрдә генә утлар яна...» эчтәлектә кабатланып, ачкыч-гыйбарә мәгънәсендә килә.

Беренчедән, «Шәмдәлләрдә генә утлар яна...» җыры – "синең сөйгән ярыңны көчләп пычрата, коллыкка куа, ата-бабаңның каберлеген таптый, нәселеңне, телеңне юкка чыгаручы дошманга җиңелү, туган илеңә дошман керү үлемнән дә хәтәр" булу турында:"

Үзең үлсәң, синең дәвамың булып нәселең, туганнарың, телең, ата-бабаңның сөякләре күмелгән изге җирең кала. Туган җиреңә дошман керсә, тапталмаган, мәсхәрәләнмәгән берни калмый. “Гөлҗамал” көе әнә шул турыда сөйли. Шуны аңлатырга тырышып өзгәләнә”. Димәк, җыр – ир-атны киләчәк өчен көрәшкә, гаделлекне якларга өндәүче символ.

Икенчедән, җыр – яшәү шарты, мәгънәсе, кызларның матур, якты киләчәк турындагы  хыялларын белдерүче билге: “Кавышу, ир кочу, бала сөю бәхетен бир, Раббым!” — дип ялварган авазлар ишетелә “Гөлҗамал” көендә. “Өмет тә, бәхет тә сугыш кырында йөрүчеләрнең исән калуларында”, — дип кисәтә борынгы көй. “Авыр ла җан сөйгәннәрнең булмавы...” — дип тетрәтә бәгырьләрне. Җырны, билгеле, күп сугыш, күп сагыш, күп михнәт күргән татар кызлары чыгарган һәм ул, онытылмыйча, буыннан-буынга тапшырылып килгән”.

Өченчедән, шәм утында татар егетенең сөйгән кызы сурәте чагылыш таба кебек: “Башына ак яулык чөйгән, билендә — күкрәкчәле ак алъяпкыч. Шәм утына аның колак яфрагындагы көмеш алкалары уйнап ала. Алтын түгел, нәкъ менә көмеш алкалар. Көмеш — иң саф металл. Анда тугрылыклы кызлардагы кебек пакьлек, гыйффәтлелек бар. Алтын — байлар, хакимнәр металлы”. Димәк, кызның тугрылыгы, намуслылыгы, сафлыгы – җәмгыятьнең тотрыклы, гадел, мул тормышын тәэмин итүче шарт икән.

Ахыр килеп, “ Шәмдәлләрдә генә утлар яңа...” – татар халкының фаҗигале язмышы билгесе: “Авыр гасырлар аша гасырларга сузылган Рәсәй золымы аша үтеп безнең чорга килеп җитә алган чын милли көй халык зарын, аның, су-гыш-ызгыштан туеп, тынычлыкка омтылуын безгә сөйли. Җырлый-җырлый, елый-елый җеп эрләүче җиткән кызлар. Грек мифологиясендәге арахналар шикелле, гасырлар буе күз яше, кан койган халык тәкъдирен эрләгән җепләре аша тасвирлый. Халык язмышы беренче чиратта яшьләр тәкъдире аша үтә. Нәселне дәвам иттерү, ата-бабадан калган йолаларны, гадәтләрне саклап тоту да аларга йөкләнгән. Токым пакьлеген саклап килү дә алар кулында. Нәселләрнең дәвамы кызларның егетләр белән кавыша алуында. Ир-егетләр сугыш кырында ятып кала килсә, нәсел корыячак. Шәмдәлләрдәге утлар сүнәчәк, ил өстенә караңгылык иңәчәк. Татар тәкъдире бу. Милләтнең киләчәге”.

XX гасырның 80 нче еллары реалистик прозасында да

публицистик өстәлмәләргә мөрәҗәгать итү саклана.

**Текст**

1.Юныс М.Шәмдәлләрдә генә утлар яна (Биектә калу) / Юныс М. Әсәрләр. Алты томда. I том. – “Рухият”, 2003. – Б.434-582.

**Төп әдәбият**

1. Гайнуллина Г. Кереш сүз / М.Юныс. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б.5-17.

2. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

3. Рахмани Р. Кыйблабызга тугрылык. Әсәрләр. Алты томда. I том. – “Рухият”, 2003. – Б.5-38.

**Өстәмә әдәбият**

1. Мәһдиев М. Секстан белән йолдызлар үлчәргә // Казан утлары – 1977. – № 5. – Б.148-152.

2. Миңнуллин Ф. Романга ни булды?/ Миңнуллин Ф. Балта явызлар кулында: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. (Т.Галиуллин кереш сүзе). – Казан: Татар. кит.нәшр., 1994. – Б.87-96.

3. Мостафин Р. Табышлар һәм югалтулар // Казан утлары. – 1980. – №9. – Б.162-164.

4. Хәлим А. Сагыну гамәле // Мәдәни җомга. – 1998, 9 гыйнвар.

## Тема: 1960-1970 елларда соцреализм чиген узган проза (Г.Әпсәләмов иҗаты)

Габдрахман Әпсәләмов – күренекле язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе, XX йөз татар совет әдәбиятында популяр булган, үз чоры замандашларының тормышын югары романтик пафос белән сугарып яктырткан, әмма соңгы елларның иҗтимагый-сәяси, эстетик үзгәрешләренә мөнәсәбәттә күләгәдәрәк калып, берьяклырак бәяләнергә дучар булган каләм осталарының берсе.

Һәр буын үткәннәрне, элгәреге иҗади мирасны үзенчә укырга, үз әдәби-эстетик зәвыге югарылыгыннан, иҗтимагый-мәдәни мөнбәреннән килеп бәяләргә омтыла. XX-XXI гасыр чикләрендә милли мираска мөнәсәбәтнең үзгәрүе нәтиҗәсендә**,** халыкның мәдәни

байлыгына үзгә караш ташлавы, соңгы елларда күләгәдә калып, күренми яткан әдәби катламнарны “ачуы” әдәбият тарихына, әдәби хәзинәләргә, шул исәптән совет чорында актив иҗат иткән әдипләрнең мирасына яңача карау, тикшерү-бәяләү мөмкинлеген бирде. Без бүген XX гасыр татар әдәбиятында соцреализм традицияләренә тугрылыклы иҗат иткән, шуның белән янәшәдә 1960-70 нче елларда романтик алымнар ярдәмендә эстетик идеал эзләү, кешене үткән һәм киләчәкне тоташтыручы күпер итеп карау, әдәби фикерләүдә милли сурәтне алга чыгару аша фикер үткәрергә омтылган Габдрахман Әпсәләмов прозасын да яңача укыйбыз, бәялибез, фикер төрлелегенә киләбез. Шул чорда әдәби мәйданда дан казанган әдип иҗатын барламыйча, заман күзлегеннән өйрәнмичә торып, әдәби-мәдәни дәвернең бөтенлекле картинасын тудыру мөмкин дә түгелдер. Язучының иҗади мирасына кабаттан әйләнеп кайтып, җентекләп күзәтеп чыгу XX гасыр татар әдәбиятына бәя, карашны тулыландыру мөмкинлеген бирә, бүген инде “совет” әдибе буларак бәяләнгән Г.Әпсәләмов иҗатының чор идеологиясеннән өстенлеген, совет идеалларына бәйләп, Кеше, тормыш фәлсәфәсен тәкъдим итүен танырга этәрә.

Габдрахман Сафа улы Әпсәләмов 1911 елның 28 декабрендә элекке Пенза губернасының Краснослободск өязе Иске Аллагол авылында (хәзерге Мордовия Республикасының Рыбкино авылы) дөньяга килә. Алты балалы гаиләдә иң олысы булган Габдрахман үз авылларында башлангыч мәктәпнең өч классын тәмамлагач, Мәскәүгә китеп, укуын Н. Нариманов исемендәге 27 номерлы татар урта мәктәбендә дәвам иттерә, әнә шулай әдипнең үсмер чоры һәм яшьлек еллары Мәскәү шәһәре белән бәйләнеп китә. Бу еллар аның күңелендә якты хатирәләр булып саклана, тормышының шушы этабы – халык телендә Әсәдулла мәктәбе дип йөртелгән әлеге уку йортында белем алган чоры хакында ул горурланып сөйли, татар теле укытучысы Фазыл Исхаковны, математика һәм физика укытучылары Нури Йосыпов, Җәлил Хәсәновларны җылы хисләр белән искә ала.

Шунда укыганда булачак әдип иҗат эше белән кызыксына башлый, әдәбият мәйданына юл сызган әлеге кызыксыну, иҗатка омтылыш яшүсмер малайны Мәхмүт Максуд, Мәхмүт Галәү, Муса Җәлилләр белән таныштыра, М. Җәлил җитәкләгән әдәби түгәрәккә алып килә, шигырьләр, хикәяләр, пьесалар язып каләмен, иҗат куәсен сынап карауга этәрә. Вакытлы матбугат битләрендә яшүсмер Габдрахманның исеме күренә башлый: “Әнвәр тегермәне” исемле

беренче шигыре “Октябрь баласы” журналында басылып чыга, югарырак классларда укыганда ул Казандагы «Азат хатын» һәм «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналлары белән тыгыз элемтәдә тора, актив языша.

Һөнәр училищесында  уку, заводларда слесарь, токарь булып эшләү дәверендә Г.Әпсәләмов әдәби иҗатка ныклап тартыла башлый, хикәя, пьесалар яза, бу еллар иҗатының өйрәнчеклек чоры буларак аерылып чыга. 1936-1940 елларда Мәскәүдә әдәбият институтында белем алуы, 1937 елда “Совет әдәбияты” журналында  «Маһинур» исемле хикәясе басылганнан соң, М.Җәлилнең “Ике Әпсәләм” шигыре белән “кыюсыз” егеткә фатиха бирүе, 1938 елда Казанга килүе булачак әдипне иҗади үрләргә канатландыра.

Әмма Габдрахманга бәйсез сәбәпләр күпмедер вакытка актив иҗаттан читләшеп торырга мәҗбүр итә. 1941 нче елның августында ул сугышка китә: Карелия фронтының диңгез бригадасы составында миномет расчеты командиры, 1943 елның җәеннән 1945 елның маена кадәр шул ук фронтта чыккан «Ватан өчен сугышка» дигән газетаның җаваплы секретаре, 1945 елның җәеннән 1946 елның апреленә кадәр (армиядән демобилизацияләнгәнче) Ерак Көнчыштагы «Сталин сугышчысы» исемле фронт газетасы хезмәткәре буларак көрәш юлын уза.

1941 елдан әдип каләмен “Ватан өчен сугышка”,  “Сталин сугышчысы” газеталарында,  “Совет әдәбияты” журналында чарлый, хикәя-очеркларын укучыга тәкъдим итә.  1941 елда – әле сугыш башланганчы — Г.Әпсәләмовның “Бәхет кояшы”н кулларына алган әдәбият сөючеләр 1944 елда аның “Төньяк балкышы” исемле җыентыгы белән таныша. Язучы үзе дә истәлекләрендә әдәби эшчәнлегенең нәкъ менә “Төньяк балкышы”ннан башлануы хакында хәбәр итә: “Аңарчы мин эзләнгәнмен, күңел төбендә яткан кайбер үрентеләр зәгыйфь кенә баш күтәргән, ләкин үземнеке дип әйтерлек төп сызык булмаган. Сугыш уты эчендә мин әнә шул орлыкны – туган ил романтикасын тапканмын”. Бу җыентыгында тәкъдим ителгән әсәрләрендә әдип сугышчыларның Ватан азатлыгы өчен көрәштәге батырлыгын сурәтләүгә йөз тота, патриотизм идеясенең, интернациональ мотивларның көчле булуы күзгә ташлана.

Шушы чордан башлап сугыш темасы Г.Әпсәләмов иҗатындагы үзәк темаларның берсенә әйләнә, чор таләп иткән батырлык культы, күтәренке романтик пафос алга куела. Язучының «Ватан улы»,

«Үлемнән көчлерәк», «Хәйбулла солдат» кебек беренче хикәяләре һәм «Ак төннәр» (1946) повесте ук шул хакта хәбәр итә. С.Хәким үз чорында аның иҗатын: “берәү дә алдан ук үз стилен тудырып килми әдәбиятка. Чор, заман язучыга аны тәкъдим итә. Әпсәләмов тулысы белән Ватан сугышы чоры язучысы. Шул заман рухы тудырган язучы. Күтәренке рух, романтик рух. Стиленең публицистик характеры да шуннан. Сугыш һәм яшьлек, героика бергә кушылды. Заманы романтик. Ватан сугышы ул поэзиядә – Фатих Кәрим, прозада – Габдрахман Әпсәләмов”, - дип бәяләп ялгышмаган. Әдәбият тарихына күз салу да  Г.Әпсәләмовның “үз сызыгын” табып, сугыш һәм сугыштан соңгы еллар татар әдәбиятының йөзен билгеләгән, төп контурларын сызган әдипләрнең берсенә әверелүен күрсәтә.

Сугыш һәм сугыштан соңгы еллар Г.Әпсәләмов иҗатының икенче чорын тәшкил итә. Ул шул чор сүз сәнгате кысаларында, алга куелган таләпләр яктылыгында иҗат итә, шушы дәвер әдәбиятындагы төп тенденцияләр аның иҗатының үсеш юлларын билгели. Мәгълүм булганча, XX гасыр татар әдәбиятының бер юнәлешен билгеләүче иҗтимагый-идеологик максатка буйсындырылган гомуми тенденция инкыйлабтан соң куелып, 50 нче елларга кадәр әйдәп бара.  Бөек Ватан сугышы елларында да  татар прозасында төп юнәлешне 1917 елдан соң сәяси тормыштагы үзгәрешләр һәм иҗтимагый вазифаларның эчтәлеге яңаруы нәтиҗәсендә яшәп килүче идеология шартлары әзерли. Әлеге вәзгыять кешене иҗтимагый тормышта һәм көнкүрештә тасвирлауны алга ала, үзара дуслык һәм ышанычка корылган мөнәсәбәтләр тәрбияләү бурычын куя. Пролетариат мәнфәгатьләренә хезмәт итәрлек, социалистик җәмгыять  үсешендә таяныч булырлык идеяләр алга чыга. Әдәбият галиме Д.Заһидуллина яңа концепциянең нигезенә революцион сәнгатьтә революциянең үзе чагылуын, чынбарлык материалы сәнгать әсәренә күчерелгәндә, коммунизм идеалы яктылыгында бәяләп күчерелүен, әсәрнең тормышка яңадан актив тәэсир ясавын – хезмәт ияләрен коммунизм  идеяләре рухында тәрбияләүгә булышу принциплары салынуын билгели. Шушы шартларда яңа тормышны социалистик идеяләргә нигезләнеп төзү мәсьәләсен үзәккә куйган әсәрләр языла. Татар әдәбиятында ул коммунизмның җиңәчәгенә чиксез ышаныч, оптимизм белән сугарыла. Кешедәге героизм, корбанчылык сыйфатларын данлап, яңа тормыш хакына үзен корбан итүчеләргә сокланып мәйданга килгән, 1934 елны рәсми рәвештә расланган соцреализм иҗат агымы 1940-1950 еллар

әдәбиятында төп юнәлешне хасил итә. Ләкин сугыш чоры әдәбиятка алып килгән яңа тема-проблемалар, әсәрләрдә сюжет хасил итүче сугыш-тыныч тормыш, дошман-илне саклаучы, чит җир-туган җир, яшәү һәм үлем каршылыклары бу агымны да күпмедер үзгәрергә мәҗбүр итә. Сугыш чоры әдәбиятында үлем-үлемсезлек төшенчәләре яшәү һәм үлем фәлсәфәсенең төп терәгенә әверелә. Яшәүнең төп максаты хакыйкать белән тәңгәлләшә, ә хакыйкать туган илне дошманнардан саклау рухы һәм шуның гамәлгә ашуы белән бәйләп куела, үлемгә фәлсәфи якын килгән әдипләр моңа кадәр бетү, югалу мәгънәләрендә килгән үлемне мәңгелеккә илтүче чара дип кабул итәләр; Ватан азатлыгы өчен үлем үлемсезлеккә, үлгәннән соң яшәүгә (азатлыгы өчен үлгәннәрне Туган ил бервакытта да онытмас, халык йөрәгендә мәңге яшәр гыйбарәсе шуңа тоташа) юл алу буларак кабул ителә, нәкъ менә шул яссылыкта үлем яшәү белән тигезләшә. Халыкны батырларча сугышырга өндәгән, әдәбиятны шул максатка буйсындырган идеология көрәшеп үлүне укучы күңеленә бердәнбер дөрес юл дип сеңдерә.

Чор әдәбиятының әлеге тенденцияләре Г.Әпсәләмов иҗатын кисеп үтә. Әдип социалистик реализм агымын романтик алымнарга баеткан иҗатчы төсендә калка һәм сугыш чоры татар прозасында хикәя, очерк жанрын үстерүче буларак таныла. Әдипнең документаль нигезгә корылган, вакыйгалар тезмәсен сөйләп бирү кебек оештырылган хикәяләрендә конфликт тыныч тормыш һәм сугыш чынбарлыгы, бурыч һәм намус, яшәү һәм үлем арасындагы кискен каршылык төсен ала, әлеге мәгънә еш кына теге яки бу образга йөкләтелә. Мәсәлән, “Зәңгәр иртә” (1945) хикәясендә иртә образына яшәү-үлем, юк ителү конфликтын көчәйтеп килү вазифасы йөкләнә. Хикәя каты яраланган ак халатлы Нурулланың бурычын үтәве – пакетны комбатка тапшыруы вакыйгасын әсәр сюжетына сала. Үз чорының идеалы схемасына утыртып иҗат ителгән Нурулла намусны яшәү кагыйдәсе иткән, сынаулар килгәндә дә вөҗданын саклап кала алучы герой булып ачыла. Төп герой тарафыннан яшәүне һәм үлемне мәгънәле итүче бердәнбер хакыйкать – туган ил, торган җир, сөйгән яр, балага карата зур изгелекләр кылу автор фикере кебек җиткерелә: “Нурулла ерак колхозда калган хатыны Тәнзиләне, “Әткәем кайчан кайтыр”, – дип тилмереп көткән биш яшьлек улы Сәлимне, чал сакаллы әтисе белән карчык әнкәсен, “Абыем!” дип өзелеп хатлар язучы сеңлесе Дилбәрне, гүзәл Ык суы буйларын, киң кырларны,

матур болыннарны хәтерләде һәм йөрәге яңа бер ашкыну белән тибәргә тотынды”. Яшәү-үлем каршылыгын алга куйган “Зәңгәр кыя” (1944) хикәясе исә җаваплылык хисен мәхәббәтнең эчтәлеге дәрәҗәсендә тәкъдим итә: “Үлем Мостафаның бугазына ук ябышкан иде. Шул чакта егетнең күз алдына Гөлбәдәре килеп басты. Ул моңсу да, бераз борчулы да күзләре белән Мостафага карый”.

Сәнгати эшләнеш ноктасыннан килеп караганда, 1941-1945 еллар аралыгында язылган татар хикәяләрендә эчке мәгънә хасил итүче элементлардан урын-вакыт төгәл билгеләнә: вакыйгалар сугыш вакытында взвод, рота, госпиталь, авыл, камалышта калган торак пунктта, елга тирәсендә һ.б. бара. Г.Әпсәләмов та урын бирелешенә аерым игътибар бирә, аның хикәяләрендә сугыш чоры өчен традицион урын-вакыт бирелеше милли прозада символ буларак укылган образлар белән янәшә куелып, лирик-эмоциональ яңгыраш хасил итә. Мәсәлән, “Үлемнән көчлерәк” (1943) хикәясендә диңгезче егет Искәндәрнең соңгы батырлыгы, тау итәгендәге Логи-Ярви күле янында утырган егетнең диңгезне сагынуы тасвирлана. Дошманны “Үлем кыясына” китереп, үз гомерен корбан итү хисабына иптәшләрен коткарган геройның күңел халәте  диңгез образында укыла: “Диңгез! Сөйкемле дә ул, куркыныч та ул, матур да ул, моңлы да ул. Аның көчлелеге, чикләнмәгән киңлеге, ак күбекләр чәчеп үкергән дулкыннары, ачы тавышлар белән кычкырып очкан акчарлаклары!..”. Әлбәттә, романтик идеаллар, югары романтик пафос әсәрне шул чор әдәбияты контекстында аңларга, кабул итәргә этәрә.

Лирик төсмерле хикәяләү исә ретроспектив вакытка мөрәҗәгать итүне сорый: “Бөркет токымы” (1944) хикәясе нәкъ шул юлны сайлый. Тыныч тормыш-сугыш кебек билгеләнүче үткән һәм бүгенгенең кырыс чынбарлыгы каршылыгы Рәшит Гыйззәтуллинның бабасы Шаһи карт белән сөйләшүләрен искә төшерүе кебек оештырыла: “Фронтта, сугышлар тынган арада, Рәшит шул үткәннәрне һаман исенә төшерә торган иде. Бәләкәй капчыгын аркасына асып, Шаһи карт белән ике куллап күрешеп, өеннән чыгып киткәннән бирле бик күп айлар үтте инде. Ләкин Рәшит Гыйззәтуллинның тыныч җаны тиз генә үзгәреп китмәде. Бөтен гомере хезмәттә, тынычлыкта, төзүдә үткән Рәшиткә яндырылган, туздырылган авылларны, хәрабәләр өеменә әверелдерелгән шәһәрләрне, бигрәк тә ерткычларча үтерелгән бала-чагаларны күрү шулкадәр гайре табигый бернәрсә булып тәэсир итте, ул берникадәр вакыт аңына килә алмыйча йөрде. Бу кадәр вәхшилекне,

бу кадәр мәгънәсез вату-сындыруны аның сәламәт акылы сыйдыра алмый иде”.

Сугыш чорында язылган намус һәм бурыч каршылыгына корылган хикәяләрдә олы җанлылык, сабырлык, хакыйкать мәгънәсен символлаштырып, даими кабатланып килүче карт образы бар. Г.Әпсәләмовның “Хәйбулла солдат” (1944) хикәясендә дә якты күңелле, шук табигатьле, кайгыртучан “отделениенең горурлыгы һәм мактанычы” булган карт солдат образы тудырыла. Ә сугыштан соң язылган хикәяләрендә автор сюжет тукымасын шартлы образлар белән баетуга игътибар бирә. “Онытырлык түгел”, “Аккош күле”, “Миләш”, “Әттиләү” һ.б. хикәяләре шул юлны дәвам итә, баета.

Г.Әпсәләмов бу чор иҗатында очерк жанрына да мөрәҗәгать итә. Хикәяләрендәге кебек үк, очеркларында да ул чорга аваздаш яшәү-үлем фәлсәфәсен үзәккә куя. Әдипнең гражданлык рухы белән сугарылган, гади хезмәт кешесенең сугыштагы батырлыгын данлаган очеркларын кисеп үткән төп лейтмотив – язучыны халык тормышы белән бәйләгән “күзгә күренмәгән бик нечкә җепләр”не кадерләп саклау, югалтмау. Сугыш чорында язылган очеркларын әдип “Карелия блокнотыннан”, “Заполярье блокнотыннан”, “Манжур сызмаларыннан” дип өч циклга бүлеп тәкъдим итә.

Г.Әпсәләмовның бу дәвердә язылган хикәя һәм очеркларында композицион корылыш, тема-проблематика, сюжет оештырылуы ягыннан жанр чикләрен сакламавы табигый. 1943 елда язылган “Карелия блокнотыннан” циклына кертелгән “Наратлар шаулыйлар”, “Йөрәк яна”, “Курай” очерклары хикәя жанрының лирик эчтәлеген, кабатлау алымын үз итә. Мәсәлән, кичәге авыл кешесе Сахабетдин Садретдинов батырлыгы хакында хәбәр иткән “Наратлар шаулыйлар” очеркын хикәя жанры белән якынайтучы як – нарат шаулавы турындагы лирик катламның кайма хасил итүе. Әдип публицистикасының бер үзенчәлеге буларак авторның укучысына мөрәҗәгать итеп сөйләве ассызыклана: “Наратлар шаулавын тыңлаганың бармы синең? Йөзәр ел буенча, җәйләрдә яшел ылысларына ак томаннар, кышларда ак укадай бәсләр уралып торган төньяк наратларының шаулавы үзе бер тарих ул”. Очерк 138 фашистны юк иткән егерме өч яшьлек Сахабетдинне дусларының мактавы белән тәгәлләнә. Яшәештәге төп кыйммәт буларак изгелек эшләп яшәүне раслаучы автор егетнең батырлыгын “өйдә калган ачык йөзле әнкәсе, шаян, чая Зәйтүнәсе, энесе Гыйлаҗетдиннәр”нең

киләчәген яклау белән бәйли һәм Сахабетдин образын яшәү мәгънәсе турындагы “йөзәр еллык” хакыйкатьне – автор фикерен җиткерүче кебек укучыга тәкъдим итә.

Үлем-үлемсезлек төшенчәләрен яшәү һәм үлем фәлсәфәсенең төп терәге дип раслау фикере әдипнең “Заполярье блокнотыннан” циклына кергән очеркларында да дәвам итә. 1944 елда язылган “Мәңгелек дан”, “Варангер-фиордта” очеркларында Нургали Хәсбиуллин батырлыгы үрнәгендә Ватан өчен, дусларың, якыннарың өчен үлем үлемсезлеккә юл алу буларак раслана, чиксез кыю операция башкарган Георгий Покромович исеме мактала.

1945 елда язылган очерклар “Манжур сызмаларыннан” дигән циклга туплана. “Ли Чен Чан картның әкияте” очеркы корея картыннан язып алган әкиятне сөйләп бирү кебек тәкъдим ителә. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр җылылыгы турындагы әлеге очеркта игътибарлылык, җаваплылык кебек сыйфатлар югары күтәрелә. Сукыр ата Сим-понсны коткару өчен кызы Сим-ченның үзен корбан итүе турындагы якты әкият укучыны тормышны газиз кешеләр өчен җаваплы була алу гына мәгънәле итә дигән фикергә алып килә, ул автор фәлсәфәсе, әдипнең тормышны гармониягә китерү юлын тәкъдим итүе кебек укыла. Әнә шулай сугышчы әдипнең истәлек язмалары фронттагы иптәшләренең исемнәрен мәңгеләштерү, чорга аваздаш яшәү-үлем фәлсәфәсен очерклар материалында тәкъдим итүе җәһәтеннән әдәбият тарихында үз урынын ала.

Сугыштан соңгы еллар Г.Әпсәләмов иҗатының, эчтәлеген саклаган хәлдә, форма өлкәсендә эзләнүләр һәм табышлар чоры буларак әдәбият тарихына кереп кала. Сугыштан соңгы татар прозасында Г.Әпсәләмов иң күп романнар авторы буларак танылу ала, роман жанрының чикләрен, мөмкинлекләрен киңәйтү юлында актив эшли. Әдипнең “сугыш эчендә табылган туган ил романтикасы”н тергезгән “Ак төннәр” (1946) повесте, “Алтын йолдыз” (1948) романы героик-романтик әсәр үрнәкләре буларак билгеләнә. Хикәяләүдәге героик пафос, дәвернең йөзен күрсәтү максатыннан патетик гомумиләштерүләргә киң урын бирелү, лирик башлангычның тарихи материалдан өстенлеге, субъективлык алга чыгу – Г.Әпсәләмовның әлеге чор иҗатын билгеләгән төп үзенчәлекләрдән.

“Алтын йолдыз” (1948) әсәрендә мәктәпне тәмамлаучы бер төркем үсмерләр, укучылар тормышын сурәтләү алга куела һәм якты хисле яшьләрнең үзара мөнәсәбәтләре олылар тормышының моделе буларак

уйланыла. Күп санлы экспрессив диалоглар, тәкъдим ителгән ситуацияләрдә аларның үз-үзләрен тотышлары идеаль чынбарлык кебек тәкъдим ителә. Сугыш шартларында төрле рухи-әхлакый сынаулар үткән, тормышка, киләчәккә якты уйлар, хыяллар белән караган яшьләр автор идеалының гәүдәләнеше булып укыла. Алар шул дәвернең заман герое буларак кабул ителә, әдип үзе дә бу геройларын замана геройлары дип күкләргә чөя: “Безнең алдыбызда нинди якты юллар тора, Галим, – диде ул, Галимнең кулын кысып.– Минемчә, сугыштан соң илебездә шундый зур төзелешләр башланыр, алар турында хәзер хыяллануы да кыен”.

Г.Әпсәләмовның “Газинур” (1950), “Мәңгелек кеше” (1960) романнары герой концепциясендә үзгәрешләрне хәбәр итә, алар геройларның бердәй модельгә утыртып эшләнүе ягыннан аваздаш. Үзәккә төп геройларның тормыш юлын, эчке кичерешләрен, шәхси батырлыкка ирешү юлларын куйган әлеге романнар тарихи-биографик материалга – документальлеккә мөрәҗәгать итүе, эпик материалның төгәлләнгәнлеге, милли яшәеш картинасына баетылуы белән дә үзенчәлекле.

Каһарман сугышчы Газинур Гафиятуллин язмышына бәйле героик пафос белән сугарылган, тел-сурәтләү чараларына һәм оста итеп сюжет тукымасына үрелгән композицион элемент-алымнарга бай “Газинур” романы дөнья күргәч, әдипнең каләмдәше Г.Бәширов: “Бу роман Г .Әпсәләмов өчен бер адым алга атлау дигән сүз”, – дип язып чыга.

Романның үзенчәлеге герой концепциясенең бирелешендә: Газинур образы катлаулы схемага утыртып эшләнә, берничә якны берләштергән герой буларак алга чыга. Бер яктан, ул, башка геройлар белән беррәттән, Г.Әпсәләмов тарафыннан соцреалистик концепциягә туры китереп уйланыла: колхозның конный дворында эшләп ат караучы, көтү көтүче Газинур соңрак леспромхозда урман кисә, һөнәр өйрәнә; туган якларына кайтып колхозда эшли башлый; Бөек Ватан сугышы башлангач, армия сафларына алына, башта санитар булып, аннары разведкада, соңрак пулеметчиклар батальонында хезмәт итә; бәрелешләрдә катнаша, командование тарафыннан аерып мактала торган солдат кече командирлар курсларына укырга җибәрелә, аннан кайткач, озак та үтми Газинур Матросов батырлыгын кабатлап һәлак була. Герой тормышы чын Совет кешесе моделенә утыртып, коммунистик идеалларга туры китереп сурәтләнә. Романдагы башка

персонажлар да – Гали абзый, Володя Бушуев, Зәбиров, Григорьян һ.б. автор идеалына якын кешеләр булып тәкъдим ителә.

Икенче яктан Газинур көчле шәхес моделенә җавап бирә, ныклык, ихтыяр көче, максатчанлык аны билгеләүче төп сыйфатлар буларак калка һәм табигать күренешләре, портрет бирелеше, психологик алымнар аша көчәйтелә. Мәсәлән, әсәрдәге пейзаж сурәтләнеше еш кына геройларның психологик портретлары белән аваздаш укыла: “Ажгырып торган амбразурага берничә адым калгач, Газинур бик азга гына тукталды. Язгы аяз күктә, биектә-биектә, бөдрә ак болытлар йөзә иде. Кояш нурлары аларны үтәдән-үтә яктырткан, алар шундый җиңелсыман тоела, өрсәң, тузганак башы кебек, очып китәр төсле. Үзләре шундый ак, беренче яуган кар да андый ак булмый, бугай... Кайда, кайчан күргән иде соң Газинур шундый ак болытларны?” Бу очракта ак төс символик мәгънәдә - җан, күңел аклыгы, пакьлеге, чистарыну, үлемсезлеккә китү мәгънәсендә төгәлләшә.

Яшәү-үлем, үз чорына аваздаш корбанчылык фәлсәфәсе роман материалында тәкъдим ителә: Газинур үзен туган иле, Ватаны, сөйгән яры, балалары хакына корбан итә, бу батырлыгы аны үлемсезләр сафына күтәрә; үлеме алдындагы мизгелдә җаны авырлыклардан арына. Башлам өлешендәге җәйге төн сурәтләнеше үк үлемсезлеккә, мәңгелеккә, Газинур батырлыгының бөеклегенә ишарә булып укыла: “Җәйге җылы төн. Күк йөзе яп-якты. Әйтерсең, аның көндезге зәңгәрлеген бик юка, бик җиңел пәрдә белән генә өретеп куйганнар. Шул үтә юка, үтә җиңел пәрдә астыннан Иләк йолдыз тонык кына җемелди. ... Еллар үтәр, кешеләр, бәлки, иләк дигән нәрсәне дә онытырлар, әмма бу шагыйрәнә исем халык телендә бик озак сакланыр”. Экспозициядә яз күренешен сурәтләү логик-символик чылбырны тәмамлый: “Яз шаулый. Җир яшәрә, агачлар яфрак яра. Тирәкләрдә кошлар сайрый. ... Ә тирә-якта яз шаулый. Җылы җилләр исә. Күгелҗем урман өсләрендә беренче күкрәү яңгырый. ... Бу күкрәү сугышчыларны киң кырларга, тыныч хезмәткә чакыра, туган җирләрен сагындыра, ашыктыра, җилкендерә”. Солдатлар Җиңү көнен сугышта һәлак булган иптәшләрен сагынып, ләкин киләчәк тыныч тормышка сусап каршы алалар. Автор тормыш сугыш бетү белән төгәлләнми, яралар төзәлә, сагыш-сагыну сүрелә, ә алда – бәхетле, тыныч, якты киләчәк дип кабатлый сыман.

Композицион төзелеш-корылыш ягыннан бүлекләргә бүлеп эшләнгән “Мәңгелек кеше” (1960) романы да шушы юлны дәвам итә,

үстерә. Ул герой сурәтләнеше ягыннан Г.Әпсәләмовның соцреалистик таләпләр кысаларында гына калмавын дәлилләп мәйданга чыга. Бухенвальд лагеренда бөтен авырлыкларны, газапларны үз җилкәсендә татыган Бакый Назыймов белән танышуы иҗатчыны әлеге әсәрен язуга этәрә. Роман тукымасында сурәтләнгән сюжет, тарихи вакыйгаларны детальләп, фактологик хаталарсыз китерү, реаль тарихи персонажлар белән эш итү "Мәңгелек кеше" романын документаль прозаның матур бер үрнәге итеп укырга мөмкинлек бирә.

Романның баш герое – реаль прототибы булган Бакый Назимов – әсәр тукымасында берничә яклы образ буларак ачыла, Газинур образы "моделенә" утыртып эшләнә. Бер яктан ул совет кешесенең типик сыйфатларын үзендә туплаган герой буларак ачыла. Беренче бүлекнең исеме үк ("Мин – коммунист!") геройның соцреализм принципларына таянып эшләнүен ассызыклап куя. Бакый совет идеалларына ихластан ышанган, шул система хакына көрәшүче герой, коммунист итеп сурәтләнә, аның һәр эш-гамәле шушы яссылыкта бәяләнә башлый.

Ләкин икенче яктан Бакый образы соцреализм кысаларыннан чыгып китә. Г.Әпсәләмов аны, сынмас-сыгылмас көчле рухлы, нык ихтыярлы кеше буларак сурәтләп, көчле шәхес концепциясенә утырта. Бакыйның гестапода коточкыч газапларга түзүе, дошманга каршы көрәше әлеге сыйфатларны алга чыгара һәм укучы аңында шәхси ныклык, ихтыяр көче тигезсез көрәштә дә җиңүгә алып килә ала дигән фикерне ныгыта. Пейзаж, портрет, хронотоп бирелеше дә Бакыйны шушы яссылыкта сурәтләүгә юнәлтелә. Мәсәлән, хронотопның еш алмашынып торуы, бүлектән бүлеккә үзгәрүе геройның төрмәдә, соңрак лагерьда булуы белән аңлатыла: Бакый реаль чынбарлыктан уенда гына булса да качу өчен, җәзалауларга түзә алмыйча аңын югалтканда хыялларына, уй-хатирәләренә чума.

Төп геройның күңел дәрьясын сурәтләү юлында прозаик үзен психологизм остасы итеп күрсәтә, Бакый хатирәләре психологизмның төрле алымнары ярдәмендә бирелә. Геройның камерада булганда сөйгән ярын искә төшерүе, аның турында кайгыртуы мизгелләре эчке монолог алымы белән сурәтләнә: "Чү, кем әйтә бу сүзләрне?" Күр, Кадриясе баш очында утырып, бәләкәй кулы белән аның чәченнән сыйпый бит. "И Кадрия, Кадрия! Кайдан килеп чыктың әле син бирегә? Менә күр, Бакыеңны нишләттеләр... Ярар, төзәлермен әле... Син елама... Көл. Менә шулай яшь аралаш көл. Их, син, минем нәни курчагым... Көнләшмәс дисеңме? Ай, юк, барыбер көнләшермен,

көнләшермен! Мин шундый көнче инде... Ачуланма, бәгырем. Әйдә, чәчрәп көл! Менә шулай... Син мине күтәрсең бит, ә алар... Әйдә. Дошман теләсә ни сөйләсен. Төкерәм мин аларның сүзләренә". "Газинур" романыннан аермалы буларак, "Мәңгелек кеше"дә пейзаж бирелеше үзенчәлекле. Беренче әсәрдә ул персонажларның психологик портретларын, эчке кичерешләрен сурәтләү өчен кулланылса, биредә табигать күренеше тасвиры фәлсәфи-семантик алым түгел, ә бәлки эстетик сурәтләү объекты вазифасын башкара: "Эттерсберг тавының көньяк-көнчыгыш ягын йөзәр еллык бүк һәм нарат агачлары каплаган. Гүя тау башындагы лагерь урнашкан бәләкәй сөзәклеккә кояшның җылы нурларын үткәрмәс өчен, анда мәңге дымлы салкын, томан, кар-яңгыр булсын өчен калын кара урманны юри көньякка китереп куеп, ә барлык зәһәр җилләр теләгәнчә уйнап йөри алсын өчен тауның төньяк-көнбатыш ягын, сыер ялаган кебек, шәп-шәрә иткәннәр. Шуның өстенә биредә һава гел үзгәреп тора: бер карыйсың, юка арестант киеме белән дә эссе, икенче карыйсың, салкыннан тешләр тешкә тими". Лагерь тормышы авырлыкларын күрсәтү юлында автор тирә-як пейзаж, экстерьерны сурәтләүдән тыш, лагерь бараклары, төрмә камерасы, кабинетлар интерьерын детальләп тасвирлауга басым ясый: "... Лагерь әйләнә-тирәсенә тыштан да бик күп дзотлар, дотлар тезеп чыкканнар. Лагерьны ураган сумак буенча, өйрәтелгән этләр ияртеп, эсэсчылар йөри. Менә шушы катлы-катлы тимер алка эченә алынган кысан мәйданга гитлерчылар ун меңнәрчә тоткыннарны китереп тыгалар. Соңга таба монда икешәр һәм берәр катлы итеп алтмышлап барак салына. Шул баракларда, яки биредәгечә әйтсәк, блокларда, өчәр-дүртәр катлы шәрә сәкеләрдә тоткыннар яши. Мондагы кысанлыкны бары тик кабер тарлыгы белән генә чагыштырырга мөмкин".

Романда көчле позициягә чыгарылган "мәңгелек кеше" метафорасы да яңа сыйфатларны билгеләү мөмкинлеген бирә: Г.Әпсәләмов бу романында кешене иң югары бөеклеккә, мәңгелек кыйммәт дәрәҗәсенә күтәреп сурәтли, үз чоры таләпләренә утыртып, көчле кеше фәлсәфәсен тәкъдим итә.

1959 елда Г.Тукай бүләгенә лаек булган "Сүнмәс утлар" (1953-1958) романы Г.Әпсәләмовны яңа иҗат дәверенә алып чыга, әдип прозасында 1960 нчы елларның икенче яртысыннан башланачак яңа баскычны әзерли. Язучының производство романы дип исем алган, яңа тормыш төзүчеләр яшәешен яктырткан әлеге «Сүнмәс утлар» романы шушы дәвердә соцреализмның үсеш юлында яңа баскычка күтәрелеп,

аерым кеше тормышының, яшәешенең кыйммәте хакында уйланулар белән баетылуын да раслый.

Казан заводларының берсендә эшләгән Уразмәтовлар династиясен сурәтләүне алга алган “Сүнмәс утлар” романы Г.Әпсәләмовны психологизм остасы итеп күтәрә. Язучы талантын билгеләү өчен критерий булырлык психологизмны прозаик сәнгати дәрәҗәдә эшләп чыга, киеренке эпизодны сурәтләү барышында бер алым белән генә чикләнми, ә бәлки алымнарның гармонияле синтезын тәкъдим итә: “Шундый шат, көләч, мөлаем, Гөлчирәнең кинәт бөтенләй үзгәреп, ярсып, театрны ташлап китүен Назиров башта берничек тә аңлый алмады. Нәрсә булды аңа? Ни өчен ачуланды ул? Ник китте? Гөлчирәнең хәтерен калдырырлык нәрсә эшләде соң ул? Бер генә минутка, анда да гафу үтенеп, Идмас янына барган икән... Назиров ачуланышуның бөтен сәбәбен Гөлчирәдән генә, аның аңлашылмас холкыннан гына эзләде. ... Назировның колаклары, битләре, муены, бөтен тәне әкренләп кыза башлады. Алдады бит ул теге вакытта Гөлчирәне. Антлар эчкәндә чынын әйтмәде!..” Шунда ук геройның эчке хисләре тышкы билгеләр аша да ачыла башлый: “Назиров төне буе йокламады, юләр кеше шикелле, почмактан почмакка йөренде, аннары хат язарга утырды. Кулына каләм алганда, аның кулы дер-дер калтыранды. Ул көч-хәл белән генә бер сүз яза алды. “Гөлчирә...” Артык яза алмагач, торып, яңадан йөренә башлады, яңадан хат язарга утырды”. Герой өзгәләнә, җаны сыкрый, күңелендәге туфанны әйтеп бирерлек сүзләр таба алмый, икеләнү катыш сагыну, үкенү туа, хис-фикерләре үзгәреш кичерә: “Назиров рәсемне кулына алып, шашкан кешесыман, аңа карап тора башлады. Гөлчирә чак кына елмайган. Элек Гөлчирәнең бу елмаюында Назиров тыйнаклык, нәфислек, оялчанлык, горурлык, яшерен теләкләр чагылышы гына күрә иде. Хәзер исә ачы ирония, үчекләү, рәхимсезлек кенә күрде. ... Назиров, җан газабына чыдый алмыйча, чишенми-нитми кроватена ташланды, йөзтүбән капланып, бик озак хәрәкәтсез ятты. Аннары, сикереп торып, тагын хат язарга утырды. Бу юлы буа ерылып киткәндәй булды, ул, сулыш та алмыйча, дүрт-биш битне язып та чыкты. Аңа калса, аның кайнар сүзләреннән кәгазьгә ут кабарга тиеш иде, ләкин Назиров хатын укый башлагач, аның сап-салкын икәнлеген күреп, ерткалап ташлады. Әгәр мөмкин булса, ул үзен дә шушылай вак кисәкләргә өзгәләп ташлар иде”.

Г.Әпсәләмов прозасына хас булганча көчле позициягә (эпиграфка) чыгарылган әсәрнең идеясе К.Тинчурин сүзләре белән дә көчәйтелә: “Без кабызган утлар сүнмәс алар, // Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә...” Әсәрнең исеме җыр сүзләре белән аваздаш килеп, сүнмәс утлар вакыйгалар барышында буыннар арасындагы бәйләнешләр, онытылмас хезмәт батырлыклары, бер буын төзегән тормышны икенче буынның дәвам итүе, бөек эшләр эшләүче гап-гади эшчеләр символы булып укыла. Әлеге роман әдәбият тарихы өчен чын мәгънәсендә хисси борылышлар, тирән эмоциональлеккә ия вакыйгалар белән сугарылган хезмәт романының матур үрнәге буларак кыйммәтле. Әлеге сүз-сурәт үзенчәлеге, сәнгати алымнар «Сүнмәс утлар» романыннан соңрак язылган “Күк күкрәр” (1972), “Агыла болыт” (1977) кебек романнарында да дәвам итә, үстерелә.

Г.Әпсәләмов романнарында кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләр милләтара мөнәсәбәтләрнең нигезе дип тәкъдим ителә. Шушы чорда иҗат ителгән хикәя-повестьларында да әдип тормыш фәлсәфәсен кеше күңеленең байлыгы, тирәнлеге белән бәйләп куя. “Дустым мәхәббәте” (1958) повесте Мин Ин исемле кытай кызы белән Вася Дубровин арасындагы якты хисләрне хикәяләп бирүгә корыла. Дустын татар театрлары, операсы, композиторлары белән таныштырганнан соң һәм татар шагыйрьләре, артистлары турында сөйләгәннән соң, кытай кызының “татар музыкасы безнекенә охшаган икән” дип соклануы әдипнең кешелек фәлсәфәсен җиткерүе кебек кабул ителә: “Мин чәчәкләр яратам. Җәй көне бакчамда үрмәле гөлләр үстерәм. Алар шундый матур, шундый купшы була, сокланмаган кеше калмый. Ничек сокланмасыннар! Үрмәле гөлләр дуслык билгесе бит”. Повестьта дуслык һәм гаилә шәхес өчен терәк дип иң олы кыйммәт дәрәҗәсенә күтәрелә. Әнә шулай 1950-1960 елларда язылган романнарында Г.Әпсәләмов яшәү фәлсәфәсен кат-кат, төрле яссылыкларда кабатлый. Аның бу дәвер иҗаты автор-хикәяләүченең укучысы белән герое ярдәмендә җылы, ихласи сөйләшүе буларак кабул ителә, әсәрләрендә сурәтләнгән дөньяның бай һәм төрле булуы күзәтелә.

1960 нчы еллар әдәбиятындагы үзгәреш-яңарышлар Г.Әпсәләмов иҗатына да “иҗади борылыш”, билгеле дәрәҗәдә үзгәрешләр алып килә: аның әсәрләрендә тематик-проблематик яңарыш, яңа сәнгати алым-чаралар күзгә ташлана. Әдип иҗатындагы әлеге үзгәрешләр чор әдәбиятында барган үзгә стиль тенденцияләренең формалашуына

мөнәсәбәтле килеп кереп калыплаша.

Билгеле булганча, 1960-80 еллар – татар әдәбиятының милли нигезләргә кайту чоры – татар прозасында яңа эзләнүләр, яңа сукмаклар, психологизмның, тәнкыйди башлангычның көчәюе, лирик-эмоциональ башлангыч алга чыгуы, публицистик башлангычның урын алуы кебек сыйфатларның алга алынуы, стиль тенденцияләренең, сәнгати алымнарның байлыгы белән билгеләнә. Шушы еллардан әдәбиятта бер тармакның соцреализм кысаларыннан чыгып китеп, классик, традицион реализмга якынаюы, реализм юнәлешен тәнкыйди башлангыч белән баетуы күзәтелә, сүз сәнгатендәге яңарыш-үзгәрешләр хакында хәбәр итә. Тәнкыйди парадигма шәфкатьсезлек, имансызлык, ялган кебек сыйфатларга юнәлтелеп, җәмгыятькә шул сыйфатларның хас булуын, кешеләрнең рухи ярлылануын күрсәтә һәм заман кешенең дөньяга карашын да, әхлагын да, холык-фигылен дә үзгәртә, үзенә яраклаштыра дигән фикерне ныгыта, алар җәмгыятьтәге, аерым кешеләр күңелендәге начарлык, ямьсезлекнең кешене кеше буларак юкка чыгаруы хакындагы фикерләр белән үрелеп китә. Шуның белән янәшәдә тәнкыйди катлам милли эчтәлекле мәсьәләләргә – рухи бәйләнешләр өзелү, традиция-гадәтләрнең, телнең югала баруы, әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүе, туган җир, туган нигез кадеренең кимүе, татар авылларының юкка чыгуы кебек проблемаларга игътибарын юнәлтә.

Көчле бер агым буларак башланып киткән әлеге сыйфат үзгәрешләре Габдрахман Әпсәләмов иҗатына да йогынты ясамый калмый. “Ак чәчәкләр” романы аның иҗатындагы сыйфат үзгәрешләренең хәбәрчесе буларак дөньяга чыга, язучының соцреализм иҗат кысаларыннан чыгып, “лирик агым”га йөз тотуын раслый. Габдрахман Әпсәләмов иҗатының гына түгел, чор әдәбиятының да гәүһәр ташы булган әлеге роман популярлыгы белән дә, образларның сәнгатьчә эшләнеше, әсәрнең әдәби камиллеге ягыннан да аерым урын тота. Үз вакытында ук әлеге әсәр социалистик реализм турындагы карашны киңәйтә һәм реалистик материалда романтик алымнарны уңышлы куллану мөмкинлекләрен дәлилләи, авыл прозасының сәнгати традицияләрен дә читкә куймый һәм аларны шәһәр кешеләренең тормышын сурәтләүгә юнәлтеп, шәһәр прозасы үсешенә өлеш кертә. Шул чор әдәбиятында, бигрәк тә авыл яшәешен сурәтләгән әсәрләрдә, геройны лирик-эмоциональ кичерешләр дулкынында тасвирлау күренеше Г.Әпсәләмовның шәһәр прозасына

караган әсәрләренә дә тәэсир итә, яңа сулыш өрә. Бүгенге көн югарылыгыннан торып бәяләгәндә романның кыйммәте шәһәр кешеләрен производствода, завод-фабрикаларда хезмәт иясе буларак сурәтләүдән китеп, зыялылар катлавын, аларның тормыш-яшәешен хис-кичерешләр, уй-тойгылар дулкынында тасвирлавы белән билгеләнә торгандыр.

Романда вакыйгалар катламы медицина институтын тәмамлап, гади татар авылында эшләгән Гөлшәһидәнең профессор Әбүзәр Таһиров җитәкчелегендә врач булып өлгерүе, үзенең хакыйкатен раславы һәм Мансур белән мөнәсәбәтләре, гаилә кору тарихы хакында сөйли. Төп геройның бәхеткә ирешү юлын тасвирлаган күпсанлы вакыйгалар төп ике сюжет чылбыры тирәсенә җыела: бер сызык медицина эшчеләре тормышын яктыртып, аңа хас проблемаларны күтәрсә, икенче сюжет сызыгы Гөлшәһидә белән Мансурга бәйле вакыйгаларны бер бәйләмгә туплый һәм романтик алымнарга таяна. Биографик вакыт чикләре Гөлшәһидәнең яшүсмер елларыннан башлап, шәхес буларак өлгерү чорына кадәрге вакыйгаларны берләштерсә, тарихи вакыт 1940 нче еллардан 1960 нчы елларның урталарын үз эченә ала.

Мәхәббәт тарихы белән бәйле романтик сюжет сызыгы Гөлшәһидәнең Мансур белән танышуы, гашыйк булуы, үткән мәхәббәт тарихлары һәм алдагы мөнәсәбәтләре турында хәбәр итә. Бу катламда мәхәббәткә бәйле эчке каршылык алга чыга һәм Гөлшәһидә белән Мансур күңелендәге хис / акыл көрәшен ача. Шушы башлангыч әсәрне психологик дулкынга көйли: күңел кичерешләре, теләк-омтылышлары әсәрнең буеннан-буена төрле сурәтләрдә укучыга җиткерелә, геройларның эчке дөньясын, кичереш-тойгылар үзгәрешен, күңел кичерешләрен ачуга юнәлтелә. Биредә психологизмның геройның үз эчке уйлануларын бәян иткән эчке монолог, үзанализ, психологик анализ алымнары күзәтелә. Автор Гөлшәһидә һәм Мансур күңелендә туып, үстерелә барган хис һәм фикер көрәшен, үсеш-үзгәрешен детальләп сурәтли, укучыны аларга сокланырга, алар өчен борчылырга, алар тормышы белән яшәргә мәҗбүр итә. Текстта символик, метафорик образлар һәм детальләр дә еш кына психологик характерда булуы белән үзенчәлекле, “Ак чәчәкләр” романының уңышы да, бәлки, әсәрдә психологик кичерешләрнең киң һәм иркен бирелүенә бәйледер.

Геройларның субъектив кичерешләрен җиткерү барышында иң киң таралган алым буларак әсәргә җыр текстларын урнаштыру аерылып чыга. Әсәр тукымасында җырлар метафора буларак ике мәгънәне – гомер агышын һәм мәхәббәт кичерешләрен ачуга буйсындырыла, аеруча соңгысы киң кулланыла. Ул Мансурны өзгәләнеп көткән кыз кичерешләрен дә ("Энҗе дә мәрҗән кызларның кул бавы, Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы"), күңелдә даими яшәп килгән Олы хисне дә ("Гыйшык уты сүнә диләр, Сүнми дә, сүрелми дә"), Фазылҗанның мәхәббәтен кабул итә алмыйча бәргәләнү газабын да ("Җил исә тын гына, ай йөзә моң гына, Күңелдә ул гына, йөрәктә ул гына..."), Мансурның Гөлшәһидәне юксынып бәргәләнү тойгысын да ("Ул уйнаган көйнең авазлары кемнедер эзлиләр, сагыналар, юксыналар, кемгәдер омтылалар, аннары диңгез дулкыннарыдай ярсып ярга бәреләләр дә, меңгә чәчрәп, кире чигенәләр... Күзгә яшь килә, бугаз кысыла. Аннары буйсынырга теләмәү, язмышка риза булмау авазлары яңгырап калкып чыга, яңадан көчле, дәртле, өметле авазлар яңгырарга тотына") укучыга җиткерергә ярдәм итә.

Психологик кичерешләрне җиткерү юлында автор табигать күренешләреннән дә уңышлы файдалана. Романда еш кабатланып торган Гөлшәһидәнең кыр казлары тавышын ишетеп сихерләнүе ("Көн аяз, күк йөзе чип-чиста. Шушы саф зәңгәрлектә кыр казлары озын муеннарын сузып очып баралар. Уйсурак җирләрдән әле эрегән кар исе аңкый, үрләр өстендә җиңел рәшә тирбәнеп тора. Язның сихерле авазлары белән тулы шушы киң кырда кыр казларының һични белән чагыштыргысыз моңлы җырлары Гөлшәһидәнең күңелен әсәрләндерде"), Айның, кояшның болытлар белән каплану күренеше, яңгырлы-яшенле яңгырның тынып калып, табигатькә тынлыкның иңүе кебек табигать сурәт**е,** аның күңел кичерешләрен, эчке дөньясындагы үсеш-үзгәрешләрне ачу белән берг**ә,** рухи чисталыгына, "табигать баласы" булуына да басым ясый. Г.Әпсәләмовның Гөлшәһидә, Мансур образларын сурәтләү барышында портретның психологик портрет төренә ешрак мөрәҗәгать итүе дә психологик кичерешләрне тирәнәйтү максатына йөз тота. Бу геройлар язмышы укучыда бер фикерне ныгыта: кеше көрәш һәм сабырлык аша гына үз бәхетенә ирешә ала.

Врачлар, медицина хезмәткәрләре тормышын яктырткан, алар белән бәйле вакыйгаларны бер бәйләмгә туплаган реалистик сызыкта конфликтның эчке каршылык, тышкы каршылыклардан герой – герой кебек формалары чагылыш таба. Әбүзәр Гиреевич, Мансур,

Гөлшәһидә / Фазылҗан, Сәлах Саматовлар каршылыгы кешеләр яшәешенә, алар арасындагы мөнәсәбәтләргә бәйле сыйфатларны аерып чыгарырга һәм автор позициясен төгәлләштерергә ярдәм итә.

Романда геройлар соцреалистик әсәрләрдәге кебек капма-каршы ике төркемгә җыела һәм яхшылык – яманлык оппозициясе тирәсенә туплана. Гөлшәһидә, Мансур, профессор Әбүзәр Таһиров, Диләфрүз, Юматша кебекләр оппозициянең бер ягына карый, аларның эш-гамәлләрендә дә, эчке дөньяларында да яхшылык кылу сыйфаты калкып чыга, Фазылҗан Яңгура, Илһамия, Сәлах Саматов, Клавдия Сергеевна кебекләрнең гамәләрендә дә, күңелләрендә дә яманлык әйдәп бара. Уңай геройлар буларак бирелгән Таһиров, Гөлшәһидә, тискәре герой – профессор Янгура – медицинада, врач хезмәтенә мөнәсәбәттә капма-каршы позицияләрдә торган кешеләр буларак алга чыгалар. Шушы катламда сурәтләнгән сыйфатлар, күтәрелгән проблемалар врачларның хезмәткә мөнәсәбәтенә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә тәнкыйди бәя булып формалаша.

Бу катламдагы төп каршылык Әбүзәр Гиреевич белән Фазылҗан, ягъни дөньяга төрле карашлы шәхесләр арасында бара, Мансур, Гөлшәһидә, Юматша, Сәлах Саматов, Клавдия Сергеевна кебек күп кенә геройлар йөзендә кабатлануы проблемаларны тирәнәйтә, калкуландыра. Таһировның Фазылҗан Яңгура белән каршылыгы врачлар тормышында хөкем сөргән ялганны, үз эшенә салкын мөнәсәбәт, бюрократлык, хәйләкәрлек, мин-минлек мәсьәләләрен ачып бирсә, Гөлшәһидә белән Яңгура, Сәлах Саматов мөнәсәбәтләре икейөзлелек, астыртынлык, үз эшенә салкын мөнәсәбәт, эчке бушлык кебек сыйфатларны кешеләр тормышын түбәнгә тартучы көчләр дип чаң суга, Мансур белән Фазылҗан каршылыгы бу проблемаларны тагын да тирәнәйтеп, кешенең үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртуын, аны бердәнбер хакыйкать дип раславын, тар күңеллелек, эгоизм, көнчелек сыйфатларын ачып бирә, кеше белән җәмгыять, яшәеш идеаллары арасындагы аерымлыкны ассызыклый. Әнә шулай иҗтимагый эчтәлекле проблемалар гомумкешелек мәсьәләләренә үрелеп китеп, медицина эшчеләре тормышына тулы, төрле яклы бәя туа. Бу проблемалар бергә кушылып, тәнкыйди башлангычны да формалаштыралар. Үз бәяләрен тулыландыру юлында автор метафоралардан уңышлы файдалана. Мәсәлән, “бик зур буалар була. Су өсте көзге кебек шоп-шома, тып-тыныч, гүя ул юаш, күндәм. Улагын ачсалар, гөрләргә тотына, тегермән ташларын, турбиналарны

әйләндерә, улагын япсалар, тагын тынып кала һәм мәңге шулай буйсынучан булып яшәр төсле. Әмма тәҗрибәле гидролог аның эчендә кайнаган “ачуын” сизә, аның колагы кайдадыр төптә бөтерелгән дулкыннарның ярсу гөрелтесен ишетә” күренеше, метафора буларак, Фазылҗанның яшәү рәвешен генә түгел, аның кебек күпләрнең эчке дөньясын ачарга, тормыш позициясен төгәлләштерергә мөмкинлек бирә.

Аларның караңгы якларын тагын да көчәйтү, тирәнәйтү барышында автор идеаллаштырылган геройларга мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә Гөлшәһидә, Әбүзәр кебек үзенчәлекле геройлар әдәби мәйданга чыга. Бер яктан Гөлшәһидә - Табигать тарафыннан бүләк ителгән табигый хискә буйсынып, Мәхәббәткә омтылучы, яратырга, яратылырга теләп яшәүче, Туган җиргә, Яхшылыкка, Табигатькә, Хакыйкатькә табынып яшәүче. Әсәр үзәгенә аның нәкъ менә әлеге теләкләре, хис-кичерешләре, ышану-омтылышлары куелу әсәрне бүгенге укучы өчен дә кызыклы итә, тәэсир көчен арттыра. Ләкин шуның белән янәшәдә ул – хезмәт кешесе, совет чоры идеаллары белән яшәүче, аларны тормышка ашыру юлында армый-талмый эш-гамәлләр кылучы, бу яктан Галияләрнең (Гадел Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар”) дәвамы да. Экспозиция өлешендә үк Г.Әпсәләмов аның белән “Гөлшәһидә башын гадәттәгедән югарырак тотып, дөньяга күзләрен зур итеп ачып карап, агач баскычтан су буена төште, дамба буйлап Кремльгә таба китте. Троллейбуста да, аннары трамвайда да керфекләрен түбән төшермәде”, - дип таныштырып куя, кызның холык-фигыль сыйфатларына ишарә ясый. Әлеге портрет ук аның дөньяга туры карауучы, сер бирмәс шәхес булуын шәрехләп куя, вакыйгалар агышында да әлеге сыйфатлар ассызыкланып бара.

Үз эшенә табынып яшәүче профессор Әбүзәр Гиреевич Таһиров образы да шушы схемага утыртып иҗат ителә. Идеягә инануы ягыннан ул “Сүнмәс утлар”дагы Сөләйман Уразмәтовның дәвамы кебек кабул ителә. Вакыйгалар хикәяләүче исеменнән сөйләнелә, автор образы әсәр тукымасында турыдан-туры чагылыш тапмый. Әмма аның медицина хезмәткәрләренә, мәхәббәткә карата шәхси позициясе әледән-әле әйттерелә тора, язучы аларны Әбүзәр фикерләре, бәясе аша җиткерә. Аның “Врач үзе өчен генә яшәми, ул барыннан да элек башкалар өчен яши! Үз кайгысы чыдый алмаслык булса да, аның җебергә хакы юк. Ул бөек артист булырга тиеш!” кебек әсәр тукымасында даими кабатланып торган фикерләре, тормыш

позициясе, яшәү рәвеше авторның да врач намусы, аклыгы турындагы уйланулары, фикерләре булып төгәлләшә. Шуңа бәйләп, врачлар тормышының формуласы, теориясе ачыклана: ул даими кешеләр тормышы хакына яшәргә тиеш, кешелекнең киләчәге алар кулында.

Үз идеясен җиткерү барышында автор тагын да уңышлырак юлны сайлап, ак чәчәкләр образына мөрәҗәгать итә. Көчле позициягә – әсәр исеменә үк чыгарылган әлеге образ вакыйгалар агышында күпмәгънәле символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Бер яктан ул врачлар, кеше гомере өчен көрәшүче медицина хезмәткәрләре буларак аңлашыла, икенче яктан, аның аклыгы Әбүзәр, Гөлшәһидә, Мансур, Юматша, Диләфрүз кебекләрнең күңел аклыгына, тормышларындагы якты идеалларына аваздаш яңгырый, өченче яктан ул рухи югарылыкка ирешү символы булып укыла. Шул рәвешле, романда кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләргә, врачлар тормышындагы хезмәткә табынуга нигезләнгән тормыш фәлсәфәсе татар укучысына якын лирик-эмоциональ дулкында тәкъдим ителә. Язучының моннан соң язылган “Яшел яр” (1968) романы, “Идел хикәяте” (1971) повестьлары да шушы дулкынны дәвам итә.

Әдәби иҗат эшеннән тыш Г.Әпсәләмов татар әдәбиятын дөнья киңлекләренә чыгарган, аның дөньякүләм танылуына өлеш керткән әдип буларак билгеле. 1940-1983 еллар арасында татар, рус телләрендә, СССР һәм чит ил халыклары телләрендә әдипнең йөзгә якын китабы дөнья күрә. Г. Әпсәләмов үзе дә тәрҗемә эше белән актив шөгыльләнә: А. Гайдарның «Тимур и его команда» («Тимур һәм аның командасы», 1941) повестен, Э. Казакевичның «Весна на Одере» («Одерда яз», 1951), А. Фадеевның «Молодая гвардия» («Яшь гвардия», 1950, 1956) романнарын һәм В. Короленко, Н. Лесков, Д. Мамин-Сибиряк, А. Новиков-Прибой, М. Пришвин, Н. Тихонов кебек күренекле рус язучыларының хикәя китапларын татар теленә тәрҗемә итә. Актив иҗат эше белән шөгыльләнгән әдип, гомеренең соңгы көннәренә кадәр каләмен кулыннан төшермичә, 1979 нчы елның 7 февралендә Казанда вафат була.

Г.Әпсәләмов иҗаты иң олы һәм гадел хөкем саналган вакыт сынавын узды. Әдипнең Газинур язмышына бәйләп сугыш чорын тасвирлаган «Газинур» (1951), көчле шәхес концепциясен тәкъдим итеп, кешене мәңгелек кыйммәт югарылыгына күтәргән “Мәңгелек кеше” (1960), медицина хезмәткәрләре тормышын гәүдәләндереп, бүгенгәчә популяр булган «Ак чәчәкләр» (1966), мәктәп, укытучылар

тормышын һәм хезмәтен мәхәббәт, әхлак проблемалары белән бәйләнештә сурәтләгән «Яшел яр» (1968) һ.б. романнары, сугыш чоры яшьләренең эчке дөньясын, теләк-максатларын сурәтләү объекты иткән «Миңа унтугыз яшь иде» (1968), һәвәскәр рәссамның рухи кичерешләрен укучыга җиткергән «Идел хикәяте» (1971) повестьлары, дистәләрчә хикәяләре, очерклары, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, публицистик язмалары һәм истәлекләре Г. Әпсәләмов иҗатының киң кырлы, күп катламлы, жанр төрлелеге һәм тема ягыннан гаять бай булуын раслый. Аларның барысын да бер максат – хезмәт һәм сугыш кырында замандашларының теләк-омтылыш, хыялларын, батырлыгын, эчке дөньяларын ачу, заман героен сурәтләү бер бәйләмгә туплый, шул яктан аның әсәрләре үткән XX гасыр тормышының иҗади елъязмасы булып укыла һәм әдәби мирасның бер хәзинәсен тәшкил итә.

**Текст:**


1. Әпсәләмов Г. Ак чәчәкләр /Әпсәләмов Г.Сайланма әсәрләр. 5 томда. Т.1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. –350 б.


**Төп әдәбият**


2. Гайнуллина Г.Р., Юсупова Н.М. Кереш сүз / Габдрахман Әпсәләмов. Сайланма әсәрләр. 5 томда. Т.1.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.– Б.7-29.
3. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.


**Өстәмә әдәбият**


4. Бәширов Г.Әдәби осталык турында // Совет әдәбияты, 1952.– №1.– Б.89-97.
5. Габдрахман Әпсәләмов // Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек / Төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. – Б.99-101.

## Тема: 1960-70 елларда татар прозасының яңартылган реализмга борылуы. Авыл прозасы агымы( Р.Төхфәтуллин, М.Мәһдиев)

1970 еллар чигендә СССР дип аталган территориядә яшәүче халыклар әдәбиятында социалистик реализм кысаларына сыешмаган әсәрләр күпләп языла. Милли һәм әхлакый кыйммәтләргә ия буларак авыл кешесен, җирдә эшләүчене сурәтләгәнгә, авыл реализмы дип атала башлый. Крестьян (авыл) реализмы шартлы рәвештә агым атамасы булып китә. В. Овечкинның «Район көнкүреше» (1952), Е. Дорошның «Авыл көндәлеге» (1954—1962) язмаларында, Ф.Абрамовның «Сугыштан соңгы прозада колхоз авылы кешеләре» дигән программ мәкаләсендә (1954), «Абыйлар һәм апалар» романында (1958 елда басыла), В. Астафьевның беренче хикәяләрендә формалаша. А. Солженицынның «Матрена ишегалды» (1959), «Иван Денисовичның бер көне» (1962), В. Беловның «Күнегелгән эш» (1966), В. Астафьевның «Саубуллашу» (1957—1992), «Патша-балык» (1972—1975), В. Шукшинның «Кызыл балан» (1973), В. Распутинның «Соңгы срок» (1970), «Матера белән бәхилләшү» (1976) әсәрләре авыл реализмы кысаларында иҗат ителгән.

Авыл прозасы җир кешесенең көндәлек тормышын сурәтли, әхлакый кыйммәтләрне, гадәт-традицияләрне югары күтәрә. Гомумән, бу агымның традицион әхлакый кыйммәтләрне әдәбиятка кайтаруы иң төп сыйфатлардан санала (А. Солженицын алар-ны «әхлакчылар» дип атый). Кешенең рухи дөньясын, фикер һәм хисләр байлыгын үзәккә куеп, әхлакый кыйммәтләрнең югала баруына ачынып, әлеге хәлдән чыгу юлларын барлап язылган әсәрләр совет әдәбиятын иҗтимагый яссылыктан – кешегә, югары кыйммәт буларак кешене сурәтләүгә юнәлтә.

Бер үк вакытта агым социалистик реализмнан капма-каршы чиккә ташлану кебек тә кабул ителә. Шәһәр тормышын, мәдәниятен кире кагу, бары тик авылда гына чын тормыш бар дип санау, авылны халыкның рухи нигезләре сакланган урын итеп изгеләштерү күзәтелә. Илне тергезү, кешене рухи һәм әхлакый яктан таза-саф килеш саклау учагы итеп нәкъ менә авыл карала. Авыл реализмына хас сыйфатлар:

– Авыл тормышын чынбарлыкка охшатып, детальләрдә сурәтләү, авылны рухи байлык сакланып калган урын дәрәҗәсенә күтәрү;

– эшче сыйныфны идеаллаштыру урынына крестьян сыйныфын тарихи һәм эстетик идеал дип белдерү, тирә-юньнән дошман эзләү

атмосферасын тергезү;

– гади, гадәти сөйләмгә лирик пафос бирү, гадәтине мәңгелек символлар ярдәмендә бәяләү;

– интернационализм урынына милли идея белән чыгыш ясау, үткәнне мактау;

– үткәндәге әхлакый кыйммәтләрне, халык традицияләрен югары күтәреп, укучыны да шул йола-гадәтләр белән мөмкин кадәр тулырак таныштырырга омтылу;

– шәһәр тормышын тәнкыйтьләү, иҗтимагый кануннарны шик астына алып, табигый кануннарны дөрес санау;

– җир кешесе, кечкенә кешенең бай рухи дөньясын, хисләр төрлелеген, характерын ачарга омтылу һ. б.

Авыл прозасы татар әдәбиятына 1960 елларда үтеп керә. Бу агым татар авылы хакында сөйләүне үзәк тема итеп күтәрә, җәмгыятьтәге барлык проблемаларны җир кешесе язмышына тоташтыра. Язучылар авыл хуҗалыгындагы кыен хәлне тулырак һәм дөресрәк гәүдәләндерергә, авылда барган иҗтимагый-психологик процессларны тирәнрәк чагылдырырга омтылалар. Торгынлык елларында ук бу агымга ияреп язылган әсәрләр, колхоз төзү вакытындагы кимчелекләр, «кулак» исеме астында кешеләрне читкә сөрү яки күчерүнең ялгышлыгы мәсьәләләрен үзәккә алып, авылдагы тәртипләр хакында сөйләгәндә, системаның аерым хаталарын да күрсәтәләр. Язучылар гади татар авылы чынбарлыгын бөтен ил тормышы белән бәйләп карыйлар. Шунлыктан авыл прозасына төп герой итеп җир кешесе, гади крестьян сайлана, уңай герой идеал дәрәҗәсенә күтәрелә. Аның, бөтен көчен куеп, колхозны аякка бастыру өчен көрәшүе, җәмгыять мәнфәгатьләрен шәхси бәхеттән өстен санавы тасвирлана. Авыл реализмы татар әдәбиятына халыкчан характерлар, милли әхлак традицияләрен, кабатланмас җанлы сөйләмне кайтарды. Халыкның рухи тамырлары, мәдәнияте сакланган урын буларак авылны күтәрү аның үз йөзен югалта баруына бәйле үкенеч, сагыш белән өртелде. Үткәнне сөйләүче агым күпмедер күләмдә шуңа бүгенгене һәм киләчәкне каршы куйды. Татар әдәбиятында А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» (1974), «Берәү» (1965); Р. Төхфәтуллинның «Авылдашым Нәби» (1963), «Йолдызым» (1962); Н. Фәттахның «Артта калган юллар» (1965); Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» (1967); В. Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» (1968), «Күпер чыкканда» (1971), «Аккан су юлын табар» (1979); С. Рәфиковның «Авыл иртәсе»

(1966), Г.Ахуновның «Чикләвек төше» (1971), Б. Камаловның «Күңел кыңгыраулары» (1971), «Ялыкмаслар» (1972) һ. б. күп кенә әсәрләр шушы агым таләпләренә җавап бирә. Кайберләрендә яшьләрнең күпләп авылдан китүе, хезмәт кешесенең кадере булмау кебек күренешләр милләт язмышы хакындагы уйланулар белән үрелеп китә. Лирик, юмористик башлангыч әсәрләрнең тәэсирлелеген арттырырга мөмкинлек бирә. Соңрак, 1970 еллар ахырына, авыл темасына мөрәҗәгать иткән әсәрләрдә шул заман авылындагы әхлакый проблемалар, кеше психологиясе калку күрсәтелә башлый, тәнкыйди башлангыч көчәя. Моңа мисал итеп, А. Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән...» (1979), «Әтәч менгән читәнгә» (1980); М. Мәһдиевнең «Каз канатлары» (1976), «Исәнме, Кәшфи абзый» (1983); Ә.Баяновның «Тау ягы повесте» (1972) һ. б. күп кенә әсәрләрне китерергә була. Татар әдәбияты крестьян реализмы чикләрен уза.

Р.Төхфәтуллинның «Йолдызым» (1962) повестен татар прозасында яңартылган реализм агымына юл салучы әсәр дип әйтеп була. Повестьта вакыйгалар якынча 1939нчы елдан башланып китә һәм 50 нче елларга кадәр вакытны колачлый. Әсәрдә төп сюжет сызыгы Гөлзифа һәм Мортаза каршылыгына корылган. Гөлзифа авыл мәнфәгатьләрен кайгыртучы образ буларак күтәрелә. Ул үзен-үзе аямыйча колхозны алга җибәрү өчен бар тырышлыгын бирә. Ә Мортаза исә үзе өчен яши, байлык туплау өчен төрле әхлаксызлыклар юлына баса. Гөлзифа һәм колхоз председателе Мортаза арасында барган кискен каршылык авыл мәнфәгатьләрен яклаучылар белән үз мәнфәгатьләрен кайгыртучылар арасындагы каршылык буларак тамгалана. Гөлзифаның пот ярым бодай мәсьәләсен тыңлап тору вакыйгасы сюжет сызыгында төенләнеш булып тора. Гөлзифа үз колаклары белән ишеткән, үз күзе белән күргән вакыйга турында сөйләргә районнан килгән Хәмдиев янына бара. Ләкин файдасыз. Колхоз җыелышында төп урын авыл мәнфәгатьләрен кайгыртучыларга бирелә. Гөлзифа, Җиһангир, хәтта гади сыер савучы Асия дә җыелышта үз сүзен торып әйтә ала. Димәк, авыл мәнфәгатьләрен кайгыртучылар саны арта, авыл үзгәрә.

Повестьта ярдәмче сюжет сызыкларын да аерып карау мөмкин. Беренче ярдәмче сюжет сызыгы булып Гөлзифа белән Давыт мөнәсәбәтләре тора. Гөлзифа — эш кешесе. Ул хезмәт өчен, авыл тормышын алга җибәрү өчен эшли, яши. Давыт – шәхси мәнфәгатьләренең колы. Аларның икесенең дә уртак теләкләре бар.

Ул – белем алып, Гөлзифа агроном, Давыт инженер булып, мул, рәхәт тормышта яшәү. Ләкин үз мәнфәгатьләренә ирешү юлларын алар икесе ике төрле күрә. Гөлзифа үз теләк-омтылышларын авыл белән бәйләсә, Давыт шәһәр тормышындагы уңайлыкка кызыга. Гөлзифа өчен бәхет – олы хезмәт нәтиҗәсе, Давыт бәхетле тормышны бәхетле очрак кебек аңлый, җаваплылык тоймый. Күргәнебезчә, алар арасындагы төп бәхәс – максатка ирешүдә юллар сайлауга бәйле килеп чыга. Беренче ямьсез төнне сурәте – ир белән хатын арасында мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе тасвиры. Давыт ул төнне бик соң кайта, Гөлзифага да «ничектер мескенләнебрәк» карый: «...Закон! Закон аларның үз кулында... Әйтәм ич, янәсе, мин эмтыес штатындагы механизатор түгел, мин прицепщик та ярдәмче комбайнчы гына. Ә кем ярдәмче, кем төп эшләүче булгандыр, аларның анда ни эше бар? Закон... Сиңа да тапканнар инде алар законны. Колхоз, тулаем алганда, план-йөкләмәләрен үтәп бетермәгән, шуңа күрә сиңа да өстәмә түләү тиеш түгел. Шулай ук күпмедер аванс алгансың, күпмедер ашагансың, шуңа хәер-доганңы укып битеңне сыпыр да моннан ары теш арасына кыстырмыйча да тук булырсың... Чабата башын ничә юкәдән үрәләр әле аны, Әптери агай, дип әйтте ди берәү...»–дип ачынып сөйли. Ул авырлыкларга, авылда хөкем сөргән хаксызлыкка түзә алмый, һаман да шәһәргә китү нияте белән яши. Шәһәрнең бай, рәхәт тормышына кызыга. Шунда икенче хатын янына китә. Аның шәһәргә китүендә Гөлзифадан үч алу нияте белән яшәүче Мортазаның да кул сузуы мәгълүм.

Димәк, икенче ярдәмче сюжет сызыгы Давыт белән Мортаза арасындагы каршылыкка корыла. Давыт та үз гаебен таный, Гөлзифадан гафу үтенергә килә. Ләкин Гөлзифа гафу итми.

Өченче ярдәмче сюжет сызыгы итеп Мөнир белән Гөлзифа мөнәсәбәтләре тора. Мөнир дә, Гөлзифа да авыл мәнфәгатьләрен кайгыртучылар итеп бирелә. Алар бер-берсенә ышаналар, бер-берсендә ышанычлы, чын, авыр чакта ярдәм кулы сузарга торырга әзер дусны күрәләр. Дүртенче ярдәмче сюжет сызыгы Җиһангир һәм Гөлзифа мөнәсәбәтләрен иңли. Җиһангир Гөлзифага гашыйк. Ләкин бу берьяклы гына, җавапсыз мәхәббәт. Шулай да Җиһангир бирешми, сөйгән ярына берсеннән- берсе матур бай эчтәлекле хатлар яза. Әлеге хатлар Гөлзифага да авыр минутларда рухи яктан сынмаска ярдәм итәләр. Шул рәвешле, автор фикеренчә, авылны, җирне үз-үзен

аямыйча хезмәт итүчеләр, авыл мәнфәгатьләрен кайгыртучы, хезмәткә ачык чырай белән караучылар яшәтә.

Әсәрнең тәнкыйди катламында ил белән идарә итү системасындагы кимчелекләр авыл тормышында хөкем сөргән кимчелекләр аша яктыртыла. Р.Төхфәтуллин Мортаза белән Хәмдиев мисалында җинаятьләрнең тиешле җәза алмавын күрсәтә. Хәмдиев тагы да югарырак урынга утыра, Мортаза исә, тире сату эше белән шөгыльләнә башлый. Үз мәнфәгатьләрен кайгыртучыларны автор Сәгый образында күрсәтә. Реалистик әсәрдә лирик катлам әсәрнең тәэсирлелеген арттыра. Мөнир белән Гөлзифа образларын автор идеаллаштып бирә. Мөнир Гөлзифада теләктәшлек күрә, ул аңа ярдәм итеп тора. Мөнир, Гөлзифа шикелле үк, романтик образ. Мөнир фронт истәлеге итеп ак бияләй саклый. Бу бияләй аның күңелендә саф, чиста хисләрне саклый. Нечкә күңелле, хыялланырга яратучы Мөнир бияләйдәге «Д.Г.» язуын төрлечә юрап карый. Гөлзифа, бернигә карамастан, Давытны ярата, аңа карата туган саф, чиста мәхәббәт аның күңелендә гел яши. Лирик катламны көчәйтү өчен автор әсәр ахырына өянкедәге тамга детален урнаштыра, Җиһангир сызыгын кертә. Повестьта Гөлзифа мисалында кеше кыйммәте асызыклана, автор Гөлзифаның авыл җире өчен йолдыз булуын күрсәтә. Романтик герой буларак билгеләнгән Гөлзифа, Мөнир һәм Җиһангир образлары соцреализмның уңай герой концециясенә туры килә.

Символ, билге һәм әдәби деталь әсәрдә зур урын биләмәсә дә, ул җаваплы вазифа – идеяне яктырту, ачыклау, характерларны тирәнрәк, тулырак ачу функциясен башкаралар. Эмоциональ тәэсирне көчәйтү хезмәтен дә үти. «Йолдызым»да билгеләр булып өянке, миләш агачлары, Давыт сөяркәсе түшендәге зөбәрҗәт брошка, Давытка дип бәйләнгән, ләкин Мөнир кулына килеп эләккән ак бияләй тора. Символ булып исә, йолдызны күрсәтергә мөмкин. Гөлзифа өчен кызы Йолдыз караңгы тормышын яктыртучы, җир өчен Гөлзифа үзе йолдыз.

М.Мәһдиевнең “Кеше китә, җыры кала” (1958-1968) повесте да авыл реализмы агымына нисбәтләнә. Вакыйгалар тарихи вакытта сугышка кадәр, сугыш вакытында һәм сугыштан соң бара. Хронотоп өч төрле: иҗтимагый, психологик, субъектив. Иҗтимагый хронотоп ярдәмче геройлар аша шул дәвергә бәя бирүне күздә тота. Психологик хронотоп - Шәйхи, Шәяхмәт, Хәкимулла, Нургали, Васфикамал,

Хисмәт, Миңлегали, Заһри һ.б.ның язмышлары, шәхси кичерешләре. Мәһдиев әсәрләренә хас булганча, төп герой – хикәяләүче үзе, аның кичерешләре субъектив хронотопны тәшкил итә. Вакыйгалар үткәннән бүгенгегә һәм киләчәккә даими рәвештә күчеп тора. һәр геройның яшьлеге, бүгенгесе күздән кичерелә, алар һәрберсе ярдәмче сюжет сызыгы булып тора. Сюжет сызыкларын берләштерүче үзәк булып хәсрәт мотивы тора. Күз яшьләре мотивы хәсрәт мотивын тулыландыра. Повестьта бу мотив Миңлебикә урынына килен булып килергә мәҗбүр булган Васфикамал елавы, аның әнисе Ташлытау кодагый елавы, сугыш башлангач Васфикамал елавы, үзенең ялгышын аңлаган Нургали күз яше, Рәмзиянең үлеменә сәбәпче булган улының хәсрәтеннән Шәяхмәт елавы, бердәнбер улы Миңлегалинең үлем хәбәре килгәч, сугыштан ярым үле килеш кайткан Хәкимулланың сыңар күзеннән тамган күз яше, Фәхернисаның күз яше, Чуар бабай каберен мәсхәрәләргә тотынган Улибаеваны каһәрләп Васфикамал елавы кебек кабатлана. Повестьта кешелекнең гап-гади кануны нәсел калдыру тиешлеге турындагы фикер алга сөрелә, шуңа күрә хәсрәт мотивы өйләнү, кияүгә бару вакыйгаларында да кабатлана. Шәяхмәт, Хәкимулла, Шәйхи өйләнүе, Васфикамал, Миңнисаларның кияүгә чыгуы, Нургали хәсрәте өй бурасындагы әйләнмәле бер бүрәнә образы аша символлаштырыла. Шәяхмәт өйләнергә тели, ләкин ул сайлаган кыз барырга теләми һәм мулланы коткарып кына кияүгә чыга һәм ике-өч атнадан кайтып китә. Сугышта ире үлгән солдаткага өйләнергә мулла белешмәсе булмаганга ризалык бирми. Бу вакыйгалар улы Хәкимулла өйләнгән вакытта да кабатлана. Ветсанитар Хисмәт кызы Миңниса "уҗым бозавы" Хәкимулладан качып китә. Ташлытау кызы Миңлебикәне урларга барган җиреннән Хәкимулла Васфикамалны урлап кайта. Миңлебикә белән Васфикамалны да уртак хәсрәт берләштерә. Миңлебикәнең Кара Чыршы авылына кияүгә китәсе килми, Васфикамалны ат карагы кызы булганга сөйгән яры урындагы кеше Нәбиуллин ташлап китә. Васфикамал Миңлебикә белән килешеп кияүгә бара. Шәйхи карт кызы белән сөйләшеп торганда тәһарәт алырга чыккан хуҗабикәне куркыта. Икенче тапкырында фонарь тотып чоланга кергән Шәйхинең эшен кызның әнисе боза. Сугыш вакыйгасы авылдагы һәр өйгә хәсрәт алып килә. 44 яшьлек Хисмәт туганнары өчен билгесез рәвештә һәлак була. Хәкимулла аны күмсә дә, ярым үле кайткан хәлдә авылдашының исән түгеллеге хакында хәбәр итә алмый Җиңү иртәсендә үлеп китә. Нәтиҗәдә Хисмәт

туганнары өчен хәбәрсез югалган булып кала. Мәйсүфә бер уч он алып кайтканы өчен Улибаева тырышлыгы белән халык дошманы буларак башта Пановкага җибәрелә, аннары хәбәрсез югала. Тол үстергән бердәнбер улы Миңлегалинең үлем хәбәре килгәч Фәхерниса Хәбирә карчыкка Коръән ачтыра. Әсәрдә үлем образы козгын символы аша көчәйтелә. Нургали хәсрәте башка рухтарак. Шук Нургалине сугыш үзгәртә. ФЗӨ мәктәбеннән качып кайткан Нургали ата-анасын кара хәсрәткә сала, Рәмзиянең үлемендә гаепле булуы аны бөтенләй үзгәртә һәм ул сугышка китеп батыр булып әйләнеп кайта. Заһри хәсрәте дә юлдан тайпылган авыл кешесенең борчуы. Ат карагы Заһри Кара Чыршыга күчеп утыра. Хәбирә карчык белән киңәшләшеп, исәнлегенә зыян китереп, сугыштан кала. Ләкин үләр алдыннан үкенә, намазга баса. Улы Әхмәтзариф әтисен күмәргә кайтуны кирәк санамый. Әсәрдә мәзәк хәлләр халыкның үз хәсрәтенә ирония аша бәя бирүенә ишарә итә. Өйләнү вакыйгаларын мәзәк итеп сөйләү, Шәйхинең яшьлегеннән күренешләр һ.б. әсәрдәге ироник модус, юмористик пафосны билгелиләр. Әсәрдә мифологик катлам да урын ала. Бу яктан Чуар бабай кабере турында сөйләнгән өлеш үткән-бүгенге-киләчәкне тоташтыра. Бу өлеш сакраль мәгънәдә мәңгелек кайту мотивына туры килә. Әсәрдә зират образы яшәү-үлем мотивына ишарә итә. Әсәрнең Нәриман-Зөлфия туе маҗаралары нәселнең дәвам итүенә, Шәйхи картның чардуганы сакланмаса да, җыры саклануына ишарә итә. Басуның зиратка тоташуы яшәү мәгънәсе, аралыгы турында искәртә.Шәйхи карт шулай ук сакраль миссия башкара. Гаиләдәге төрле хәлләрдә зирәк киңәшләре белән ярдәм итү (Васфикамал-Хәкимулла вакыйгасы), авылдагы хәвеф-хәтәр турында хәбәр итү (ул каланчада эшли), Җиңү хәбәрен аның таратуы символик мәгънәгә ия

**Текстлар**

1. Мәһдиев М. Кеше китә – җыры кала / Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. 3 тода. III том: Повестьлар, роман. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1996. – Б.253-569.

2. Төхфәтуллин Р. Йолдызым / Төхфәтуллин Р. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшр. (ТаРИХ). – Б. 109-310.

**Төп әдәбият**

1. Галиуллин Т. Кояшлы иҗат / Шәхесне гасырлар тудыра: Әдәби тәнкыйть, хикәяләр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2003.- Б.39-60.

2. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

**Өстәмә әдәбият**

3. Давлетшина Л.Х. Мифологизм в татаркой прозе конца XX – начала XXI в.в. – Казань: РИЦ «Школа», 2006.– С. 86-87.

## Тема: XX гасырның 70 нче елларында тарихи роман жанры үсеше (Н.Фәттахның “Итил суы ака торур”, “Сызгыра торган уклар” романнары)

Тарихи вакыйгалар халыкның үзендә дә, башка халык язмышында да кабатланалар. Җәмгыятьнең ниндиендә генә яшәсәләр дә, халыклар үз дәүләтләрен, ә аңа кадәр ыруларны ныгытырга тырышалар. Ыруларны һәм дәүләтләрне берләшеп, уртак тел табып та, башка халыкларны яулап, алар исәбенә ныгытырга да мөмкин. Бер-берсенә каршы булган ике теләк, хакимият өчен көрәш рәвешен алып, тарихның буеннан буена сузыла. Тарихның шул рәвешле кабатлануы язмышлары билгесез булган халыкларның язмышын өйрәнүгә ярдәм итә. Н.Фәттах шулай иткән дә: ул үзенең хыялын шундый фәнни нәтиҗәләргә буйсындырган.. Фәнни нәтиҗәләре – тарихта армый-талмый эзләнү нәтиҗәсе. Әдип тарихи роман жанрын гына түгел, татар романын яңа баскычка күтәргән язучы буларак әдәбият тарихына кереп кала. Әдип совет чоры татар прозасы кысаларында тәүге язучы буларак борынгы тарихны әдәби чагылдыру юлына аяк басты. Икенчедән, тоталитар режим шартларында әлеге факт милли дәүләтчелек тамырлары турындагы мәсьәләне кыю рәвештә сәнгать югарылыгына күтәрү. Өченчедән, татар прозасында борынгылыкны бәян итүдә тарихи чыганакларның һәм фәнни ачышларның әдәби ижат өчен нигез булуы гамәли расланды.

Язылу тарихы, романны язуга этәргеч, төп тарихи чыганак булган факторларны әдип үзе болай тасвирлый: “Хәзерге заман темасына язучыга барыннан да элек бүгенге тормыш тәэсир итсә,

тарихи темага язучыга китап, язма әдәбият тәэсир итә дисәк, ялгыш булмас дип уйлыйм. Тарих бит ул үзе китап. Мин беркайчан да тарихи романнар уку белән мавыкмадым һәм тарихка мәхәббәт уянуда тарихи романнарның бернинди роле булмады дияргә мөмкин. Миңа бик нык тәэсир иткән беренче тарихи китап «Кабуснамә» булды, ахрысы. «Кабуснамә» XI гасырда яшәгән чын кешенең чын язмалары. Икенче китап итеп мин Усама ибне Мункызның «Үгет-нәсихәт китабы»н («Книга назидания») күрсәтә алам. Усама ибне Мункыз, Сурия гарәбе, тәре сугышлары вакытында яшәгән, бик күп сугышларда катнашкан. Өченче китап итеп «Исландия саголары»н атап әйтәсем килә. Әйтәсе килгәнем шул: миңа үткән заманның үз кешеләре язып калдырган чын фактлар, чын вакыйгалар «беренче этәргеч»ләрнең берсе булды. Бу урында мин атаклы ибне Фазлан язмаларын укуымны һәм үземнең 1957 елда Болгар хәрабәләрен казуда катнашуымны да искә алмасам, «беренче этәргеч»ләр мәсьәләсе тулы булмас дип уйлыйм. Ибне Фазлан язмаларын уку, өйрәнү, ятлау һәм җирдән казып алынган болгар әйберләрне үз кулларым белән тотып карау – болар барысы да, әлбәттә, беренче, иң беренче этәргечләр булгандыр. Болары күреп, тотып була торган «этәргеч»ләр. Ләкин «этәргеч»ләрнең күреп, тотып булмый торганы да бар. Анысы – мәхәббәт. Туган халкыма, туган телемә, культурама чиксез мәхәббәт тойгысы. Бу тойгы беренче дә, икенче дә тугел, ул – төп этәргеч, даими этәргеч. Иң беренче чыганак  ибне Фазлан язмалары булды. Моннан тыш, борынгы Болгарга, аның күршеләренә караган башка хезмәтләр белән танышып чыктым".

Романның тарихи чынлыгы авторның үзе тапкан фәнни нәтиҗәләренә нигезләнсә, вакыйгаларда катнашкан персонажлар чынлыгы аларның кичерешләрен дәлилләү нәтиҗәсенә бәйле. Тарихның ерак чоры турында ни язсаң да ярый, үткән заман әдипләрне дә, тарихчыларны да җавапка тартмый. Шулай булса да, Н.Фәттах болгарларның чиксез батырлыкларын күрсәтү кебек бик отышлы вакыйгалар язу белән мавыкмаган. Батырлык көчтә дә, гайрәттә дә, куркусызлыкта да түгел, сабырлыкта, ди. Зирәклекнең бер нәтиҗәсе буларак сабырлык борынгы бабайларның иң күркәм сыйфатлары итеп гәүдәләнә.

Р. Салихов  Н.Фәттахны татар әдәбиятында беренчеләрдән булып яңа тарихи герой концепциясен тәкъдим иткән язучы дип билгеләп

үтә. Яңа герой – ерак гасырлар төпкеленнен кайткан төрки-татар характеры кебек уйланыла.

Н. Фәттахның «Итил суы ака торур» (1969) романында Идел-Чулман болгарлары дәүләтенең оешуы, төрле ыру-кабиләләрне берләштерү тарихы тасвирлана. Көчле позициядәге мәгънәләрне роман эчендәге бәйләнешләрдән табабыз. Роман исеме – борынгы җырның беренче юлы. Шуннан чыгып, исеменең мәгънәсе – Идел ярларына сыеша алмый, ireккә омтыла. Ireккә чыга, җәелә һәм шулай итеп тереклек өчен уңайлы шартлар тудыра. Идел образының мәгънәләре эпиграфта кабатлана, көчәйтелә:

1. Автор үзе борынгы дип әйткән җырда Идел – заман агышын күрсәтүче вакыт ака торур).

2. Идел – бик куәтле ил (ярларына бәрә, киңәя, тереклеккә уңай шартлар тудыра).

3. Автор үзе хәзерге заманныкы дигән җырда хәзерге заман татар кешесе дигәнне укыйбыз.

Икенче эпиграфтагы мәгънәдән автор Тотышнымы, әллә Бөек Болгар дәүләтенме кызгануын аңларга мөмкин. Н.Фәттахны милләтнең 70 нче еллардагы хәле борчый, вакыйгалар шул дәверне күздә тотып языла.

Роман берничә вакыйганы: йолык туен, Акбүреләрнең Казаяклар ыруы белән очрашуын, Алмыш ханның яу белән килүе һәм орыш вакыйгасын, Койтым бикәнең улы өчен сорап Алмыш ханга мөрәҗәгать итүен сөйләп бирә. Үзәктә гаделлек проблемасы чагылыш тапкан. Роман бер образ – Тотыш тирәсенә җыела. Романдагы конфликтлар:

1. Көчле, дәртле, үз гамәлләренә җавап бирү дәрәҗәсенә күтәрелеп җитмәгән яшь Тотышның үзен күрсәтәсе килә. Үзенең көчен, җитезлеген ул фәкать сугышта гына күрсәтә ала. Шуңа күрә егет ил агаларының килешеп берләшү сәясәтенә каршы чыга.

2. Тотыш табигате белән ирек сөюче шәхес. Аның ирек сөюенә йолалар, законнар каршы төшә.

3. Тотыш башкалардан үзенең көче, чибәрлеге белән аерылып тора. Үзеннән өстеннәргә ул бервакытта да битараф кала алмый: я табына, я юкка чыгара.Үзендә фикер, теләк, сайлау ирeген саклап калу өчен Тотыш гомер буе көрәшергә тиеш. Тотыш нинди генә көчле булмасын, йолаларны да, тирә-юньне дә, ханнарны да берьялгызы гына җиңә алмый. Шуңда күрә ул үләргә тиеш.

Сюжет сызыклары: беренчесе – Тотышнњ ир булу тарихы. Ул егетне Алмыш ханның тотык итеп алып китүенә кадәр бара. Икенчесе – Тотышның мәхәббәт тарихы. Беренче сызык икенчесенең дәвамы булып тора, сюжет бөтенлеген төенләнеш (йолык туе), вакыйгалар үстерелеше (Казаяклар килу), кульминацион нокта (Алмыш хан таләбенә Тотышның каршы чыгуы) һәм чишелеш (Тотышның җиңелеп әсир төшүе) хасил итә.

Роман маҗаралылыкка омтыла. Каршылыклар кискен, колачлы, көтелмәгән борылышлар ясарга сәләтле итеп оештырыла (Тотыш-ыру, Койтым кырнак-Алмыш конфликтлары )

Үзәк каршылык Алмыш ханның Акбүреләр ыруын буйсындырырга килүендә Тотышның хәлиткеч роль уйнавыннан гыйбарәт. Алмыш ханның сәясәте, Акбүреләр ыруының кучеп утыру тарихы, ыруара мөнәсәбәтләр һәм Тотыш тормышы, язмышы бер төенгә бәйләнә. Үзәк герой әлеге юлларны бергә җыйнаучы булып тора.

Бу романда Болгар дәүләте тормышы, гореф-гадәт, йолалар, сәүдә, мәдәният, дин мөнәсәбәтләренә зур урын бирелә. Автор халыкны (милләтне булып чыга) җыеп торучы, татулаштыручы көч дин дип исәпли, ләкин Тотышны дингә каршы куя. Йола – Тотыш иреген кысып торучы көч. Дин законнарын ул йола законнары дип атый, тыючы закон буларак аларга буйсынырга теләми.

Чор сурәтен тудыручы детальләр – йолык туе, кунак каршылау, үлекләрне күмү, орыш кагыйдәләре.

«Сызгыра торган уклар» (1977-1985) романында исә автор гомумтөрки яшәү моделен тергезә. Җитди сәяси, милли проблемаларны автор биредә дә милли тамырларын оныта барган татар укучысы алдында куя. Романның тарихи концепциясе алдынгы карашлы дәүләт кешесенең ердәм дәүләт булдыру, берләштерү бары халык теләге, мәнфәгатьләрен кайгыртканда гына була алуын раслый.

Әсәрнең буеннан-буена әлеге тормыш картинасының өч элементы: яшәү рәвеше-шартлары, төркиләр характеры, фикерләү рәвеше урын ала. Тарихилык принцибының бер шарты булган объектив вакыйгаларны ничек бар шулай сурәтләүдән тыш автор иҗади уйланмага да урын бирә.

Романның 1991 нче елда чыккан икенче басмасында автор сөннәр хакында тарихи белешмә бирә. «Сөн тарихын күз алдына китерүдә минем өчен борынгы кытай хроникалары, аерым алганда,

Сымацяньнец «Шицзи» («Тарихи язмалар») дигән хезмәте төп юл күрсәткече ролен үтәде», – дип яза Н.Фәттах.

Борынгы төркиләр тарихын тергезүдә үзара тыгыз бәйләнгән ике халыкның, дәүләтнең үткән тарихын чагыштыру ярдәмгә килә: «Сымацянь борынгы Кытай тарихы язган. Үзенең «Тарихи язмалар»ында сөннергә ул Кытайдагы вакыйгалар уңае белен генә тукталган. Шунлыктан, сөн тарихын дөрес аңлау өчен, азмы-күпме без Кытай тарихына да күз ташлап алырга мәжбүрбез». Сюжет сызыгы тарихи шәхес – сөннәр патшасы Тоумань һәм аның улы белән булган вакыйгаларга нигезләнә. «Һуннар үзләре – составына төрле кабиләләр кергән, этник яктан шактый чуар булган берләшмәнең үзәген төзегәннәр һәм бу берләшмә тулысынча аларның исеме белен аталган. Ул башлыча төркиләрдән, шулай ук монголлардан һ.б. халыклардан торган. Берләшмедә хакимлек иткән һуннарның да, башкаларның да бу бердәмлектә ихтыяжлары бигрәк тә сугыш куркынычы алдыннан сизелерлек көчәйгән», – дип яза И.Х.Хәлиуллин.

Беренче төп сюжет сызыгы далада шикле кешеләр күренүе белән башланып китә. Әлеге кешеләр сөннәрне сугышка котыртып, чин капкынына төшерергә телиләр. Туман тарханның сугышка барырга ризалашуы – төенләнеш. Сөннәр һөҗүм ясый, ләкин капкынга төшәләр. Кульминацион нокта – чин илендә Шихуанди үлү, сөннәрдә Албуганың тархан булуы Чишелеш – далада тупланган чиннәрне Албуганың җиңүе.

Икенче төп сюжет сызыгы – Туман тархан һәм Албуга арасындагы мөнәсәбәтләр. Ике сызыкны Албуга китергән сөенче вакыйгасы тоташтыра. Төенләнеш биредә Албуганың Табылдыкка карап торуы. Албуга әтисен коткара. Әтисе исә Албуганы үлемгә хөкем итеп курчаклар ясата., чин кызын тартып ала. Кульминацион нокта – Сөенеч баласын уңкул тәгин итү. Чишелеш – Албуганың тарханны үтерүе.

Туман тархан чиннәргә каршы бара, җиңелә, илне бөлдерә, Албуга сөннәрне берләштерә. Роман  төркиләрнең нык дәүләт төзүе турында. Халык мәнфәгатьләрен кайгырткан, көчле, акыллы, нык идарәче генә халыкны туплый, дәүләт төзи ала, ди Н.Фәттах.

Табигать үзгәреше, көнитеш, йола-гадәтләр бер үремтәдә сөннәр күзаллавында бирелә. Шуңа күрә төрки характер тудыруда пейзаж әһәмияткә ия (Албуганың каган сараена керү вакыйгасы). Кышкы ау

күренешенең мәгънәсе беренче китапның ахырында ачыклана. Кышык ау текстта ил, халык язмышына киная булып яңгырый.

Романда фәлсәфи гомумиләштерүләр дә күп (автор-хикәяләүче кешеләрне тумыштан ук бүленгән дип әйтә).

Билгеле булганча, романда сөн кабиләләре беркемгә дә буйсынмый торган аерым дәүләт буларак көн күрүче дәүләт итеп тасвирлана. Ләкин сөн дәүләтенең хакимият төзелеше детальләп бирелми. Романда аларның яшәү рәвеше Кытай җирендә оешкан дәүләт – Чин империясенең таркалып, сөннәрнең дәүләт буларак ныгый баруы аша тәкъдим ителә. Язучы төрле катлам вәкилләренең көнкүреше, ышануларына мөрәҗәгать итә.

Әсәр структурасында конфликтларны хакимлек өчен барган көрәш дип бер бәйләмгә туплыйбыз: Туман каган – Чин патшасы; Туман каган – Албуга; Туңгак алып – Исәнтәй; Күрекле бикә – Сөенче.

Төп проблемалар Туман тарханга һәм Албуга язмышына барып тоташа. Алар арасындагы мөнәсәбәтләр сөн халкының язмышына гына түгел, яу чапкан ил язмышына да тәэсир итә. Табылдыкка бәйле һәм урын үзгәләү – Салчак урынына басу тәҗрибәсез Албуганы Туманга каршы куя. Романда төрки тормыш күренешләрендәге хакимият өчен көрәш шулай яктыртыла башлый.

Көнчелек, хәйлә-мәкер – төркиләрдә иң киң таралган явызлык дип атала, төп проблеманың нигезен ачуга хезмәт итә. Бердәмлеккә мөнәсәбәт проблемасы да романда ярдәмче проблемалар рәтенә керә. Алдагы ярдәмче проблема булып үлемнән, онытылудан курку тора. Төп проблеманы ачуга куркусызлык, батырлык мотивы да ярдәм итә (Ментйәннең Кортка ана утка ташлангач әйткән сүзе). Күрекле бикә язмышы, уйланулары аша дәүләтнең таркала башлавы әйтелә. Каганның Туңгак алыпны читләштерүе, Исәнтәй киңәше белән йөрүе дә шул хакта сөйли. Автор каганның портретында да аңсыз, хакимлеккә омтылган кеше сыйфатларын берләштерә.

Горур, ирек сөючән, тәвәккәл, чыдам Албуганың рухи үсеше (тарихи шәхес – Маодунь исемле һун каганы, Кытай чыганакларында атасын үтергән кансыз, усал итеп бирелә) романда төрле әдәби алымнар – психологизм, портрет, пейзаж бирелешендә тәкъдим ителә. Әнисенең киңәшләре, Туңгак алып йогынтысы белән егеттә җаваплылык, мөстәкыйльлек кебек төрки характерны билгеләүче сыйфатлар формалаша. Албуганың гаскәр, ил башлыгы буларак рәхимсезлеге дә аклана.

Төрки көнитештәге йола-гадәтләрдән туй йолалары, корбан чалу һ.б. лардан тыш мәҗүсиллектән килгәннәрен – Ут-анага агач кисәген бирү, үлгәннәргә корбан бирү, мәет җирләү үзенчәлекләре, уртак хатын, уртак ир булу кебек мотивларның урын алуын билгеләп үтәргә кирәк.

1970-1980 еллар аралыгында үткән заман вакыйгаларын тасвирлаган Г.Бәширов, Г.Ахунов, Н.Фәттах әсәрләренең уртак ягы – татар халкы тарихындагы хакыйкатьне яктырту, ди әдәбият галиме А. Яхин.

**Текстлар**

1.Фәттах Н. Итил суы ака торур. Роман. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1980.

2.Фәттах Н. Сызгыра торган уклар. Роман. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1994.

**Төп әдәбият**

3. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 367 б.

4. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

5. Хатипов Ф. Нурихан Фәттах / Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.6: 60-90 еллар әдәбияты. – Казан: “Раннур” нәшр., 2001. – Б.172-185.

**Өстәмә әдәбият**

5. Әшрәфҗанов Х. Тарихка әдәби сәяхәт. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 288 б.

6. Яхин А.Г. Әдәбият: Татар гомуми белем мәктәбенең 11 сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2003. – 383 б.

## Гамәли дәресләр

## Тема: XX йөзнең икенче яртысы татар прозасында шәхес культы фаҗигаләре гәүдәләнеше (М.Хәсәновның “Язгы аҗаган” романы, И.Салаховның “Колыма хикәяләре” фаҗига-хроникасы, А.Гыйләҗевның “Йәгез, бер дога!” романы)

**М.Хәсәновның “Язгы аҗаган” романы:**

1. Романда хикәяләүче образларын атагыз.
2. Романда герой дискурсы:

1) Гази язмышын сөйләгез, автор иҗтимагый һәм шәхси сызыкларга бәйле нинди проблемалар куя:

а) Гази-Булат Хәнипович мөнәсәбәтләре. Конфликтның сәбәпләре, куелган проблемалар.

ә) Газинең хезмәт юлындагы фаҗигасе нәрсә белән бәйле? Гази үзе ничек кичерә? Романнан өзекләр китерергә.

б) Гази-Дисә мөнәсәбәтләре. Мөнәсәбәтләрнең Дисә карашларына йогынтысын ничек күрәсез?

в) Гази-Гөлүсә мөнәсәбәтләре. Романны каймалап алган бу сызыкта нинди проблема калкытыла? Гази куркак яисә ышанычсыз дип бәяләп буламы? Газинең шәхси фаҗигасендә кем гаепле?

д) Романда хикәяләүче Фәйзинең Газигә бәйле вакыйгаларны күзәткәндә уй-карашлары үзгәрәме, ихтыяры ныгыймы?

2) Иргали язмышын сөйләгез, автор иҗтимагый һәм шәхси сызыкларга бәйле нинди проблемалар куя:

а) Зәйтүнә апа образы аша нинди проблема калкытыла? Романнан өзек китереп раслагыз.

ә) Бәһрам җизнине ничек бәяләр идегез? Куркаклык, җайлашу хакында сөйләгәндә М.Хәсәнов стиле А.Гыйләҗев дискурсына якын тормыймы? Куелган проблеманы романнан өзек белән раслагыз (Бәһрам җизни Иргалигә нәрсә сөйли? Иргали Миргалиев эше кузгатылгач үз-үзен тотышы).

б) Гыйззәт хәзрәт образы ярдәмендә романда нинди проблемалар калкытыла? Романнан өзекләр китерегез.

в) Гыйззәт карт теле авторның Үшән Халәпләрне күтәргән җәмгыятькә бәясе әйтелә. Шул бәяне күрсәтегез. Үз карашыгыз. Иргали-Халәп сызыгын кыскача сөйләгез.

г) Сәүдә турында әйтелгән Гыйззәт хәзрәт фикерләрен язып алыгыз.

д) Иргалигә бәйле килеп кергән ат, торналар образларын шәрехләгез.

е) Солдат гомеренә Иргали бәясе. Илья Олегович Клочкин белән бәйле сызыкта нинди фикерләр җиткерелә?

ж) Иргали- Миңсылу мөнәсәбәтләренә автор фикере.

3) Таҗи образы иҗтимагый һәм шәхси сызыкларга нинди проблемалар өсти:

а) Җәүһәрия образына бәя бирегез. Бу образда татар кызына, хуҗабикә һәм хатынга хас булырга тиешле кайсы сыйфатлар туплап бирелгән?

ә) Таҗи холкының кайсы сыйфатлары калкытыла?

4) Һади образына ничек бәя бирерсез?

5) Гөлүсә образына бәйле килеп кергән гомерлек хисләр сызыгын сөйләгез (Гөлүсәнең портреты, язмышы, Гази белән очрашуы һ.б.)

6) Гаделша карт образын зирәк карт архетипик моделе дип билгеләп буламы?

**И.Салаховның "Колыма хикәяләре" фаҗига-хроникасы:**

1. Ибраһимны нинди шартларда кулга алуны сөйләргә.
2. Алкин образын автор ничек сурәтли? Аның кайсы сыйфатлары калку сурәтләнә?
3. Галимҗан Нигъмәти образын автор-хикәяләүче кайсы яктан аерып куя?
4. Гыйлем Камай кем ул?
5. Ардалион Михайлович Нижегородцев образын язмышын сөйләгез, образны автор кайсы яктан ача?
6. Чегән хатыны фаҗигасен сөйләргә.
7. Гений Измайлович Республиканец язмышын сөйләгез.
8. Гыйлемдар ага фаҗигасен сөйләгез.
9. Мохтар Мутин образы ничек тасвирлана?
10. И.Салаховның иреккә чыкканнан соңгы тормыш юлын сөйләгез.

**А.Гыйләҗевнең “Йәгез, бер дога!” романы:**

1. Көчле позицияне тексттан мисаллар белән шәрехләгез:

1)“Гыйбрәтләрне мисалга китергәндә, Аллаһы Тәгаләнең кодрәтле яхшы сүзен искәрмәдеңмени? Яхшы сүз – таза агач кеби ул, тамыры нык, ә ботаклары күккә ашкан!” (“Ибраһим”сурәсе, 29 аять)

2. “Соңгы очрашуларның берсендә “Сез татар халкының язмышын бик иртә аңлый башлагансыз. Моңа ни сәбәп иде?” – дип сорадылар”. Әдип ни дип җавап бирә? А.Гыйләҗевнең нәселе хакында нинди фикер кала?

3. Кем ул Хәбир Зәйнуллин? А.Гыйләҗев бу образны әсәргә ни өчен кертә?

4. “1944 нчедә Югары Баграж урта мәктәбен яптылар, унынчыга мин Сарман мәктәбенә бардым. 44 тә Казан университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылды. Алдагы бәхетле көннәргә юл бары тик университет аша үтә!” Хыялы тормышка ашамы? Университетка ничә тапкыр килә?

5. “Авыл тезләнгән, хәлсез. “Комсомолдан” дигәч, сиңа тиле кешегә баккандай карап торалар. Нинди комсомол, кемгә хаҗәт ул?.. Нигә без балачактан бер-беребезне алдарга һәм алданырга өйрәтәбез?” А.Гыйләҗевнең бу сүзләре аның иҗатының әрнү-сыктавы.

“Мин сезгә, һәрбарчагызга искиткеч рәхмәтлемен: минем рухым бөтенлеген сез саклап калдыгыз, җанымның Аллаһы Тәгалә биргән бөтенлеген ваттырмадыгыз”.

Бу һәм башка гыйбарәләргә бәйле А.Гыйләҗев шәхесе хакында ниләр әйтә аласыз?

6. А.Гыйләҗевны ни өчен МГБ га чакырталар? Нинди сәбәп белән кулга алалар?

7. Әдип татар халкына үрнәк булырлык сыйфатлар дип башка халыкларның кайсы сыйфатларын күрсәтә? Санап чыгарга?

8. Әсәрдә башка текстларның урын алуын ничек бәялисез?

9. Әдипнең фразасын дәвам итегез: “Рухың камил булса, Черек күл төрмәсендә дә ....

Бу фикер кайсы геройларга карата әйтелгән? Әдип геройларда кайсы сыйфатларны кабатлый?

10. Әсәрдә иң ошаган сатирик тәнкыйтьне язып куегыз.

11. Тоткын хатын-кыз образлары нинди тәэсир калдырды?

12. А.Гыйләҗевның идеаль образы кем, нинди сыйфатларга ия шәхес ?

## Текстлар

1. Гыйләҗев А.М. Йөгез, бер дога! Роман-хатирә. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1997. – 448 б.

2. Салахов И.Н. Колыма хикәяләре. Фаҗига-хроника. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. – 255 б.

3. Хәсәнов М. Язгы аҗаган: Роман. – Казан: Татар.кит.нәшр.– 1989. – 608 б.

## Төп әдәбият

4. Заһидуллина Д.Ф. ХХ гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: ХХ йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

## Тема: Герой дискурсы (А.Гыйләҗевның “Балта кем кулында?” романында төп герой аша бирелгән автор тавышы)

1.Романның төп герое Нәҗип Йосыф улы Нургалиев образының эшләнеше:

1) Басыйр Бариевич, Иван Иванович образлары ярдәмендә автор нинди проблема күтәрә? Бу образлар Нәҗип образын бәяләргә ярдәм итәләрме?

2) Фәридун Фазлыев кем ул? Автор бу образны кертеп, нинди проблема калкыта? Нәҗип Нургалиев белән ничек бәйләнгән?

3) Нәҗип- Наилә мөнәсәбәтләре, кем гаепле?

4) Нәҗип-Сабит мөнәсәбәтләренә үз карашыгыз.

5) Йосыф карт, Мәрьямбикә образлары ярдәмендә автор нинди фикер җиткерә?

2. Романда шартлы образлар эшләнеше:

1) Сары йорт образы кемгә бәйле килеп керә? Нинди мәгънәдә килә? Романнан өзекләр китерергә.

2) Фәридун Фазлыев йорты образы нинди мәгънә белдереп килә? Фатирлы-йортлы булу омтылышы Нәҗип-Наилә мөнәсәбәтләрен ничек үзгәртә?

**Текст**

1. Гыйләҗев А. Балта кем кулында / Әсәрләр, 4 томда. 3 том: Повестьлар, роман. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994. – Б.265-567.

**Төп әдәбият**

2. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

## Тема: Тарихи роман жанры (М.Хәбибуллинның “Кубрат хан” романы)

1. Кубрат ханны ил башы буларак характерлагыз.

2. Романда болгарларның характер сыйфатлары, хан, аның мохите ярдәмендә тәкъдим ителә. Автор-хикәяләүче аларның кайбер сыйфатларын аерып бирә, вакыйгаларны сөйләп нигезләргә:

1. Ирек сөю. Уртак тормышка күчү генә алар иркенә зыян салмый (халыкның, Кубрат ханның закон булдыруга мөнәсәбәтләрен әйтергә (Кубрат-Иоанн Фасиан сөйләшүе)). Дәүләтне ныгыту ул – халыкка ирек бирү.

2. Үз халкыңны ярату. Дәүләт башлыгының үз халкын ихтирам итүе, дәүләтнең киләчәген кайгыртуы (Кубратның халыкка мөнәсәбәтенә бәйле сүзләрен әйтергә, грек утының серенә төшенергә теләвен, чиркәү салырга ризалашуын, дин ирекe бирүен, Чәчкәне Юстинианга бирергә ризалашуын, коллар сатудан баш тартуын, Аслан улын базилевска тәрбиягә бирүен, җәйләүләрен улларына бүлеп бирүен сөйләргә).

3. Бәйсезлек өчен көрәшә белү (Дулуның Кубрат килгәнче халәтен сөйләргә, Византия империясенең, ханның ышанычына кереп, болгарларны христианлаштырырга омтылышын әйтергә, диварларны дүрт терсәк төзеттерүне билгеләп үтәргә)

4. Толерантлык (Кубрат ханның Константин, Ирсан белән әңгәмәләрен, дәүләттә тугандаш халыкларның мөнәсәбәтләрен сөйләргә).

5. Гореф-гадәтләрне саклап яшәү, киң күңеллелек (Агасикенең сатлыкҗаннарга мөнәсәбәт белән бәйле фикере).

3. Хронотоп тарихи төгәлләшә. Ачыклагыз.

4. Төп иҗтимагый сюжет сызыгын сөйләргә.

5. Вакыйгалар барышында Византия императоры Ираклийдан килгән илчелекне (патрикий Симеон, философ Иоанн Фасиан, илче Феофан, аның улы Константин) кабул итү, аларның үз теләкләрен төрки телдә җиткерүләре, ханның Константинны тотык булып Фәнәгүрдә калдыру теләген сөйләгез.

6. Автор-хикәяләүче исеменнән Кубратның үткәне хакында нәрсә әйтелә, диннәргә мөнәсәбәте ачыклана.

7. Грек уты нинди символик мәгънәгә ия? Кубратның теләген язып куегыз.

8. Ярдәмче конфликт булып Кубрат-төптәңре каршылыгы тора. Сөйләгез.

9. Ираклийның Феофан белән каршылыгы бар, сәбәбен әйтергә.

10. Баһадир Илбарыс-Чәчкә сызыгын сөйләргә.

11. Кубрат ханның кичерешләре диңгез, кояш, туган ил турындагы җыр образлары белән көчәйтелә. Сөйләргә, шәрехләргә.

12. Әсәрдә шартлы алымнардан җиде саны – җиде йолдыз, елга, дала, җиде ант каны тамызу кыз куыш уены, әсәр дәвамында елга шаулавының ишетелеп торуы, диңгез, Кубрат ханның яшәеш турындагы күзаллаулары, караул алыпны су анасы алу, кораб-диңгез образ һәм мотивларның мәгънәсен аңлатырга.

13. Романдагы проблематиканы сөйләргә:

1) дин проблемасы (Илбарыс-Ташбулат сөйләшүендә, Илбарысның ышануы, диннең асылы күңел сафлыгына бәйле рәвештә Кубрат хан исеменнән әйттерелә);

2) икейөзлелек проблемасы (Агасике, Симеон);

3) әхлакый проблема (Болгар-Рум каршылыгы, ил башларының фахишәлеккә, азгынлыкка мөнәсәбәте;

4) хыянәт проблемасы (төптәңре Ирсан).

**Текст**

1.Хәбибуллин М. Кубрат хан. Роман. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994. – 430 б.

**Төп әдәбият**

2. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

**Зачетка әзерләнү өчен сораулык**

1. 1960-1980 еллар татар прозасында стиль тенденцияләре.

2.Ә.Баянов прозасында лирик-эмоциональ башлангыч (“Тау ягы повесте», «Яшьлегемне эзлим»).

3. М.Мәһдиев прозасында лирик-эмоциональ башлангыч (“Торналар төшкән җирдә”, “Бәхилләшү”).

4. 1960-1980 еллар татар прозасында психологизм (Ә.Еникинең “Туган туфрак” хикәясе мисалында сөйләргә).

5. 1960-1980 еллар татар прозасында публицистик башлангыч (М.Юныс прозасы).

6. Авыл прозасы агымы. 1960-70 нче еллар татар прозасында авыл прозасы (Төхфәтуллин Р. “Авылдашым Нәби”, “Йолдызым”, М.Мәһдиевнең “Кеше китә, җыры кала” повестьлары).

7. 1960-70 нче еллар татар прозасында соцреализм чиген узган романнар (Г.Әпсәләмов прозасы).

8. Татар прозасында шәхес культы фаҗигаләре бирелеше. (М.Хәсәновның “Язгы аҗаган” романы, И.Салаховның “Колыма хикәяләре”нең язылу-басылу тарихы, А.Гыйләҗевның “Йәгез, бер дога!” романы)

9. Ф.Яруллинның “Кыйгак-кыйгак каз кычкыра” повестенда сентиментальлек үзенчәлеге.

10.Тарихи роман жанрын үстерүдә Н.Фәттах романнарының тоткан урыны. “Итил суы ака торур”, “Сызгыра торган утлар” романнары

11. Тарихи роман жанры. М.Хәбибуллинның “Кубрат хан” романына анализ. Романның проблематикасы.

12. 1980 еллар татар прозасында җәмгыятьнең гаделсез якларын фаш итү. А.Гыйләҗевның “Балта кем кулында?” романы. Романда тәнкыйди дискурсның оештырылуы.

**Реферат темалары**

1. Х.Сарьянның “Бер ананың биш улы” повестеның сюжет структурасы.

2.М.Мәһдиевнең “Бәхилләшү” романында лирик-эмоциональ башлангыч.

3. Р.Төхфәтуллинның “Авылдашым Нәби” повестенда авыл прозасы билгеләре.

4. Ф.Яруллинның “Кыйгак-кыйгак каз кычкыра” повестенда сентиментальлек үзенчәлеге.

**Агымдагы контроль эшкә әзерләнү өчен билет сораулары**
**Тема: 1970 еллар прозасында тарихи роман жанрының үзгәрүе (Н.Фәттах романнары)**

Билет №1

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. 50 яшьләр чамасындагы богадай таза, имәндәй төз озын буйлы Күрән бине нәрсә борчый?

2. Алмыш хан ханлыкны ничек ныгытырга уйлый?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. “Суга корбан бирү” йола-вакыйгасын сөйләргә. Бу мифопоэтик мотивның тексттагы мәгънәсен аңлатыгыз.

2. Этимчәк-Албуга мөнәсәбәтләрен сөйләгез.

Билет №2

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Утташ камның йолык туе алдыннан Күрән бигә сөйләгән төше.

2. Багдадка илче итеп кем җибәрелә?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Тарханның болан ату вакыйгасын сөйләгез. Бу вакыйга текстка нинди мәгънә алып керә? Ау вакыйгасы тагын кайчан кабатлана? Үз янындагы төлкегә дә тигерә алмавы нинди символик мәгънәгә ия?

2. Мамак ни өчен Аю-Мамак? Сылу-кыз һәм Аю-Мамак сызыгында нинди проблема калкытыла?

Билет №3

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Өлкән хатыны Әди үлгәч, Күрән би өлкән хатын итеп кемне куя? Ни өчен? Утташ кам бу сайлауны ничек кабул итә?

2. Текстта Бәкәч Чичән образы нинди вазифа башкара?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Туман тарханның беренче атудан соң алачыкка кереп китмәве нәрсә белән бәйле? Кайсы җәнлек атылмый? Бу текстка нинди мифологик мотивны алып керә?

2. Исәнтәй, тархан җиңелгәч, кемгә бара, нинди карар кыла?

Билет №4

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Йолдыз-кашканы корбан итеп бирү турында Койтым бикә Күрән бигә нинди киңәш бирә?

2. Алмыш ханның Тотышны якын итүе нәрсә белән бәйле?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Албуганың ау вакытында Туман тарханны коткару вакыйгасын сөйләгез.

2. Туман тархан мәетләрне күмүгә ничек карый? Күмү йоласын сөйләгез

Билет №5

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Аланның уртасында утырган ялгыз нарат текстка нинди мәгънә алып керә?

2. Аппак белән Тотыш йолалар турында ни сөйләшәләр? Автор позициясе. Ни өчен автор Тотышны дингә каршы куя?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Киез өйдә ау турында беренче сүзне кем әйтә? Туман тархан беренче батыр дип кемне атый, ни өчен? Ау беткәннән соң оештырылган бәйрәм нинди йоланы хәтерләтә. Сөйләргә.

2. Кортка-бикә кем ул? Аның үлемен сөйләгез. Ни өчен Ментйән “мондый куркусыз халыкны җиңү мөмкин түгел!” дигән нәтиҗә ясый?

Билет №6

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Йолык туе йоласын сөйләгез. Нинди максатка юнәлтелгән? Кайчан, ничек үтә?

2. Алмыш ханның Тотышка ат, корал бирергә уйлав ни белән бәйле?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Исәнтәй-Банхуаның тышкы рәвешен автор ничек тасвирлый? Сөннәргә килеп эләгү вакыйгасын, атасы Банлу белән тархан арасындагы мөнәсәбәтләрне сөйләп бирергә. Исәнтәйнең үлеме кемнән, нинди шартларда була?

2. Сырга бикә, Тутыя бикә, Кәринә бикәләр арасында булган каршылыкны Исәнтәй кем аша хәл итә. Ул образның әсәрдә архетипик модель булып торуын расларга.

Билет №7

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Чумак, җөфүт, румнардан Күрәнби нинди вакыйгага бәйле шикләнә?

2. Тотыш Корыч Тимердән ничек үч ала? Корыч Тимер ничек җавап кайтара?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Исәнтәнең Албугага кыз алып килү вакыйгасын сөйләгез. Албугага бүләк ителгән әлеге кыз кайдан, аны кем алып килә?

2. Баргынтай баба ни өчен дунхулардан качып китүне өнәми? Баба караша автор карашын кабатлый. Дәлилләгез.

Билет №8

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1.Тотышның йолага каршы баруы – бүреләрне үтерүе Тотышның кайсы ягын характерлый?

2. Утамыш көтүче ни өчен Тотышка Тимеркүкне бирергә теләми?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Ут аша сикерү йоласы романда кайсы образга бәйле килеп керә? Мифологик мотивның мәгънәсен аңлатыгыз.

2. Буран мотивы романда берничә тапкыр кабатлана. Кайсы вакыйгаларда буран коткаручы, кайсы вакыйгаларда куркыныч турында искәртүче булып тора?

Билет №9

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Казаяк һәм Акбүре ырулары хакында нәрсә әйтә аласыз: яшәгән урыннары, Ак хан җире, шөгыльләнгән гамәлләре.

2. “Миңа зур сулар ошый”,– дип Тотыш Аппакка кайчан әйтә?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Чәнси образына чин тәртипләрен аңлату вазифасы йөкләнә. Нинди проблемалар калкытыла?

2. Чин явыннан кайтучы куяннар, аланнар, сөйбүләр, сыбукларны Исәнтәй ни өчен сыендыра?

Билет №10

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Ямгырчы би Күрән бигә нинди хәбәр алып килә? Уй-нияте нинди?

2. Алмыш хан Тотышка нинди җаваплы эшләр тапшыра?

Н.Фәттахның "Сызгыра торган уклар" романы буенча:

1. Туман тарханның төшен сөйләгез. Автор нинди вакыйганың башлануын хәбәр итә? Төш чынга ашкач, тархан аны үзе ничек юрый. Детальләргә игътибар итеп сөйләргә. Булгак алыпның каракошны атуы белән төш арасында уртаклык бармы?

2. Далага басып кергән дунхуларны тасвирларга. Аларга Начин-нойон ни өчен ачулана? Салкын далада Начин нойон ни өчен елый?

Билет №11

Н.Фәттахның "Итил суы ака торур" романы буенча:

1.Ямгырчы бинең орыш хакындагы сүзенә Майчан аксакал ничек җавап бирә?

2.Тотыш иленә кайтканда үзе белән кемнәрне ала?

Н.Фәттахның "Сызгыра торган уклар" романы буенча:

1. Автор Баргынтай баба исеменнән сөннәр тарихына карашны әйтә? Сөннәрнең ничә еллык тарихы бар? Бу хакта автор әсәрнең язылу тарихын сөйләгән вакытта нинди фикер белдерә? Соңрак Тарханга Баргынтай нинди үпкәсен белдерә?

2. Җирән кемнәр кулыннан үлә? Күрекле бикә Начин нойонга ни өчен кирәк?

Билет №12

Н.Фәттахның "Итил суы ака торур" романы буенча:

1.Койтым бикә ни өчен Алмыш ханга яу чыгарга өнди?

2. Кайгы туе йоласын сөйләгез.

Н.Фәттахның "Сызгыра торган уклар" романы буенча:

1. Ана-камның төш юравын языгыз. Улын нәрсәдән кисәтә?

2. "Ике як та үзен җиңүче дип исәпләрдәй җиңүдән дә олырак җиңүнең булган юк" – дигән нәтиҗә автор карашы дип кабул ителә. Начин нойон белән Елдырым бәк илчедәре нәрсә турында килешә?

Билет №13

Н.Фәттахның "Итил суы ака торур" романы буенча:

1. Атасы Тотышка нинди җаваплы эш йөкли? Башкарып чыгамы?

2. Күрән бине кем үтерә?

Н.Фәттахның "Сызгыра торган уклар" романы буенча:

1.Тозлы күл ни өчен шулай дип атала? Аркача елгасы мифологик укылышта нәрсәне аңлата? Туңгак алып исеменнән кеше гомере, аның мәгънәсе әйтелә. Сөйләгез.

2. Елдырам бәк кодага ялынып барганда Күрекле бикә нәрсә турында уйлый? Аның өчен хәзер төп кыйммәт нәрсә? Фәлсәфи проблеманы билгеләп куегыз.

Билет №14

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Ямгырчы би Койтым янына нинди ният белән керә?

2. Койтым Утташ камнан ничек үч ала?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Туман тархан-Албуга кофликты башланган урынны Табылдыкка бәйле вакыйганы сөйләгез. Ни өчен тархан Табылдыкны Сөенечкә алыштыра? Ни өчен Сөенеч баласы тәхеткә ия була?

2.Серле бөти аба аланнар белән куяннарны ничек берләштерә?

Билет №15

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1.Тотышның Тәңкәгә өйләнергә ният итүе нәрсә белән бәйле?

2. Күрән үлгәч ыру башы итеп кем сайлана? Нинди шартларда?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Албуга ни өчен Сөенечтән баш тарта?

2. Чин һәм сөннәр арасында булган йола-гадәтләр аермасын автор Албугателе белән ничек әйттерә?

Билет №16

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Тотыш Алмыш хан белән конфликтны ничек хәл итмәкче?

2. Тотыш белән Тәңкәнең соңгы көрешүе.

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Корбан бирү йоласын сөйләргә.

2. Бага алдына килеп баскач, чиннар ягында Албуга Туңгак алыпның кайсы сүзләрен исенә төшерә? Үзенә чиннәр тарафыннан яңа өй корылганда, алыпның һәм әнисе белән Бөртекнең сүзләре ничек йогынты ясый? Сөйләгез.

Билет №17

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. “Өчкә түгел, өч унга, өч йөзгә дә каршы чыгудан курыкмый торган батыр бул”. Бу сүзләрне кем әйтә?

2. Аппак нинди шартларда кияүгә озатыла?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Куян ыруыннан булып калгач, Албуганын беренче гамәле нинди була? Сөйләргә.

2. Чан чен кайда, ничек корыла? Кем тарафыннан? Шихуандины күмү-кабер-төрбәгә озатуны сөйләгез.

Билет №18

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Чәкән алпагыт кем ул?

2. Габдулла Алмышка хәзәрләр турында ни сөйли?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Каравыл агасы  Туңгак алыпны нәрсәдә гаеплиләр? Ул үзе тарханны гаеплиме? Ни өчен? Яргу-хөкем эшен кемнәр башкарырга хокуклы? Тархан алыпны гаиләсеннән аерып кая сөрә? Аның алдагы язмышы хакыда да сөйләгез.

2. Албуга туганнарның уртак кызга ир булу йоласын чиннәр янында ничек файдалана?

Билет №19

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Будрач сукман кем ул?

2. Майчан аксакал Ямгырчы бигә килгәч Тотышка нинди киңәш бирә?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Котлуг бәк белән Күрекле бикә арасындагы мөнәсәбәтләрне сөйләгез. Күрекле бикә атасын нидә гаепли?

2. Лисы Хухайга тәхеткә менәргә ничек ярдәм итә? Вәхшиләрчә үтерелүен сөйләгез

Билет №20

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Батырлар орышында кайсы баты сөнге, кайсы батыр кылыч белән орыша? Ни өчен?

2. Алмыш хан Тотышка нинди титул бирә? Нинди шартларда?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1.Уң кул тучи бәк тәгин углының куян атканга Төпсәнең башын чабуы Күрекле бикәне ни өчен борчуга сала? Туңгак алып белән алар бу турыда нәрсә сөйләшәләр? Төпсәне үтерүен соңрак Албуга чинннарда әсирлектә искә төшерә. Сөйләгез.

2. Ябалак карт белән Хучи картның очрашуын, аңарда көн күрүен сөйләргә.

Билет №21

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Корыч Тимер кем ул? Тотыш-Аппак язмышына ничек йогынты ясый?

2. Котанга тарханлык ничек эләгә? Нинди шартларда үлә?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1.Күл иясе ни өчен Күрекле бикәгә ачулы? Су иясе сакчысын үтерү Шихуандига ничек йогынты ясый?

2.Тархан-Албуга, Булгак алып-улы очрашу вакыйгаларын чагыштырып сөйләргә.

Билет №22

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1.Тотыш кайсы батырны ни өчен җиңә алмый? Нинди шартларда тотык була?

2. Котанның тархан булгач Тотышка бәйле иң әүвәлге нияте?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. “Яшәү ул – үлемне җиңү”. Кем сүзләре? Кемгә дүрт үлемне җиңәргә кирәк? Әсәрдә төп геройга бәйле бирелгән дүрт үлемне языгыз. Үлем сүзенә нинди мәгънә салына?

2. Автор карашы буларак оештырылган имче карт теле белән сөйләнгән борынгы бабаларыбыз тарихын искә төшерегез.

Билет №23

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Ямгырчы бинең Алмыш белән бәйле нияте нинди?

2. Гарәпләргә сатыла торган кол кызларны сурәтләп, автор текстка нинди мәгънә алып керә?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1.Кучеп киткәч, Туман тарханның Күрекле бикә, Албугага беренче боерыгы нинди? Ул ничек үтәлә?

2. Серле коралны кем уйлап таба? Сызгыра торган ук нәрсә ул, ничек истә калды? Символик мәгънәсен аңлатырга.Ук кемгә тапшырыла? Беренче уктан нәрсә һәм кем үлә?

Билет №24

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Торымтай кем ул? Тотышка, Тәңкәгә бәйле сөйләгез.

2.Тотыш Аппакны соңгы тапкыр нинди шартларда күрә? Ни өчен елый?

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Чәнси кем ул? Албуга белән нинди бәйләнеше бар?

2. Сөн тарханы Туманны күмү вакыйгасын сөйләргә.

Билет №25

Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча:

1. Кайсы вакыйгадан соң Алмыш хан “Безгә бердәмлек кирәк, иминлек кирәк, көч-байлык кирәк”– дип әйтә?

2. Көчле позицияне аңлатырга.

Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы буенча:

1. Инчжән үзен ни өчен Шихуанди дип атый башлый? Аның яшерен теләге нинди?

2. “Ил йөрәге, йорт терәге – ана!” Бу сүзләр кем тарафыннан кемгә әйтелә?

## Әдәбият исемлеге

## Текстлар

*Әпсәләмов Г.* Сайланма әсәрләр. 5 томда. Т.1.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.

*Баянов Ә.* Сайланма әсәрләр. Ике томда. I том: Повестьлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1993.

*Гыйләҗев А.М.* Йәгез, бер дога! Роман-хатирә. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1997. – 448 б.

*Гыйләҗев А.* Балта кем кулында / Әсәрләр, 4 томда. 3 том: Повестьлар, роман. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994.

*Еники Ә.* Әсәрләр. 3 томда. 3 том. Хикәяләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1991. – Б.146-175.

*Мәһдиев М.* Сайланма әсәрләр. 3 томда. I том: Повестьлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994.

*Мәһдиев М.* Сайланма әсәрләр. 3 тода. III том: Повестьлар, роман. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1996.

*Сарьян Х.* Бер ананың биш улы. Повесть, хикәяләр. – Казан: Тат.кит.нәшр, 2000.

*Салахов И.* Колыма хикәяләре. Фаҗига-хроника. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989.

*Төхфәтуллин Р.* Сайланма әсәрләр. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшр. (ТаРИХ), 2000.

*Фәттах Н.* Итил суы ака торур. Роман. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1980.

*Фәттах Н.* Сызгыра торган уклар. Роман. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1994.

*Хәбибуллин М.* Кубрат хан. Роман. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994.

*Хәсәнов М.* Язгы аҗаган: Роман. – Казан: Татар.кит.нәшр.– 1989.

*Юныс М.* Шәмдәлләрдә генә утлар яна (Биектә калу). Әсәрләр. Алты томда. I том. – “Рухият”, 2003.

## Төп әдәбият

*Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

## Өстәмә әдәбият


Татар телендә

*Әпсәләмов* Габдрахман // Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек / Төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. – Б.99-101.

*Әшрәфҗанов Х.* Тарихка әдәби сәяхәт. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 288 б.

*Бәширов Г.* Әдәби осталык турында // Совет әдәбияты, 1952.– №1.– Б.89-97.

*Гайнуллина Г.Р.* Ә.Баянов повестьларында лирик-эмоциональ башлангыч / Фәнни язмалар – 2006. – Казан: Казан дәүләт университеты нәшрияты, 2007. – Б.114-122.

*Гайнуллина Г.* Кереш сүз / М.Юныс. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б.5-17.

*Галиуллин Т.* Шәхесне гасырлар тудыра: Әдәби тәнкыйть, хикәяләр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2003.

*Заһидуллина Д.* Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгат улы (1930-1995). – Казан: Казан дәүләт ун-ты нәшрияты. – 2003.

*Заһидуллина Д.* Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004.

*Заһидуллина Д*. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.4-5.

*Мәһдиев М.* Секстан белән йолдызлар үлчәргә // Казан утлары – 1977. – № 5. – Б.148-152.

*Миңнуллин Ф.* Балта явызлар кулында: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. (Т.Галиуллин кереш сүзе). – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994.

*Мостафин Р.* Табышлар һәм югалтулар // Казан утлары. – 1980. – №9. – Б.162-164.

*Рахмани Р.* Кыйблабызга тугрылык. Әсәрләр. Алты томда. I том. – “Рухият”, 2003. – Б.5-38.

*Урманче Ф. И*. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А-Г). – Казан: Мәгариф, 2008.

*Хатипов Ф.* Нурихан Фәттах / Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.6: 60-90 еллар әдәбияты. – Казан: “Раннур” нәшр., 2001. – Б.172-185.

*Хәлим А.* Сагыну гамәле // Мәдәни җомга. – 1998,  9 гыйнвар.

*Яхин А.* Әдәбият: Татар гомуми белем мәктәбенең 11 сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия.  – Казан: Мәгариф, 2003.

*Яхин А., Мәһдиев М.* Халык иҗатын әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе (Мәкаль, табышмак, җырлар). – Казан: Казандәүләт ун.-ты нәшр., 1982.

Рус телендә

*Давлетшина Л.* Мифологизм в татаркой прозе конца ХХ – начала XXI в.в.  – Казань: РИЦ «Школа», 2006.

*Жюльен Н.* Словарь символов. – Челябинск: Урал LTD. –  1999. – 498 с.

Мифы народов мира. Энциклопедия (в 2 томах). Гл. ред. С.А.Токарев. - М. "Советская Энциклопедия" 1998. – Т.1. А-К.

*Лейдерман Н., Липовецкий М.* Современная русская литература: В. 3-х кн.. Кн. 2: Семидесятые годы (1968-1986): Учебное пособие. – М.: Эдиториал, УРСС, 2001

**Эчтәлек**

1.Тема: XX гасырның 60-80 нче еллар татар прозасында стиль тенденцияләре 3

2. Тема: XX гасырның 60-80 нче татар прозасында лирик-эмоциональ башлангыч: Ә. Баянов прозасы 5

3. Тема: М. Мәһдиев повестьларында лирик-эмоциональ башлангыч 10

4. Тема: 1960 еллар татар прозасында психологизм үсү (Ә.Еникинең “Туган туфрак” хикәясе) 25

5. Тема: XX гасырның 60-80 еллар татар прозасында фәлсәфи катламның публицистик катлам белән керешүе (М.Юныс прозасы) 28

6. Тема: 1960-1970 елларда соцреализм чиген узган проза (Г.Әпсәләмов иҗаты) 37

7. Тема: 1960-70 елларда татар прозасының яңартылган реализмга борылуы. Авыл прозасы агымы (Р.Төхфәтуллин, М.Мәһдиев) 58

8. Тема: XX гасырның 70 нче елларында тарихи роман жанры үсеше (Н.Фәттахның “Итил суы ака торур”, “Сызгыра торган уклар” романнары) 65

Гамәли дәресләр 72

1. Тема: XX йөзнең икенче яртысы татар прозасында шәхес культы фаҗигаләре гәүдәләнеше (М.Хәсәновның “Язгы аҗаган” романы, И.Салаховның “Колыма хикәяләре” фаҗига-хроникасы, А.Гыйләҗевның “Йөгез, бер дога!” романы) 72

2. Тема: Герой дискурсы (А.Гыйләҗевның “Балта кем кулында?” романында төп герой аша бирелгән автор “тавышы”) 75

3. Тема: Тарихи роман жанры (М.Хәбибуллинның “Кубрат хан” романы) 76

Зачетка әзерләнү өчен сораулык 77

Реферат темалары 79

Агымдагы контроль эшкә әзерләнү өчен билет сораулары 79

Әдәбият исемлеге: текстлар, төп әдәбият, өстәмә әдәбият 87